Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты
Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге

***Биктимирова Т.Ә.***

# ТАРИХЫБЫЗДА ТАТАР КЫЗЛАРЫ

Казан – 2025

УДК 82-92
ББК 63.3(2Тат)
Б 49

**Фәнни редакторлар:**
*М.М. Гибатдинов,* педагогика фәннәре кандидаты
*Л.Р. Мортазина,* педагогика фәннәре кандидаты

**Рецензентлар:**
*Ф.М. Солтанов*, фәлсәфә фәннәре докторы
*Х.З. Бәһаветдинова*, фәнни хезмәткәр

***Биктимирова Т.Ә.***
Б 49 **Тарихыбызда татар кызлары:** мәкаләләр җыентыгы. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2025. – 268 б.

ISBN 978-5-94981-407-9

Китапта авторның дистә еллар буе матбугатта басылган һәм Татарстан радиосында ясаган чыгышлары урын алды. Хезмәт киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-407-9 УДК 82-92
ББК 63.3(2Тат)

© Биктимирова Т.Ә., 2025
© ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2025

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз (*Ф.М. Солтанов*) ........ 5
Сөембикә һаман да халык күңелендә… ........ 11
Ул Мәчкәрә кызы иде ........ 17
Төшемдә җиде комганны утка аттым… ........ 20
Күренекле мәгърифәтче кызыбыз
Фәхрелбанат Сөләймания ........ 26
Татар хатын-кызларының беренче корылтаена 100 ел! ........ 31
Тарихларда җуелмаслык эзләре бар ........ 37
Кызлар язмышы – милләт язмышы ........ 43
Тукай даирәсендә – мәгърифәтче хатын-кызлар ........ 50
Халкыбызның гүзәл энҗесе Фатыйма Дәүләткилдеева ........ 59
Кемнәрең сагындыра… ........ 65
Кырым энҗесе ........ 71
“Вәгъдә – иман” дигән… ........ 77
Язмышларын белүчеләр бар микән? ........ 83
Милләт, киләчәк хакына ........ 89
Татар халкының мәгърифәтче кызы Фатыйха Аитова ........ 96
Онытмадык Сине, Зөһрә апа ........ 105
Безнең Җиһан апа ........ 114
Гражданнар сугышы батыры Зөһрә Алтынбаева ........ 120
Татар кызының үкенечле язмышы ........ 126
Мөгаллимә Фатыйма Әдһәмова хакында берничә сүз ........ 132
Алар үзебезнекеләр бит… ........ 137
Үткән елларның күркәм хатирәсе ........ 143
Ник үзәкне өзә үткәннәр… ........ 149
Сугыш чоры балалары ........ 155

Сез тартканны… ..................... 163
Ут эчендә татар кызлары… ..................... 169
Хәтерләүчеләр Мари урманнары гына түгел… ..................... 176
Олы ихтирам иясе укытучы Зәкия апа ..................... 180
Остазларым хакында берничә сүз (1960 елларда
Педагогия институты укытучылары) ..................... 187
Сездә галим булса, бездә галимә бар ..................... 193
Дан иясе Дания ..................... 198
Милләтпәрвәр Сүрия Усманова ..................... 204
Шәфкать иясе табибә Лилия ханым ..................... 211
Таныш өянкеләр дә рәхмәт әйтә… ..................... 216
Сабырлыкның гүзәл бер үрнәге иде ..................... 222
Алар – Мәрҗанинекеләр ..................... 227
Укытучы дустым, ай, Халисә! ..................... 234
Татарстанда ачлык фаҗигасе ..................... 240
Хезмәтләрендә туган җир тарихы ..................... 262
Ул дөньяга изгелек кылу өчен яратылган ..................... 265

# КЕРЕШ СҮЗ

Киң катлам укучыларга тәкъдим ителгән сезнең кулдагы бу китап тиздән үзенең 85 яшьлеген билгеләп үтәргә җыенган милләтебезнең горур кызы, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, фәнни монографияләре, вакытлы матбугатта басылган көнүзәк мәсьәләләрне күтәргән кыю мәкаләләре аша халыкта киң танылу алган мәгърифәтче-галимә Әхмәт кызы Тәминә ханым Биктимирова тарафыннан әзерләнде. Биредә урнаштырылган һәр язмада татарның төрле чорда яшәгән алдынгы карашлы асыл затлары – хатын-кызлары, аларның ачы һәм гыйбрәтле, бәхетле һәм бәхетсез язмышлары, милләтне үстерүгә керткән изге гамәлләре турында бәян ителә; аларга авторның җан авазы һәм җылысы, рухи күтәренкелек хисе салынган, шуңа да алар укучы күңеленә җиңел үтеп керәләр, аны уйландыралар, “күзләрен ачалар”, төрле нәтиҗәләр ясарга этәрәләр. Бу, бер караганда, бик табигый да, чөнки Тәминә ханымның шәхси тормышы, яшәеше, куйган хезмәте дә аның мәкаләләрендә телгә алынган шәхесләрнең язмышларына теге яки бу дәрәҗәдә охшаш һәм аваздаш.

Һәрнәрсәнең үз вакыты булган кебек, адәм баласының гомере дә табигатьтәге күк: аның да ямьле язы, эссе җәе, моңсу көзе һәм салкын кышы бар. Бу чорларны һәр кеше үзенчә кичерә, кемгәдер ул җиңелчә бирелсә, икенчегә зур сынаулар аша үтәргә туры килә. Шушы нисбәттән чыгып, галимәнең тормыш юлына, иҗатына кыскача гына булса да тукталып үтәсем килә. Максатым – аны мактаудан бигрәк, әлеге милләтпәрвәр гүзәл зат мисалында татар хатын-кызлары белән горурлану хисен белдерү, аларның көчле рухына һәм кылган изге гамәлләренә дан җырлау, киләчәк буыннар гыйбрәт һәм үрнәк алсыннар дип, шул хакта мөмкин хәлдә фикер уятырга тырышу.

Тәминә ханымның тәрҗемәи хәленә килгәндә, күңелемдә уелып калган шигъри юллар искә төшә:

*85 яшь ул – күп тә, аз да,*
*85 яшь ул – олы юл.*
*Төрлесе булгандыр юлда,*
*Юллар җиңел булмый ул…*

1940 елның 12 октябрендә Татарстанның Әтнә районы Яңа Шимбер авылында туган Тәминәнең гомер язы сугыш чоры авыл балаларыныкыннан берни белән дә аерылмый: ачлы-туклы балачак, әтисе булса да, кечкенәдән “уф-алла” арбасы тартып, әтисез эшләп үскән һәм Түбән Көек, Күлле Киме мәктәпләрендә тырыша-тырыша укыган яшүсмер еллары, паспорт алу һәм гаиләгә матди ярдәм күрсәтү максатыннан төзелешкә урнашу, Казан дәүләт педагогия институтында жан асрарлык стипендиягә яшьлек дәрте белән татар теле һәм әдәбияты укытучысы һөнәрен үзләштерүгә керешү, үзенең мәхәббәтен очрату, улы Айрат туу…

Гомеренең “эссе җәе” бик ук куанычлы башланмый, узган гасырның 60 нчы елларында илдә милли мәктәпләр, шул исәптән татар мәктәпләре дә, ябыла бара, татар теле укытучыларына элекке ихтыяҗ калмый. Яшь белгеч Казан авиация институтына китапханәче булып урнаша, тырыш ханымны берничә елдан КПСС тарихы кафедрасына өлкән лаборант итеп чакыралар. Шушы вакытларда ул фән өлкәсендә тәүге адымнарын ясый, төп хезмәтеннән аерылмаган хәлдә, “Хатын-кызларны социалистик җәмгыять (1920–1926 еллар) төзүгә җәлеп итүдә Урта Идел буе партия оешмаларының эшчәнлеге” дигән темага тарих фәннәре буенча кандидатлык диссертациясе яза һәм аны 1982 елда уңышлы яклый, студентларга мавыктыргыч лекцияләр укый башлый. 80–90 нчы елларда кузгалган үзгәреш җилләре татар тормышына да үтеп керә, кайчандыр дәүләтле булган халыкның милли үзаңы уяна һәм ул мөстәкыйль яшәү уе белән яна башлый, әлеге юнәлештә милли хәрәкәт юл яра. Җырларда җырланганча, “илдә көрәш барган чакта, өйдә ятып буламы” дигәндәй, милләтпәрвәр Биктимирова да бу көрәшкә якыннан кушылып китә, яңа оешкан Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетына эшкә күчә, бар көчен “Ак калфак” хатын-кызлар оешмасын һәм аның татарлар яшәгән төбәкләрдә филиалларын җайга салуга, халкыбызның гүзәл гореф-гадәтләрен яшьләрдә тәрбияләүгә куя, шушы максатта төрле конференцияләр, кон-

курслар оештыруда, аларны үткәрү өчен иганәчеләр эзләп табуда катнаша, радио аша хатын-кызлар турында тапшырулар алып бара, туган-як тарихын өйрәнү белән дә кызыксына һәм башкаларны да шул эшкә тарта, кыскасы, һәр яңалыкның үзәгендә кайный. Әмма дүрт елдан соң биредән китәргә мәҗбүр була. Язмыш аны яңадан фәнгә кертеп җибәрә һәм аңа сокландыргыч иҗади талантын тулысынча ачу мөмкинлеге бирә. Татарстан фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе бүлегендә өлкән гыйльми хезмәткәр буларак эшкә керешкәч, галимәнең балалар бакчалары сабыйларына, башлангыч сыйныф укучыларына атап язган “Минем шәҗәрәм” (1999) дигән кулланма әсбабы шул чор татар мәгарифендә чын мәгънәсендә зур яңалык була. Кече яшьтәге балада ата-анасына, нәселенә, туган йортына, иленә ихтирам уяту, алар белән горурлану, милли аң тәрбияләү юлында беренче адымнарын ясауда тәрбиячеләргә, укытучыларга ярдәм итү ниятеннән тәкъдим ителгән гаять тә кирәкле хезмәт ул. Шуңа да, әлеге кулланма зур тираж белән ике мәртәбә нәшер ителә, бүгенгәчә аның кулланылыштан төшкәне юк.

Тәминә ханым, үзенең фәнни юнәлешенә тугры кала биреп, катлаулы татар тарихын, аерым алганда, үтә дә сабырлык, үҗәтлек, җитдилек, җаваплылык таләп иткән эшкә – шул тарихта татар хатын-кызлары калдырган эзләрне барлауга – алына. Куанычлы нәтиҗәләр озак көттерми, бер-бер артлы “Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында” (2002), “Сорбоннага хәтле илткән белем юллары” (2003, рус телендә) кебек монографияләре басылып чыга. Татар мәгарифе, бигрәк тә мәгърифәтче татар хатын-кызларының бу өлкәдә куйган көчләре һәм уңышлары турында тарихи күзлектән чыгып язылган фәнни тикшеренүләрнең бик аз булуын, дистәләрчә еллар дәвамында халкыбыз аңына совет чорына кадәр татар хатын-кызы надан булган, укый-яза белмәгән, иренә һәм гаиләсенә генә хезмәт иткән дигән ялган уйдырманың сеңдерелә барганлыгын истә тотсак, галимәнең яңарыш китергән һәм архив чыганакларына таянып язылган бу китаплары күпсанлы укучыларының күзләрен ачты, хакыйкатьнең асылына төшенергә, уйланырга җирлек бирде. Безнең кызларыбыз алай ук надан булмаганнар икән бит, әйтик, XIX гасыр азагы – XX гасыр башларында талантлы һәм тырыш,

горур гүзәл затларыбыз абруйлы Сорбонна (берсе хәтта шунда укытырга кала), Женева, Санкт-Петербург, Мәскәү, Казан университетларында, бүтән танылган уку йортларында юриспруденция, медицина, авыл хуҗалыгы, математика һәм башка белгечлеклер буенча белем алып, милләтебезгә намуслы хезмәт иткәннәр. Тәминә ханым аларның тулы булмаган исемлеген төзи, анда Октябрь инкыйлабына кадәр төрле югары уку йортларында укыган 68, рус гимназияләрен тәмамлаган 185, рус һөнәри училищеларында белем үзләштергән 50 татар кыз баласының исем-фамилияләре күрсәтелә. Әлбәттә, киләчәктә бу исемлекнең тулыланачагына һич кенә дә шигебез юк. Алар арасында Сафия Сыртланова, Мәрьям Габдрахманова, Сара Шакулова, Сара Әхмәрова, Гайшә Апанаева, Әминә Мөхетдинова һ.б. бар. Тагын иң мөһиме шунда, бу монографияләрдә моңа кадәр оныттырылган, әмма онытылырга һич тә хаклары булмаган батыр йөрәкле мәгърифәтче хатын-кызларыбыз, шул җөмләдән Казанда иң беренче булып кызлар җәдит мәктәбе ачкан Бибимаһруй Үтәмешева, атаклы мөгаллимә Ләбибә Хөсәения, Фатыйма-Фәридә, Суфия Җантурина, Мәрьям Акчурина, Фатыйха Аитова һәм башкаларның исемнәре, аларның кылган изге гамәлләре халкыбыз хәтерендә янәдән яңартыла. Үзенең бер интервьюсында: “Мин егерменче гасыр башында яшәгән зыялы татар хатын-кызларыннан ак көнләшү белән көнләшәм: ир-атлар аларны акыллы, гүзәл, үз кадерләрен яхшы белүләре өчен хөрмәт иткән, аларның идеяләрен күтәреп алган, аларга үзләренең әсәрләрен багышлаган. Ә совет чорында бу мәрхәмәтле хатыннарның күбесе кыен хәлгә дучар ителә һәм хәтта Сталин лагерьлары җәһәннәме аша уза. Без аларның бөтенесен дә халкыбыз хәтеренә кайтара алмадык әле…”, – ди ул, җаны әрнеп.

Күренекле тарихчының “Ил язмышын салып иңнәренә” (2006) китабы – аның күңел биреп язган һәм укучылар тарафыннан бик тә җылы кабул ителгән тагын бер зур хезмәте. Бигрәк тә Ватан сугышы елларында татар хатын-кызларының батырлыкларына һәм күргәннәренә, ачы хакыйкатькә багышланган дулкынландыргыч сәхифәләр күпләрне тетрәндерә, бу хакта авторга алардан килгән хатлар сөйли, һәр кеше үзенең күз яшьләрен тамызган һәм ачы язмышларын әрнеп язган хатлар алар. Күрәсең, галимә үзе дә сугыш

чоры баласы булганга һәм татар хатын-кызлары кичергәннәрне үз күзләре белән күргән һәм үз җилкәсендә татыганга, аның язмалары кеше күңеленә тирән үтеп керәдер.

Татар халкының үзенә генә хас бай тарихлы педагогик карашлар системасы бар, ул гасырлар дәвамында барлыкка килгән, өстәлгән, үстерелгән. Әлеге күренешне күзалларга ярдәм итү максатыннан, Тәминә ханым эшләгән Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгендә фәнни тикшеренүләр алып барыла, галимнәр алдына татар халык педагогикасын чагылдырган татар халык авыз иҗаты әсәрләреннән, борынгы төрки чор, Кол Галидән алып XXI гасыр башына кадәр иҗат иткән мәгърифәтче язучылар, шагыйрьләр, мөдәррис-мөгаллимнәр, педагог-галимнәр, гамәли мәгариф хезмәткәрләре, укытучы-методистларның хезмәтләреннән унышлы дип табылган текст-өзекләр, үрнәкләр туплап, үзенчәлекле татар педагогик фикере үсешен күрсәтү, әлеге мирасны һәм байлыкны барлау, аларның дөньядагы гомумпедагогик киңлеккә керткән өлешен ачыкларга тырышу төп бурыч итеп куела. Бу зур эшнең нәтиҗәсе булып Татарстан китап нәшриятында ике томда басылып чыккан “Татар педагогик фикере антологиясе” тора (2014–2016). Кушымта рәвешендә татар мәгарифе үсешенә өлеш керткән күренекле шәхесләр (XVII гасыр – XX гасыр башы), татарлар белем алган атаклы мәктәп-мәдрәсәләр, татар телендә дөнья күргән тәрбия-тәгълим журналлары (XX гасырның беренче чиреге), атамалар сүзлекчәсе, шулай ук Татарстандагы халык мәгарифе җитәкчеләре исемлеге дә бирелә. Әйтергә кирәк, Т.Биктимирова бу коллектив хезмәтнең уртасында кайный, шактый еллар архивларда эзләнә, кешеләр белән очраша, һәр язган мәкаләсен үз йөрәге аша үткәрә, нык тырышлык куя.

Тәминә ханымның шәхси тормышы исә, фәнни тормыштан үзгә, аянычлырак килеп чыга, язмыш аны бу яктан иркәләми диярлек: тол калу, ялгызы үстергән һәм олы тормыш юлына аяк баскан өрлектәй бердәнбер улын, таянычын югалту хәсрәтен бүгенгә кадәр йөрәгендә йөрткән газиз ана да әле ул. Аның кебек укымышлы зыялылар хакында “аяклы энциклопедия”, диләр.

Инде гомеренең моңсу көзенә аяк басса да, Тәминә ханым моңсуланып утырмый, аның моңа вакыты да юк: бер караганда, ул туган нигезендәге йортын яңартып йөри, андагы җиләк-җимеш бак-

часында кайнаша, җиң сызганып авылы тарихын яза, икенче караганда, ул Татарстан районнарында, татарлар күпләп яшәгән Россиянең төрле өлкәләрендә төбәкне өйрәнүгә багышланган фәнни-гамәли конференцияләрдә, мәктәп укучылары белән очрашуларда, радио-телевидение тапшыруларында җитди мәсьәләләр күтәреп чыгыш ясый, Казанның “Ярдәм” мәчетендә татар хатын-кызларының милләт язмышында тоткан урыны турында лекцияләр алып бара, татар вакытлы матбугатында мәкаләләрен бастыра, татар мәгърифәтче хатын-кызларына багышланган музей-күргәзмәләр оештыруда башлап йөри. Аны татар хатыннарының балалары, оныклары белән үз ана телебездә сөйләшмәүләре, татар теленә карата торган саен арта барган битарафлык бик тә борчый. Әмма бу хәлнең яхшы якка үзгәрәчәгенә һәм үзе өйрәнгән тарихның кайбер гүзәл битләре кабатлануына өметен өзми, киләчәкне ул кайчандыр тарихта матур эз калдырган шәхесләр үрнәгендә тәрбияләнгән батыр йөрәкле, укымышлы милләтпәрвәр егет-кызларда күрә, аларга шул юнәлештә булдыра алганча белемен ирештерә, киңәш-табышын бирә.

Татар тарихында сокландыргыч эзләр калдырган гүзәл затларыбыз мирасын өйрәнгән һәм шуны халкыбыз хәтеренә янәдән сеңдерергә тырышкан тынгысыз җан иясе Тәминә Биктимирова үзе дә милләтебезнең горурлыгы булып тора. Ул һәрвакыт хәрәкәттә, гел ашыккан булыр, күрәмсең, әлегә яшәү көче барында үзе туплаган рухи байлык белән яшь буынны таныштырып калырга тели, милләт үсешен туктатмаска чакыра. Ул – хәйләли белми һәм хәрәмгә керми торган, туры сүзле шәхес, Тукайча әйтсәк, газраилне күргәндә дә дәшми калмас… Үзенә күз генә тимәсен! Гомеренең түгәрәк бәйрәме уңаеннан аңа киләчәктә дә тазалыкта-саулыкта бәхетле тормыш итүен, үзенең укучыларын яңа иҗади ачышлары, китаплары белән сөендереп торуын телисе килә.

***Фәрит Солтанов,***
*фәлсәфә фәннәре докторы*

## СӨЕМБИКӘ ҺАМАН ДА ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНДӘ…

*Сагышларны сүтә-сүтә,*
*Айлар үтә, еллар үтә.*
*Безнең язмыш синең белән*
*Мәңге бергә, Сөембикә.*

*Разил Вәлиев*

Сөембикә, Сөембикә ханбикә…. Олы тарихыбызда менә ничә гасырлардан бирле халкыбыз йөрәгендә мәңге төзәлмәслек яра да, азатлыкка омтылышыбызда фәрештәдәй изге җан һәм милләтебез язмышына битараф булмаучыларга үрнәк өлге дә ул Сөембикә ханбикә. Исемен, шәхесен пычратырга тырышсалар да, пычранмаган сафлык, намус иясе, буй җитмәслек гүзәл дә ул. Шул ук вакытта милләтебезнең ирегe өчен, эзсез югалудан саклап калу өчен көрәшкән каһарман да, фаҗигале язмышлы ана да ул Сөембикә. Менә шуңа күрә дә, исеме, образы Казан ханлыгы чорыннан сакланып калган аз санлы елъязмаларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә генә түгел, буыннардан-буыннарга изге васыять итеп тапшырылып килгән амәнәт тә кебек.

Бала чагымның иң матур бер истәлеген язып үтәм. Безнең Әтнә районы Яңа Шимбер авылында яшәгән Сәләхи бабай белән Хәтимә апаларга елга бер мәртәбә кыш көне бер укымышлы ханым килә иде. Әбиемнең мине, 4–5 яшьлек оныгын ияртеп шул ханымның (бәлки ул остазбикә дә булгандыр) сөйләгәннәрен тыңларга алып барганың хәтерлим. Ни үкенеч, анда ишеткәннәремне язып барырлык түгел идем әле.

Шул кичтә мин беренче тапкыр “Сөембикә, Сөембикә ханбикә” дигән исемне ишеттем. “Сөембикә бәете”н дә беренче тапкыр шунда ишеттем. Озак сөйләде бу хакта кунак апа. Тыңлаучылар елыйелый Сөембикә исемен кабатладылар.

Әле дә исем китә. Сугыш барган еллар иде бит. Кеше кайгы диңгезенә чумган вакыт. Ничек итеп үз кайгыларын бер якка куеп, Сөембикә язмышы өчен еладылар икән авылдаш апаларым. Әллә алар халкыбызның язмышына төшкән коллык газабын тирәнрәк

аңладылар микән? Шулайдыр, иманым камил, чөнки авылыбыз тарихы, нугай кабиләләре нәселеннән килгән авылдашларыбыз фаҗигасе дә, Явыз Иван сәясәте белән тыгыз бәйләнгән бит. Хәзер дә татар һәм нугай халыклары тарихына чөй кагучылар бар. Әмма юкка. Тарих күптән үз бәясен бирде инде.

Сөембикә исеме халык хәтерендә. Шөкер, аның образы тарихи әсәрләрдә, фәнни хезмәтләрдә, рәсем һәм музыка сәнгатендә гәүдәләнү тапты. Әмма, ни кызганыч, ни үкенеч, бүгенге көнгә кадәр үзе яраткан Казанына кайтып, постаментка басып халкыбызны сөендерә алмады. Ни өчен? Ничә гасырлар элек яшәгән бу изге затның бөеклеген бүген дә күтәрә алмаучылар булгангамы?

Татар халкы яраткан, хөрмәт иткән Сөембикә хакында олуг тарихчыбыз Һади Атласи сүзләрен искә төшерик. “Сөен-бикә Казаннан китә башлагач, аның кадерен белүчеләр күбәйде. Сөен-бикә Казаннан киткәндә Казан халкының ире-хатыны, кызы, зурысы һәм кечкенәсе Казан елгасына чаклы озата барулары, яшьләрен агызаагыза үксеп елаулары, күп кешенең Зөягә чаклы Сөен-бикә артыннан барулары – барысы да Сөен-бикәнең Казан өчен сагынырлык кеше булганлыгын аңлаталар иде”, – дип яза ул.

Сагынырлык кеше булгач, димәк, Атласи Сөембикәнең шундый катлаулы, авыр чорда ил белән идарә итә алырлык, тәвәккәл, зур ихтыяр көченә ия булган акылын, гыйлемен һәм хөрмәт иясе, югары әхлаклы кеше булганын күз алдында тоткан. Алай гына да түгел, ханбикәнең үз халкына мәхәббәтен дә, олы һәм кечеләрне хөрмәт итә белгән гаделлеген дә искә төшерергә онытмый галимебез. “Ул, Казан олугъларыны дәрәҗәләренә карап багышладыгы кеби, Казанның урта һәм түбән дәрәҗәдәгеләрене дә онытмыйдыр, һәркайсына үзенең сыеннан өлеш чыгарадыр иде. Аның шушы эшләре Казан халкының күңеленә бик нык урнашкан булганлыгы өчен, алар Сөенбикәне бик тиз генә оныта алмадылар. Ул үзе күңелләрдә калдыгы кеби, аның исеме дә телләрдә калды”[1].

Без, заманында борынгы тарихны да, урта гасырлар тарихын да өйрәнгән идек. Искә төшерсәк, кешелек җәмгыяте үсешен алга җибәрүдә тиңдәшсез өлеш керткән идарәче хатын-кызларның аз булмаганын күрәбез. Көнбатыш илләре тарихында да, мөселман

[1] Һади Атласов. Сөенбикә. Казан, 1914. 56–57 б.

илләре тарихында да мисаллар бар. Мисал өчен, Англия королевасы Елизавета I үз илен көчле диңгез державасына әйләндерә алган. Испания королевасы Кастилия Изабелла XVI йөз башында таркалып беткән дәүләтен берләштереп, көчле дәүләт оештырган. Төрки мөселман дәүләтләре тарихын карасак, тәхеткә беренче булып утырып, акылы һәм тәвәкәллеге белән күпләрне сокландырган Разия хатунны күрәбез (1232 ел).

17 яшьлек Сөембикәне Җан Галигә биргәндә дә Йосыф Морза шундый бурыч куя. “Алтын Урда таркалды, кызым. Казан ханлыгы тирәсенә берләшә алсак иде. Шуңа бөтен көчеңне, тырышлыгыңны куй. Акылыңа ышанам. Риза булсаң кызым, милләтеңнең, ватаныңның, халкынның данын коткарып калачаксын. Мин сиңа ышанам”, – ди. 18 ел гомерен багышлый Сөембикә бу ышанычны акларга.

Әйе, онытмады халык үзенең ханбикәсен. Октябрьгә кадәр һәм аннан соң да татарлар Сөембикә исемен кыз балаларына бирде, аның рухына багышлап Коръән укытты, догаларын укыды, мәҗлесләрдә “Сөембикә бәетен” һәм мөнәҗәтләрен әйтте. Бу истәлекләр миллионнарныкы икәнен кем кире кага алыр икән?

Боларга өстәп, кыз балалар өчен ачылган мәктәпләргә Сөембикә исеме бирелүе хакында әйтеп китәр идем. Мәсәлән, шундый исемдәге мәктәп Троицк шәһәрендә 1909/1910 уку елында ачыла. Кыз балалар өчен ачылган бу мәктәпне оештыруда зур тырышлык күрсәткән кеше – Төркиядә алган белемнәре белән татар, башкорт, казах халыклары арасында зур хөрмәт казанган Габдрахман Әхмәрев. Ул, киләчәктә бөек рәссам булып танылачак Чыңгыз Әхмәревның әтисе. Соклангыч хәл бит: әтисе кыз балалар өчен “Сөембикә” мәктәбе ача, улы Чыңгыз халкыбызның ханбикәсенең гүзәл рәсемен ясап, миллионнарны тетрәндерә, уйланырга мәҗбүр итә. Үз баласына Сөембикәнең матур образын сеңдерә алган Габдрахман агага ничек рәхмәт әйтмисең ди?

Мәктәп хакында бер ике генә сүз. Ул җәдиди мәктәп. Аның тормыш өчен иң әһәмиятле ягы шунда – биредә дин һәм дөньяви фәннәр иң алдынгы ысул белән укытыла. Әле Россиядә мондый мәктәп өчен мөгаллимәләр табу кыен вакыт. Габдрахман Әхмәрев “Сөембикә” мәктәбенә аларны төрле шәһәрләрдән эзли һәм таба да. Алар арасында Кәттә Курганнан Маһирә Латыйпова, Германиядә белем

алып кайткан Мәрьям Черкасова, Галия Буби, Нәфисә Төхфәтуллиналар бар. Мәгариф тарихыбызда исемнәре алтын хәрефләр белән язылырдай атаклы педагогларыбыз Газиз һәм Хәҗәр Әдһәмовлар, Закир Бакиров, Мәймүнә Шәфигуллиналар биредә эшли.

Бу хәлне милләт язмышына, аның киләчәгенә битараф булмау белән генә аңлатып була.

Ә без? Без хәзер Сөембикәбезнең исемен генә түгел, аның хакындагы дөрес истәлекләрдән дә качабыз төсле. Көчәнә-көчәнә, Сөембикә исемен йөрткән манараның, инде ничә тапкыр атаклы археологлар, галимнәребез раславына карамастан, төзелгән елларын үзгәртеп күрсәтү өчен фәнни хезмәтләр язабыз. Явыз Иван алып киткән китапханәсен эзләүчеләрне дә хәзер үзәк каналлар Иван Грозный китапханәсен эзләүчеләр дип күрсәтәләр. Эндәшмибез, шулай җайлы безгә.

1920 елдан 1922 елга кадәр яңа оешкан Татарстаныбызда ревком рәисе, Совнарком рәисе булып эшләп, ярты миллионнан артык (600 мең) халыкны ач үлемгә дучар иткән Сәетгалиевнең исеме мәңгеләштерелгән. Ә Сөембикәнеке юк. Ни өчен?

Әле ярый Чаллыда Сөембикә урамы, Казанда “Сөембикә” кафесы бар. Манара хакында әйттем инде.

Менә ничә еллар актив җәмәгать эшлеклесе Әлмира ханым Әдиятуллина башкалабызга Сөембикә исемендәге мәчет төзетү өчен тырышты. Атаклы җырчыбыз Гөлзада Сафиуллина бары йөрәге кушканга, яшь талантларны Кырымда җыеп, “Сөембикә варислары” дигән конкурс үткәреп килә. Рәхмәт үзенә.

Казахстан башкаласы Астанада да Сөембикә урамы бар диләр. Озакламый Сөембикәне дә үз кызыбыз дип әйтерләр әле казахлар (Алла сакласын!).

Тагын бер истәлек. Фронтовик язучы Мәгъсүм абый Насыйбуллин, Юрмалага ял итәргә баргач, ничек итеп күңелсез хәлгә очраганын сөйләгән иде.

Англиядән килгән язучылар аны оялтканнар икән. “Ник сез, татар язучылары, шундый патшабикәгез белән горурлана белмисез? Ни өчен сездә Шекспир трагедияләре кебек Сөембикәгә багышланган әсәрләр юк? Дөньяда тиңдәше булмаган ханбикәгезнең исемен пычраталар, ә сез дәшмисез? Нинди халык сез?” – дигәннәр.

Мәгъсүм абый бу сүзләрне күренекле журналистыбыз Шәех абый Зәбировка сөйләгәндә елады. Үзем шаһит. Горурланырлык шәхесләр бар бездә, Аллага шөкер. Тик без Мәскәүдән рөхсәт алгач кына бөек шәхесләребез белән горурлана алабыз шул.

2019 елның 18 декабрендә Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Сөембикәнең тууына 500 ел тулуга багышланган "Татар ханбикәсе Сөембикә: тарихи чынбарлыктан тарихи хәтергә" дигән темага фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Бу чараның искиткеч күтәренке, өметле шартларда үтүен язсам, язмам бик озакка китәр. Әмма чыгыш ясаучыларның да, катнашучыларның да уртак фикерен Россия ФА Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, Россия халыклары тарихы һәм этникара мөнәсәбәтләр үзәге җитәкчесе профессор Вадим Трепавловның сүзләре белән генә искә алып китәм. "Шартлы вакыт белән Сөембикәнең 500 ел элек туганлыгы искәртелү – очрашулар оештыру өчен шатлыклы сәбәп булуып тора. Фаҗигале язмышлы тарихи шәхесне өйрәнү игътибарга лаек".

Конференциядән соң катнашучылар барысы да зур кызыксыну белән Казан дәүләт филармониясендә оештырылган Сөембикәгә багышланган күргәзмәне карадылар. Соңыннан Ханбикәбезне олылап искә алуга багышланган кичә дә заманча матур үтте.

Әмма иң зур тетрәнү – Казаныбызда Сөембикәгә гасырлар дәвамында һәйкәл куелмавы. Казахстан Республикасының сәнгать эшлеклесе, дәүләт премиясе лауреаты, халык рәссамы, Россия һәм Кытай сәнгать академияләренең Мактаулы әгъзасы Камил Муллашев һәйкәлнең төрле варианттагы макетларын да конгрессның башкарма комитетына калдырып киткән иде. "Сөембикәнең" эчке матурлыгы, халкыбызны яратуы, тынычлыкка омтылуы, тирә-юньгә яхшылык теләве һәркемгә күренеп-беленеп торсын" дигән теләктә иде ул. Ни кызганыч, аның игелекле нияте дә бүгенгәчә тормышка ашырылмады әле.



*Сөембикә һәйкәле макеты. К.Муллашев. 2019 ел*

# УЛ МӘЧКӘРӘ КЫЗЫ ИДЕ

Мәгърифәткә, китапка мәхәббәт татарларда бик борынгыдан килә. Бу хакта халык авыз иҗаты әсәрләреннән, риваятьләрдән, җырлардан, бәетләрдән укып беләбез. Бу язмамда мәгърифәт учакларының иң мәшһүрләренең берсендә, ягъни тарихыбызга хаклы рәвештә "Татар университеты" исеме белән кереп калган "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе каршында кызлар өчен мәктәп ачкан Бибимаһруй Исхак кызын рәхмәт хисләре белән искә алам.

Инде белгәнебезчә, татар кызларына мәктәпләр ачу, XIX гасыр азаклары – XX гасыр башында киң таралган җәдитчелек хәрәкәтенә бәйле. Җәдитчеләр мәктәпләрдә яңа укыту ысуллары кертеп кенә калмыйлар, ә бәлки кызларны укытуның милләт өчен зарурлыгын да исбатлап, яклап чыгалар. Мәгълүм булганча, беренче кызлар мәктәбенә нигез салучылар да җәдиди муллалар, яки аларның абыстайлары була. Мисал өчен, Казанда ир балалар өчен беренче җәдит мәктәбен 1889 елда Галимҗан Баруди ачса, кызлар өчен беренче мәктәпкә 1890 елда аның хатыны Маһруй абыстай нигез сала.

Маһруй ханым 1862 елда элекке Вятка губернасы Малмыж өязе (Татарстанның хәзерге Кукмара районы) Мәчкәрә авылында тирә-юньдә халык хөрмәтен казанган, бай сәүдәгәр Исхак Үтәмишев гаиләсендә туа. Бу гаилә мондый хөрмәтне "гыйлемгә мәхәббәт, голәмәгә ихтирам, мәдрәсә шәкертләренә яхшы тәрбия бирү" белән казанган икән. Шуңа күрә Маһруйның йөрәгендә яшьтән үк белемгә мәхәббәт уяну һич тә гаҗәпләндерми. "1882 елда Казанга остабикә һәм килен булып төшкәч тә, буш вакытларында һаман гыйлемен арттырырга тырышкан, Галимҗан хәзрәттә булган татарча һәм төрекчә китапларны мөталәгә итәргә башлаган". Бу сүзләрне Барудилар гаиләсен яхшы белгән тарихчы, мөгаллим Шәһәр Шәрәф яза: "Маһруй ханым Казанда биш-алты ел торгач, кызлар укытырга керешкән. 1889 елда тирә-күршеләреннән берничә кызны укытып караган. Куркып кына эшкә керешкән Маһруй ханымга бу эш бик күңелле, муаффәкыятьле булып чыккан".

Бу хәлне, дөрес, әле чын мәгънәсендә мәктәп дип әйтеп булмый. Башка мулла хатыннары кебек, Маһруй абыстай да үз өенә

мәхәллә кызларын җыеп, аларга догалар, дин нигезләрен өйрәткән, бәлки хәреф тә таныргa өйрәткәндер. Әмма тәҗрибәләренең барысын да ире Галимҗан хәзрәт үрнәгендә, аның ярдәме белән эшләгән.

Тагын Шәһәр Шәрәф истәлекләренә мөрәҗәгать итәм. “Икенче елында остаз Галимҗан хәзрәтләрнең “Бәдигъ әл-мәгариф”, “Сәвадхан” кеби ысулы җәдидә китаплары басылып, “Мәдрәсәи Мөхәммәдия”дә ир балаларны ысулы җәдидә илә укыта башладыкта, Маһруй ханым кызларны да шул тәртип берлә укытырга, хатын-кыз галәмен дә агартырга кызыгып, үз өенә берникадәр кызлар җыеп, ысулы җәдидә берлә укыта башлаган… Маһруй ханым чын ихлас илә укытырга бирелеп, көне-төне шуның берлә мәшгуль булганга күрә, кызлар мәктәбе бик тиз тәрәкъкый иткән. Килеп укучылар елдан-ел күбәйгән”, – дип дәвам иткән Ш.Шәрәф.

Шәһәр Шәрәфнең истәлекләрен укыганда, Маһруй ханымның гүзәл тәрбияле, олы җанлы шәхес икәнлегенә сокланмый калып булмый. “Маһруй ханым, – дип яза ул, – 1893 елда үзләренең түбән катындагы бер бүлмәсендә янә бер сыйныф ачып, махсус мөгаллимә куеп, урамда сорашып йөрүче фәкыйрь кызларны тәрбияләп укытырга керешкән. Шул фәкыйрь кызларга һәркөн 3–5 тиен акча биреп, ялангач вә мохтаҗларына үз акчасыннан өс-башларын җитештерергә тырышып, мөгаллимәләр өстеннән үзе карап укытуын дәвам иттергән. Ушбу фокара (ярлылар) мәктәбендә һәр ел 40–50гә кадәр фәкыйрә һәм ятимә кызлар килеп укып торганнар. Шулай итеп, ханәсенең ике бүлмәсендә ике мәктәп дәвам иттергән”.

Изге гамәлләренең тагын берсе хакында әйтми калып булмый икән. Галимҗан Барудиның тырышлыгы белән “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә уку-укыту эшләре һаман җайга салына бара, шәкертләр саны да арта һәм уку бинасын зурайту мәсьәләсе килеп баса. 1894 елда Маһруйның кардәше Габдулла Үтәмешев дүрт мең сум, ә Маһруй абыстай ике мең сум акча түләп, мәдрәсәнең янәшәсендәге җирне сатып алалар һәм ике катлы агач бина салалар (Бу акчаларның күләмен хәзерге укучылар үзләре санарлар).

Шәһәребездә Маһруй абыстай мәктәбенең дә абруе үсә барган. Әмма абыстайның үзенә һәм ярдәмчеләренә бу мактаулы эштә төрле каршылыклар да очрап торган шул. Бигрәк тә наданлыкка һәм төрле хорафатларга каршы торырга туры килгән. Бу эштә һәм

мәктәпне танытуда уку елы азагында үткәрелгән имтиханнар ярдәм иткән. “Мәктәп, яңа тәртип берлә ачылган беренче мәктәп булганга күрә, яңача укытуның рәвешләрен вә файдаларын күрү өчен, дәрес вакытларында килүчеләр күп була, хосусән имтихан вакытларында бик күп хатын-кызлар җыела торган булган”, – дип язган Ш.Шәрәф.

Мәһруй абыстай мәктәбендә яңалыклар дигәндә иң беренчеләрдән шуны басым ясап әйтергә кирәк: бу – кызларны аваз ысулы белән укырга өйрәтү (элек гасырлар буе иҗек ысулы кулланылган). Ә мәктәптә кызлар берничә ай эчендә йөгерек укый башлаганнар. Кызларны язарга һәм Коръән укырга өйрәтү дә иң зур яңалыклардан булган. Заман өчен бу яңалыклар иң мөһим эшләрдән саналган. Мәктәпкә килеп укучылар күбәйгән, хәтта өлкән яшьтәге хатыннар килеп, балалар белән бер сафта утырып укырга өйрәнгәннәр.

Мәһруй абыстайның иң якын ярдәмчеләреннән Ләбибә Һадиулла кызы Хөсәенияне олы рәхмәт белән искә алып китик. Казан губернасы Чистай өязе Яңа Әмзә авылында мулла гаиләсендә туган кыз яшьтән үк зирәк, тырыш булып үскән. Бик иртә укый башлаган һәм китап аның гомерлек юлдашы булып киткән. Ул, әлбәттә, динигәхлакый китаплар белән мавыккан.

1896 елда Ләбибә, Казанга килеп, Мәһруй абыстайның иң якын ярдәмчесе булып эшли башлаган.

1904 елның маенда Мәһруй абыстай Барудия вафат булганнан соң, аның мәктәбе таралган. Менә шунда укучы кызларның бер өлеше Ләбибә Хөсәениядән үзләрен укытуын үтенгәннәр. Ләбибә ханым Мәһруй абыстай башлаган эшне дәвам итәргә риза булган. Рәхмәт аңа.

# ТӨШЕМДӘ ҖИДЕ КОМГАННЫ УТКА АТТЫМ…

Мәгариф тарихының алтын баганасы булырдай Фатыйха Габделвәли кызы Аитованың шәхесенә табынган кеше мин. Аның фидакарьлеген, милләтебезгә күрсәткән изгелеген бүген аңлап та булмас кебек инде.

Искитәрлек хәл, әтисеннән мирас булып калган акчасына Казан шәһәрендә татар кызлары өчен мәктәп, ә 1916 елда татарның ир балалары өчен дә булмаган вакытта (!), кызлар гимназиясе ача бит ул. Биналарын төзеткән, укытучыларга хезмәт хакы түләгән, читтән килүчеләр өчен пансионат та булдырган.



*Ф.Аитова мәктәбенең I сыйныф укучысы*
*Хәлимә Госманова (уңда) өлкән сыйныф укучылары белән*

Аның мәктәбендә белем алып, мәдәният тарихыбызның гүзәл энҗеләре булып танылган Мәрьям Рахманкулова һәм Сара Садыйковалар белән горурланабыз. Ә башка кызларыбызның язмышлары ничек булды икән, ниләр кичерделәр икән алар гомер барышларын-

да? Шулай кызыксына торгач, миңа Сара апа белән бер сыйныфта ук укыган Хәлимә Гаязетдин кызы Госманова-Әхмәрова язмышын белергә насыйп булды. Тик кыз баланыңниләр күргәнен язарга озак вакытлар хәлем җитмәде.

Хәлимә апаның әтисе Гаязетдин ягыннан да, әнисе Җәмилә ханым ягыннан да (татарның күренекле мәгърифәтчеләре, җәмәгать эшлеклеләре Касыйм, Ибраһим, Хәмит Бикколовларның апасы – Буа районы) нәсел шәҗәрәләре бик кызыклы: Гаязетдин – Борһанетдин – Фәхретдин – Хәбибулла – Госман – Юныс – Чирүче (сугышчы мәгънәсендә). Чирүче исеменең чыгышы тарихыбыз белән бәйле: имеш, Әстерхан ханлыгы җимерелгәч, ул яклардан чукындырудан качып киткән юлчылар (хан нәселеннән булганнар диләр) хәзерге Чирмешән районында, урман буенда ялга туктаганнар. Алар кулында яшь бала да булган. Әмма юл бик куркыныч булганлыктан, яшь баланы ефәк юрганга төреп бишеккә салганнар да, агачка элеп калдырганнар. Янына 200 сум алтын акча куйганнар. Хәлне аңлатып, 100 сум акча баланы тәрбияләгән кешегә, 100 сум баланың үз тормышына дип язу да калдырганнар. Баланың яхшы нәселдән икәнен аңлатып тәрбия кылып үстерүне дә үтенгәннәр.

Хәлимә ханым нәсел тарихын яхшы белгән, тик ачыктан-ачык язып калдырырга курыккан булса кирәк. Нәселләренең рус шагыйре М.В.Лермонтов белән бәйләнешләре хакында да өлкәннәрдән ишеткәнен балаларына сөйләгән.

Шунысы кызыклы: элегрәк, Лермонтовның ерак бабалары Шотландиядән чыкканнар дип кайларга гына язмыйлар иде. Ә менә 2007 елда Оксфорд университеты галимнәреннән Брайан Сайкс бу нәселнең геннарын тикшереп караган һәм нәтиҗәсен язып та чыкты. Россиядә яшәгән Лермонтовлар белән Британиядә яшәүче Лермонтлар арасында бернинди уртаклык та юк икән. Димәк, Михаил Васильевич та татардан бик ерак китмәгән булып чыга ич. Нәселләрендә дә татарлар барлыгы тарихта билгеле бит инде.

Хәлимә апаның әтисе Гаяз (Гаязетдин) Иске Тинчәле авылы мулласы Борһанетдин баласы. Тик Гаязга 4 яшь тулганда, ул үлеп китә. Әнисе баласы белән туган авылы Яңа Тинчәлегә кайта.

Кечкенәдән матур тәрбия алган, зирәк мулла баласының үскәч указлы мулла булып китүе гаҗәп түгел. Тик, яшь мулланың яңа-

лыкка омтылуы, балаларга дини генә түгел, дөньяви фәннәр дә укытуы ошап бетми авылдашларына. Алар Гаяз хәзрәткә төрле яла ягулардан, хәтта һөҗүмнәр оештырудан да тартынмаганнар.

Хатыны Җәмилә абыстай белән аларның Мәсхүдә, Рәхимә, Хәлимә, Мәхмүт, Зөфәр исемле балалары туа. 1901 елда туган Хәлимәсен Гаяз мулла Казанга, инде матур даны еракларга таралган Аитова мәктәбенә (Аит мәктәбе дип йөрткәннәр) 1909 елда үзе алып килеп урнаштыра.

Инде мәгълүм булганча, Фатыйха апа – Ислам дине кануннарын кечкенәдән канына сендергән, барлык таләпләрен һәм йолаларын үтәгән, затлы нәсел тәрбиясе алган зыялы. Мәктәбендә дә һәрбер укучы кызга намаз укуны мәҗбүри куйган.

Әмма, XX гасыр башы кешеләргә башка, яңа таләпләр куйган чор. Дин белән бергә дөньяви фәннәр өйрәнү кирәклеге акылы төзек һәркемгә аңлашылган инде. Шуңа күрә мәктәптә дөньяви фәннәр дә укытыла башлый. (Бу хакта “Ил язмышын салып иңнәренә” дигән китабымда язып чыккан идем инде). Шунысы да кызыклы – ана теле, гарәп телләре белән беррәттән, француз яки немец телен өйрәнүне дә кирәк тапкан Фатыйха апа.

Хәлимә апа менә шундый мохиттә укыган һәм гомер буе мәктәбендә алган, үзләштергән гадәт-тәртипләр буенча яшәргә дә тырышкан. “Әнием бик гыйлемле, сабыр кеше иде, – дип сөйли кызы Оркыя ханым. – Г.Тукайның барлык шигырьләрен дә яттан белә. Ш.Мәрҗани, Дәрдемәнд, Р.Фәхретдин, Акмулла кебек галимнәребезнең һәм шагыйрьләребезнең әсәрләрен дә, Пушкин, Чехов, Достоевский, Лермонтовларның тәрҗемә әсәрләрен дә яратып укый иде. Гарәпчәне су кебек эчә, Коръәннең күбесен яттан белә, вәгазьне бик матур сөйли иде. Болар өстәнә, Шәрык медицинасыннан яхшы хәбәрдар, күпләрне дәвалаганын да хәтерлим. Бөтен авыл халкы аңа киңәшкә, эч серләрен сөйләп җиңеләеп китәргә дип тә килә иде”.

Хәлимә апа Фатыйха Аитова мәктәбендә алган белемнәре белән Яңа Тинчәледә мөгаллимә булып эшли башлый. Кыз балаларны ул үзләренең өендә, ә этисе Гаяз имам ир балаларны мәчеттә укытканнар.

1926 елда Хәлимә Татарстанның хәзерге Чүпрәле районы Кушкуак авылы мулласы Әхмәров Гарифулла Шәрәфетдин улына кияүгә чыга (араларында 30 яшь). Әйтеп үтик, Гарифулланың этисе Шәрәфетдин сәүдәгәр булган, улына мәчетне дә үзе салдырып биргән икән… (Гарифулланың энесе Шиһаб Әхмәров – күренекле мәгърифәтче, Г.Тукайның иң якын дусты, бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевне тәрбияләп үстергән җизнәсе, репрессия газапларын кичергән кеше.

Тик, уйлап карасак, Октябрь революциясеннән соңгы еллар искә алырга да куркыныч бер чор бит. Совет власте урнашу белән башланган гражданнар сугышы, аңа ияреп үк килгән ачлык, мәчет-мәдрәсәләр ябылу, дин әһелләренең “хокуксыз җаннар”га әверелүе, булган мал-мөлкәтләренең тартып алынуы… Бу елларда бу хәлләрне кичергәннәрнең нинди аяныч хәлдә калуларын аңлау кыен түгел.

Илдә колхозлашу башлангач, гомерләрен халыкка аң-белем таратуга багышлаган муллаларны илдән сөрү башлана. Алар хәзер бөтенләй “контрреволюцион элемент”лар дип кенә атала башлыйлар. Менә шундый “элемент”ка әйләнгән Гаяз мулланы 1930 елның 24 мартында төнге сәгать 12 дә кулга алалар. Ул башта Буа, соңрак Казан төрмәсендә утыра. 1931 елның 25 февралендә Кемерово өлкәсенә сөрелә һәм анда шахтада эшләргә тиеш була. Әҗәле үк җиткән булган икән, шул ук елда, 67 яшьлек карт, шахтада күмер төялгән ике вагонетка арасында кысылып үлә. Бәхетенә дип әйтимме, янында үзе белән бергә тоткын булган Хәмит Бикколов кабергә куя алган аны. Берүзе казыган каберен дә. Рухына догабыз барсын.

Хатыны Җәмилә абыстай Бикколова да балалары белән кулга алына. Алар ерак Себер аръягына Чита өлкәсенә сөреләләр. Акыл ирешмәслек хәл: бу зинданнан башта 13 яшьлек Мәсхүдә Фирганәгә кача. Соңрак 7 яшьлек Рәхимәсе белән Җәмилә апа үзе дә Ташкентка качып китә алган. Башка балалар да шулай. Ни гаҗәп хәл, Ташкент урамында бу гаилә кешеләре бер-берсе белән очрашалар һәм шунда яшәп калалар. Качарга үз татарларыбыз булышкандыр дип уйлыйм. Ул вакытларда мәрхәмәтле кешеләребез булган бит әле.

Инде Хәлимә апаның үз язмышына килсәк, аларга да бер үк төсле “кояш”. Кулга алыначагын белгән Гарифулла хәзрәт Бакуга качып китә алган. Хәлимәне өч баласы белән 1930 елның 29 нчы февралендә йортларыннан урамга куып чыгаралар, анда авыл советы урнаша. 250 ел элек корылган нигез шулай җимерелә. 200 ел буе, ничә буын муллалар җыйган бик бай китапханә яндырыла. Булган мал-мөлкәт, хәтта бармакка киелгән йөзеккә кадәр талап алына.

Хәлимә апа, өйдән-өйгә йөрүдән туеп, сүтелми калган кечкенә өйләренә кире кайтып кергән. Сүтәргә килүчеләр куса да, чыкмаган. Соңрак барыбер чыгарганнар чыгаруын. Колхозга кергән. Кушкуак авылында балалар яслесендә тәрбияче, укытучы булып та эшләп алган. Аның белеме кебек белемле кеше булды микән әле ул чагында авылларда. Юктыр. Әмма авыл түрәләре ат караучы ите куялар аны. Колхозда нинди авыр эш бар – шунда эшләтәләр. Яз көнендә су ерып орлык ташый, тик аягына бик нык салкын тия. Шулай салкыны да, күргән газаплар да эзсез үтмәгән күрәсең. 45 ел аяксыз утыра Аит мәктәбен бетергән мөгаллимә.

Гарифулла абзый 1944 елда авылга кайткан, шөкер, ничектер кулга алынмаган, исән-сау калып, 1963 елда 90 яшендә фани дөнья белән саубуллашкан. Үлгәнче авылдашларын дини йолаларны үтәргә тырышып яшәгән, муллалыгын ташламаган.

Гаиләнең туганнары, балалары өстенә төшкән газаплар да җитеп ашкан. Авыл мәктәпләрендә укучы балалары да татып караганнар хөкүмәт сәясәтен. Оркыя исемле кызларын Чирмешән мәктәбеннән дүрт мәртәбә чыгарганнар. Никтер һаман яңадан чакырып алганнар. Уен уйныйлар дип белерсең.

Хәлимәнең Зөфәр исемле энесе үзенең хокукларын тартып алган, туган җиреннән куган илне саклар өчен Бөек Ватан сугышына киткән һәм 1943 елда һәлак булган. Оркыяда ике открыткасы саклана. Хат язарга да курыккандыр дип уйлыйм.

Хәлимә ханым төшендә “Җиде комганны утка аттым” дип куркып уянган. Гаиләсендә бер-бер артлы җиде ир кеше үлемгә дучар булган аның. Түзәргә шул динле булуы, сабырлыгы, күркәм тәрбиясе булышкандыр.

Гомеренең соңгы көннәрендә кызы Оркыя, кияве Әнвәр тәрбиясендә яшәгән. Оркыя югары белем алуга ирешкән, экономист булып эшләгән. Апасы Мәрьям тегүче.

Гарифулла хәзрәт 1963 елда вафат була. Ул үлгәч, Хәлимә апа авылда калмый инде, әйткәнемчә, Казанга килә. Оркыяның сөйләвенчә, үзен бик тәртипле, җыйнак итеп тоткан. Урамга чыкканда өйдә бәйләп йөргән яулыгы белән чыкмаган. Коръән укып, дини йолаларны бик тырышып үтәп яшәгән. Шунысы кызык: 61 яшендә ныклап русча өйрәнергә тотынган. Кызы “нәрсәгә инде ул сиңа”, – дигәч, “ник мин алардан ким түгел бит, телләрен аңламый утырырга”, – дигән.

Шигырьләр язган. Аларда үткән тормышын, баштан кичкән хәсрәтләрен аңлатырга тырышкан:

*Читләтеп үтте дип әйтмим,*
*Тормышның давыллары.*
*Басмады түгел күкрәкне*
*Кайгының авырлары.*

*Таныш миңа югалтулар,*
*Кичерешләр, янулар.*
*Түзә алмаслык газаплардан,*
*Ярадан сызланулар.*

*Тормыш утына каршы мин*
*Күкрәгем куйган кеше.*
*Әти-әни, туганнарны,*
*Дусларны җуйган кеше,*

– дип йөрәктән сыкрап чыккан хисләрен язган.

Ни хәл итәргә кирәк, ни өчендер дөньяның газаплары, бәхетсезлекләре талантлы, уңган яхшы кешеләргә күбрәк төшә. Урыннары җәннәттә булсын.

# КҮРЕНЕКЛЕ МӘГЪРИФӘТЧЕ КЫЗЫБЫЗ ФӘХРЕЛБӘНАТ СӨЛӘЙМАНИЯ

Бөтен гомерен хатын-кызларның мәгърифәтен күтәрү, агарту эшенә багышлаган, хезмәтләре әле бүген дә кыйммәтләрен югалтмаган татар мәгърифәтчесе һәм педагогы Фәхрелбәнат Сөләйманиянең тууына да 150 елдан арткан икән инде. XX гасыр башында беренчеләрдән булып матбугат дөньясына аяк баскан татар кызларының берсе ул. Ләкин никтер шушы көннәргә кадәр тормыш юлы ныклап өйрәнелмәгән, хәтта ки туган елы да төрле чыганакларда төрлечә язылган аның. Мәкаләм шушы бушлыкны бераз гына тулыландыру нияте белән языла да инде.

Халкыбызда "Оясында ни күрсә…" дигән мәкаль бар. Кыз баланы очырган ояга күз салсак, анда хөрмәтләп искә алырга лаеклы шәхесләребез барлыгын ачыклый алабыз икән. Фәхрелбанат 1865 елда (аен, көнен ачыклап булмады) Казан губернасы Чар өязе (хәзер Татарстанның Арча районына керә) Түбән Оры авылында туа. Аның әтисе Сибгатулла хәзрәт Сөләйман гомеренең күп өлешен шушы авылда имамлык хезмәтендә үткәрә. Шунысы безнең өчен әһәмиятле булыр дип уйлыйм, Сибгатулланың улы Лотфулла хәзрәт Сөләйман Орыдан ерак түгел урнашкан Котаймас (хәзерге исеме Кышлау) авылы имамы булган. Аллага шөкер, Лотфулла хәзрәтне хәзерге татар зыялыларына азмы-күпме билгеле шәхесдер дип уйлыйм. Чөнки аның кызы Галимәтелбәнат Биктимерия танылган әдибәләребезнең берсе. Әтисендә укып, уналты яшендә ул әтисенең кызлар мәктәбендә мөгаллимәлек эшенә керешә. 1895 елда кияүгә чыгып, Касыйм шәһәре якларындагы Янбаш (Җаубаш) авылына китә. Анда да кызлар мәктәбе оештырып, кыз балаларны заманча укыта башлый. Алай гына да түгел, язучылык эше белән шөгыльләнә һәм кыз балалар тәрбиясенә багышланган китапларын бастырып чыгарырга өлгерә. Тик бик яшьли, бары 30 яшендә үлеп китә. Олуг әдибебез Фатыйх Әмирхан аның хезмәтләренә зур бәя биреп "Тәрбиятел-этфаль" журналында махсус мәкалә язып чыга (№1, 1907).

Галимәтелбәнатның сеңелләре Затессәгадәт, Фатыйма, Гайшә, Гафифәләр – барысы да заманы өчен алдынгы белемнәр алган һәм,

кабатлап әйтәм, барысы да төрле җирләрдә кызлар мәтәпләре оештырган игелекле, булдыклы шәхесләр булганнар.

Аларга белем бирүдә этиләре куйган көч, хезмәтне әйтеп бетереп булмый. Лотфулла хәзрәт, үзе үзәк шәһәрләрдән читтәрәк яшәсә дә, “Тәрҗеман” гәзитен укучыларның берсе булган һәм яңа метод (аваз методы) турында сүз кузгалгач та, аны тормышка ашырырга керешкән. Кыз балаларын ул мөгаллимәлеккә үзе хәзерләгән. Махсус уку планнары, программалар, кулланмалар төзегән, төрле фәннәрдән төпле белем бирергә тырышкан. Хезмәте, шөкер, бушка китмәгән икән.

Фәхрелбәнат та шушында, кардәш кызлары янында белем алган. Әтисе Сибгатулла мәдрәсәсендә алган башлангыч белемнәрен шулай күтәрергә тырышкан. Лотфулла хәзрәт кызларга системалы рәвештә сарыф (морфология), нәхү (синтаксис), бәлгаять (поэтика), әдәбият гарәбия вә төркия (төрки һәм гарәп әдәбияты), гаруз (шигырь төзелеше), гакаид (дин нигезләре), хисап, тарих, география, ысул тәгълим (укыту ысулы – методика) һ.б. фәннәрне өйрәткән.

Лотфулла хәзрәт хакында безнең олуг галимебез Мәсгуд ага Гайнетдин язып чыккан иде, рәхмәт аңа.

Ә менә Фәхрелбәнатның Лотфулла хәзрәт кызлары янында белем эстәгәнен әдәбиятчы һәм тарихчы буларак танылган шәхесебез Габделбари Баттал (1880–1969) “Йолдыз” гәзитенең 1914 ел, 24 нче гыйнвар санында язып, искәртеп үтә.

Г.Баттал үз мәкаләсендә болай дип яза: “Күптән түгел, үз йомышым белән Мәскәүгә барган идем. Анда, Фәхрелбәнат ханым Сөләйманиянең яңа гына Истанбулдан кайтып, Мәскәүдә мелла Габдулла Шәмсетдинов ханәсендә тукталганын ишеттем. Фәхрелбәнат ханым […] Оренбург духовный собраниесендә әгъзалык иткән […], Нижний имамы Хәлил хәзрәт Сөләйманның рафикасы (хатыны) вә хәзер […] мәгъруф (атаклы, танылган) яшь имам Габдулла афәндедең вәлидәседер (әнисе). […] Фәхрелбәнат ханым […] бик иртә танылган ханымнарыбыздан Галимәтелбәнат Биктимериянең хәмширәсе […]”.

Габделбари Баттал мәкаләсе эчтәлеген тулысы белән китерү максатым түгел. Әмма аңлашылганча, Фәхрелбәнат Сөләйманиянең исеме 1914 елда татар зыялылары арасында инде танылган һәм

хөрмәт казанган кеше булганлыгы ачык беленә. Шулай булмаганда, аның белән очрашуны махсус эзләп кем барсын ди?

Фәхрелбәнат матбугатка 1905 ел революциясе чорында килеп керә. Аның беренче шигырьләре "Казан мөхбире" гәзитендә 1905 елда ук басыла башлый. Дөрес, иҗатының башлангыч чорында хатын-кызлар мәгарифе мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре ничектер төрекләргә якынлаштыруга тырышкан кебек. "Башлангыч мәктәпләр өчен, – дип яза ул, – бөтен дәрес китапларын, программаларны госманлылардан күчереп алып, ирләр һәм кызлар мәктәпләребез өчен бастырылып чыгарылып кулланылса, башлангыч мәктәпләребез алга китәр иде".

Тормыш аның бу өлкәдә бераз ялгышканын бик тиз ачыклаган. Ник дигәндә, 1908 елда аның ире Хәлил хәзрәт һәм Алма-Ата бае Габделвәли Исхаков Хаҗга барырга чыгалар. Тик ни сәбәптәндер Фәхрелбәнат Төркиядә кала (элек хатын-кызларның Хаҗга барулары хәзерге кебек гадәти күренеш булмаганы билгеле бит). Өч ай буе Истанбулда яшәгән, күзе ачык хатынга төрек хатын-кызлары тормышы белән якыннан танышырга мөмкинлек шулай ачылган. Тагын Г.Баттал истәлегенә мөрәҗәгать итик. "Фәхрелбәнат ханымның әйтүенчә, – дип күрсәтә ул, – төрекләрдә гаилә тормышы бик начар, ирләр тәүлекнең иң күп өлешен кәһвахәнәләрдә уздыралар, хатыннары моңаеп вә зарыгып аларны көтәләр. Гаиләдә өлфәт, иттифак вә киңәш белән эш кылу юк икән… Хәзер Истанбулда "Мөтәрәха хокук нисван" ("Хатын-кыз хокукын яклау") җәмгыяте нигезләнгән. Җәмгыять "Кадыннар дөньясы" исемле бер журнал чыгара. […] Журнал хатын-кызлар арасында мәгариф тарату өчен дә тырыша икән. […]

Фәхрелбәнат ханым "Кадыннар дөньясы"на күп кенә мәкаләләр язган. Татарларның гаилә тормышын, бездәге хатын-кызлар әхвален төрекләргә таныттырга тырышкан һәм төрек хатын-кызларын Русиягә чакырган […]".

Шушы сөйләшү барышында Г.Баттал Фәхрелбәнаттан киләчәккә нинди ниятләре барлыгын сорый. Ул аңа "Аналар" исемендә журнал чыгарырга теләге барлыгын, әмма Казанда чыга башлаган (1913, октябрь) "Сөембикә" журналы яхшы гына чыгып китсә, анда эшләргә, шуңа күрә Казанга күчеп китәргә дә теләге барлыгын әйтә.

Истанбулдан кайткач, Фәхрелбанат Казанга килә һәм 1914 елдан 1918 елга кадәр "Сөембикә" журналының сәркатибе булып бәрәкәтле хезмәт итә. Журналның редакторы Якуб Хәлили белән фикердәшләр булып эшләве аның иҗтимагый һәм иҗади активлыгын яңа югарылыкка күтәрә дияр идем. Ул бу чорда уку-укыту, бала тәрбиясе, гаилә, әхлак мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрне күп яза һәм алар укучыларның игътибар үзәгендә була. "Сөембикә" журналындагы мәкаләләрнең теле үзебезгә, халкыбызга якын. Темалары, эчтәлекләре, куелган проблемалары бүген дә әһәмиятен, кыйммәтләрен югалтмаган. Мисал өчен, "Без хәйәткә ничек хәзерләнәбез", "Татар хатын-кызлары дикъкатенә", "Балалар тәрбиясе", "Булдыксызлыгымыз", "Исмәгыйль Гаспринский", "Бөек фаҗига", "Идел буе матбугаты" – барысы да укучылар күтәп алган, көн кадагында торган мәсьәләләргә багышланган мәкаләләр.

Әйтеп үтик, Фәхрелбанат журналга хатын-кыз авторларны чакыра, аларның мәкаләләре дә һаман ешрак күренә башлый. Шундыйлардан Маһруй Мозаффария, Мәхбүбҗәмал Акчурина, Әминә Төхфәтуллина, Багбөстан Мөэминовалар журналда каләм чарлаган шәхесләр.

Фәхрелбәнатның кызлар мәктәпләре, андагы уку-укыту тәртипләре белән бик нык кызыксынып йөрүе гаҗәп түгел. Аны имтихан вакытларында мәктәпләр үзләре үк чакыра торган булганнар. Чөнки биредә ул гади күзәтүче генә түгел, ә бәлки якын киңәшче, ярдәмче дә була.

Уллары Габдуллла (1886–1937) аның горурлыгы да, мәңгелек йөрәк ярасы да.

Яшьтән үк бик сәләтле булган бу бала башта әтисе, соңрак Казандагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәләрендә белем ала. Соңрак (еллары билгеле түгел) Бәйруттагы Америка көллиятендә, университетта укый. Русиядә чакта татар, рус, гарәп телләрен белгән булса, Бәйрутта француз, инглиз телләрен өйрәнеп кайта. Кайткач, 1912–1917 елларда Түбән Новгородта мулла була.

1917 елдагы вакыйгаларда ул актив көрәшче, татар милли азатлык хәрәкәте лидерларының берсе була. 1917 елның апрелендә Түбән Новгород губерна мөселман комитетын оештыра. Бөтенроссия мөселманнар корылтайларының барсында да катнаша, чыгыш-

лар ясый. Чыгышларында хатын-кызларның ирләр белән тигез хокуклы булуларын яклап чыга. 1917–1918 елларда Милләт мәҗлесе делегаты, шул ук вакытта Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте казые (1917 елдан), Голямәләр шурасы әгъзасы (1926 елдан), Мәскәүнең Собор мәчетендә мулла (1929–1930) булып игелекле хезмәт итә.

Инде мәгълүм булганча, 1924–1927 елларда Диния нәзарәтенең казые, актив җәмәгать эшлеклесе Кәшшафетдин Тәрҗемани редакторлыгында Уфада "Ислам" мәҗәлләсе (журналы) чыгып килә. Габдулла Сөләймани журналның иң актив авторларының берсе. Ул дини йолаларга үзгәрешләр кертү турында уйлана, эзләнә башлый. Үзе гает, җомга көннәрендә сөйләнә торган вәгазьләрне саф татар телендә алып бара. Хәтта Коръәнне татар теленә тәрҗемә итеп, намазда укыла торган сүрәләрне дә татарча уку мәсьәләләрен күтәрә. Әмма мондый "бидгать" хәрәкәткә каршы барлык иске руханилар баш күтәрәләр. Диния нәзарәтенә гаризалар язалар, "Динне бетерәләр… Харап итәләр… Коръән татар телендә булса, аның бөтен изгелеге бетәчәк" кебек "зур дәлилләр" китерәләр.

Репрессияләр чорында Г.Сөләймани Диния нәзарәте әгъзалары белән берлектә 1930 елда кулга алына һәм 1937 елда үтерелә. Аның белән бергә халкыбызның горурлыгы, мактанычы булган иң зыялы шәхесләребез Җ.Абызгильдин, К.Тәрҗемани, Х.Атласи, З.Камали, М.Бубилар юк ителәләр. Урыннары җәннәттә булсын.

Фәхрелбәнат ханым бу хәсрәтләрне исән вакытында кичерә әле. 1918 елда журнал ябылгач, ул Сабада кызлар мәктәбе ачып, бер ел укыта. Соңгы гомере хакында беркем дә язмаган. Мәгълүматым юк. Вафаты 1959 елда.

Уйланам. Күпме эшләгән, нинди акыллы, милләтебезнең горурлыгы була алырлык бала тәрбияләп, заманында иң хөрмәтле ханымнарыбызның берсе булган Фәхрелбанат Сөләйманиягә дә язмыш артык елмаймаган икән. Ник талантлы шәхесләргә тормыш бу кадәр рәхимсез соң? Ә хәзер ник без битараф мондый шәхесләребезгә, аларның тормыш юлларына, хезмәтләренә? Ник онытабыз икән аларның халыкка күрсәткән изге гамәлләрен?

Урыннары җәннәттә булсын. Рәнҗемәсеннәр инде безгә.

## ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ КОРЫЛТАЕНА 100 ЕЛ!

XX гасыр башының үтә каршылыклы иҗтимагый-сәяси вазгыяте татар зыялыларын, милләтпәрвәрләрен үз дулкыны эченә ала. Бу дулкынның өермә-давыллары аларның барысы өчен дә җитди имтихан, милли сынау чоры була. Меңъеллык дәүләтчелек тарихы булып та, коллыкта изелүгә дучар ителгән татар халкы язмышка гына буйсынып яши алмый инде, ул уйланырга, азатлык өчен көрәшкә хәзерләнергә мәҗбүр. Төрле юнәлешләрдә барган көрәшнең башында татар зыялылары, милләт җанлы затлары тора. Алар арасында без укымышлы, бүген дә исемнәрен горурлык һәм сагыш белән искә алырлык кызларыбызны күрәбез.

Инде мәгълүм булганча, 1917 елның февралендә Россиядә патша хөкүмәтенә каршы хәрәкәт үскәннән үсә барып, хакимиятнең Николай II кулыннан IV Дәүләт Думасының вакытлы комитетына күчүенә китерә. Комитет үз нәүбәтендә, Вакытлы хөкүмәт төзеп, Дума утырышында раслата да. 21 мартта Вакытлы хөкүмәт рәисе князь Г.Е. Львов хатын-кызларның сайлауларда тигез хокуклы булулары хакында игълан итә. Хатын-кызларга хөкүмәт учреждениеләрендә эшләүгә дә хокук бирелә һәм шунда ук кадетлар партиясенең күренекле эшлеклесе С.В. Панина мәгариф министры урынбасары булып сайлана.

Мондый вазгыять татар хатын-кызларына да искиткеч тәэсир ясый. Тарих бүләк иткән форсаттан файдаланып, алар ирекле илдә иркенләп, алда торган бурычлар, чишәсе мәсьәләләр хакында сөйләшер өчен, тарихта беренче тапкыр мөслимәләр корылтаен үткәрүгә хәзерлекне башлап җибәрәләр. Инде 5 мартта ук Мәскәү татар хатын-кызларының җыелышы уза. Җыелыш Дәүләт Думасының Мөселман фракциясенә мөрәҗәгать кабул итә. Анда мондый юллар язылган була: “Мәскәүдәге мөселман хатын-кызлары Яңа хөкүмәтне тәбрик итәләр. Мәскәү хатын-кызлары кебек Казан, Уфа, Оренбург, Троицк, Әстерхан шәһәрләре хатын-кызлары да ничә гасырлардан бирле тапталган хокукларын сорарлар дип өмет итәбез … Аурупа хатын-кызларына күз салып, алардан гыйбрәт алырга кирәк”.

Мөрәҗәгать газета-журнал редакцияләренә дә җибәрелә һәм тиз арада бөтен мөселман хатын-кызлар дөньясын кузгата. Оренбург, Уфа, Троицк, Әстерхан, Сәмәрканд хатын-кызларының бер-бер артлы уздырылган җыелышларының барысында диярлек тигез хокук, азатлык, мәгариф лозунглары куела. Бу җәһәттән 17 мартта үткәрелгән Оренбург хатын-кызлары мәҗлесе карарлары игътибарны җәлеп итә. Алар: Оренбург мөслимәләре җәмгыятен бөтен Оренбург тарафыннан хөрмәт итәрлек итеп ислах кылырга (оештырырга); уку яшендә мәктәп күрә алмаган мөслимәләр өчен “җомга дәресләре” оештырырга һәм мөслимәләр өчен дарелмөгаллимат ачарга; мәгълүмат таратыр өчен авылларга хатын-кызлар җибәрергә; Төркестанда һәм Казахстандагы мөселман хатын-кызлары арасында аңлату эшләрен оештырырга һ.б.

Оренбург хатын-кызларының эшне колачлап алып бару һәм тугандаш хатын-кызларга да илдәге үзгәрешләрне төшендереп, азатлык көрәшендә ярдәм кулы сузу теләкләре аңлашыла. Карарларының үтәлешен тәэмин итәргә дип, алар 9 кешедән “Мөслимәләр комитеты” да оештырып куялар. Әгъзалары итеп табибә Разия Котлыярова-Сөләйманова, мөгаллимәләр – Маһирә Мөштәриева, Зәйнәп Вәлиева, Мәхфүзә Хөсәенова, Зәйнәп Камалия, Сәкинә Бакирова, Хәдичә Мәрҗания, Сафия Мәхмүдова һәм Тенишева (исеме күрсәтелмәгән) сайлана. Җыелыш соңында ул заман мәҗлесләренең аерылмас билгесенә әйләнгән “Уян татар” җыры башкарыла.

Югарыда искә алынган җыелышларның барсында да Бөтенроссия мөселман хатын-кызларына гомуми бер съезд кирәклеге хакында сүз кузгала һәм “әгәр була калса” дип вәкиләләр дә сайлана.

Мәскәү хатын-кызлары янә үз җенестәшләренә мөрәҗәгать белән чыгалар: “Мөслимә кардәш вә иптәшләр! – диелә анда. – Бу тарихи көннәрдә ханымнарыбызның хәзерге һәм киләчәктәге тормышлары өчен мәйданга чыгып, эшкә тотыныгыз! Яңгырдан соң чыккан гөлләр кебек бердәм күтәрелегез!.. Хәзерге көндә бөтен Русия халкы – русы, яһүде, әрмәне вә башкасы үзара киңәшеп җәмгыятьләр, съездлар ясап, аерым бер фикергә килә, сайлау хәзерлеген күрә. Сайлауда, сайланууда ханымнарга ирләр белән бертигез хокук биреләчәк булганга, аларның ханымнары да ирләре кебек үк эшли, хәзерләнә, төрле оешмалар ясый [...]. Безнең дә эшли, эшкә

ярый торган көчләребез бар. Фәкать болар бер җиргә, бер фикергә, бер максат астына җыелмаган. […] Ханымнар арасына чәчелгән көчләрне бергә җыеп, аерым бер юл белән барыр өчен без бергә җыелырга тиеш”[1].

19 мартта Казанда уздырылган хатын-кызлар җыелышын съездны хәзерләүгә турыдан-туры хәзерлек дияргә була. Чөнки аны оешкан төстә үткәрү һәм матди ягын тәэмин итү өчен җыелышта иганә дә җыела. “Кайбер ханымнар мең сумга кадәр иганә иттеләр”, – дип яза “Сөембикә” журналы[2]. Бу җыелышта әле яңа гына оешкан “Мөселман комитеты”на әгъзалар итеп Хәдичә Ямашева-Таначева һәм Гайшә Юнусовалар сайлана. Бераз вакыттан соң Гайшә урынына Әминә Мостафина кандидатурасы күрсәтелә.

Соңыннан съездны үткәрү өчен “Вакытлы мәркәз бюро” сайланып, аның рәисәсе итеп Хәдичә Таначева күрсәтелә. Әйтеп үтик, Хәдичә ханымның Россия мөселман хатын-кызлары арасында сәләтле оештыручы, дәрәҗәле, зыялы ханым булып формалашуында, һичшиксез, Хөсәен Ямашевның (Хәдичәнең беренче ире, Хөсәеннең вафатыннан соң ул Вәллидхан Таначевка кияүгә чыга) да, туганы Фуад Туктаровның да йогынтылары булгандыр. Татарның олуг затларыннан саналган бу шәхесләр милли азатлык өчен көрәшкә төрле юллар, төрле фикер каршылыклары аша килсәләр дә, тормышлары һәм көрәшләре белән татар дөньясы тарихында якты эз калдыралар. Хәдичә дә актив көрәшче, без өйрәнгән чорның азатлык көрәшендә, бигрәк тә хатын-кызларның тормышта тигез хокукларын даулап чыгучы. 1917 елдагы активлыгының Сталин репрессиясенә дучар итәсен ул әле белми, Россия тарихында беренче мәртәбә уздырылачак мөселман хатын-кызлары корылтаен хәзерләүгә үзенең бөтен көчен сарыф итеп йөри.

1917 елның 24 апрелендә Казан шәһәрендә Бөтенроссия мөслимәләренең беренче корылтае тантаналы шартларда үзенең эшен башлап җибәрә. Кызыл әләмнәр белән бизәлгән “Новый клуб” бинасы (элеккеге Лядов, хәзерге М.Горький урамында урнашкан) хөрриятккә, тигез хокук өчен көрәшкә, бөтендөнья хатын-кызларын берләшүгә өндәгән лозунглар белән тулы була. Корылтайга Эчке

[1] Сөембикә. 1917. №11. 191–192 б.
[2] Сөембикә. 1917. №10. 157 б.

Россия, Кавказ, Кырым, Төркестан, Польшадан сайланган 71 вәкиләнең барысы да чиксез дулкынлану кичерәләр. Сайланып килүчеләр янына дөньяда күрелмәгән бу хәлне “Күрү, ишетү өчен тагын өч йөздән артык хатын-кызлар килеп, баштан-ахырга кадәр чын ихлас белән утырдылар”, – дип яза Якуб Хәлили. – Чит ирләргә керергә ярамаса да, матбугат вәкилләре өчен махсус урын куелган иде”[3].

Корылтайны мәркәз бюро рәисәсе Хәдичә Таначева ача. Килгән вәкиләләрне тәбрик итеп, ул: “… Әлегә кадәр безгә хокуксызлык, золымнар хакында сөйләшергә иске хөкүмәт ирек бирми иде. Хәзер иске идарә бетте, революция безгә хөррият алып бирде. “Мәркәз бюро” исеменнән шатлыгымны сезгә белдерәм һәм съездны чын күңелемнән тәбриклим. […] Съезд Мәскәүдә булачак гомуми мөселманнар съездына кертелергә тиеш булган иң әһәмиятле мәсьәләләрне генә тикшерәчәк. Ул мәсьәләләр исә: хатыннарның шәригатьтәге хокуклары; аларның гаиләдәге тоткан һәм тотачак урыннары; сәяси хокуклары; иҗтимагый тормышта тоткан урыннары; Учредительное собраниягә катнашулары һәм шуны эшкә ашыру һәм хатын-кызларга махсус мөәссәсәләр.

Шушы алты мәсьәлә хакында бюро тарафыннан доклад хәзерләнде. Алар хакында сөйләү, бер карарга килү съезд эше булачак. Хәерле сәгатьтә мөхтәрәм иптәшләрем!”

Съездның президиумына Сара Әхмәрова (рәисә), булышчылары итеп Фатыйма Алкина, Хәдичә Таначева, сәркатиблеккә Зөһрә Салихова, Мәрьям Гобәйдуллина, Хәдичә Мостафина, Зәйнәп Алиевалар күрсәтелә. Докладларны карап, тикшерү өчен 5 комиссия сайлана. Шулар арасында хокуклар хакындагы докладны карап чыгу өчен Гайшә Абызкилдеева, Фатыйма Лотфия, Хәтимә Камалова һәм Мәрвәрит Туктаровалар сайлана. Иҗтимагый-сәяси хокуклар хакындагы комиссиягә тагын 12 кеше күрсәтелә.

Съездны укытучылар исеменнән Газиз Гобәйдуллин, Ташкент хатын-кызларыннан Сәгадәт Еникеева, Польша мөселман хатын-кызларыннан Мәрьям Криницкая тәбриклиләр. Гаяз Исхакыйның тәбрик телеграммасы алкышлап каршы алына. Татар халкының мәгърифәт өлкәсендәге мәшһүр кызларыннан Зөһрә Акчурина-

[3] Сөембикә. 1917. №11. 174 б.

Гаспринская һәм Фатыйма-Фәридә Нәүрүзоваларны зал аягүрә торып искә ала.

25 апрельдә съезд докладларны тыңлап, карарлар кабул итәргә керешә. “Шәригатьтә хатын-кызларның хокуклары” (докладчы Мәрвәрит Туктарова), “Иҗтимагый-сәяси тормышта хатын-кызлар” (Мәрьям Мөштәриева), “Хатын-кызларның гаиләви хәлләре” (Хәтимә Камалова), “Милли мәсьәләләр хакында” (Мәрьям Мөштәриева, Заһидә Бурнашева) докладлар тыңлана. Фикер алышуларда безгә билгеле зыялы ханымнарыбыздан Ләбибә Хөсәения, Зөләйха Рахманкулова, Фатыйма Дәүләткилдеева, Әминә Мөхетдинова, Мәймүнә Шәфигуллина, Рауза Солтангалиева, Фатыйма Лотфия, Илһамия Туктарова һ.б. катнаша. Алар бүгенге көн өчен дә әһәмиятен югалтмаган тәкъдимнәр кертсәләр дә, сүз артык озынга китүдән сакланып, кабул ителгән карарларны гына санап күрсәтик.

Хатын-кыз хокуклары хакында съездның карары түбәндәгечә:

- ир белән хатын-кыз бертигез танылсын;
- хатын-кызларга иҗтимагый-сәяси эшләрдә катнашырга хокук бирелде, димәк сайлауларда да катнаша алалар;
- күп хатынлылык рөхсәт ителмәсен;
- 8 яше тулган һәр балага уку мәҗбүри булсын һәм кызлар өчен урта һәм югары мәктәпләр ачылсын;
- хатыннарга йөзләрен ачып йөрү тыелмасын;
- уку яшенә җитмәгән балалар өчен бакчалар һәм тәрбия йортлары ачылсын;
- шәһәрләрдә һәм авылларда аналарны саклау (охрана материнства) җәмгыятьләре ачылсын.

Карарлар бер тавыштан кабул ителеп, Мәскәү шәһәрендә 1 майда ачылачак Бөтенроссия мөселманнары съездына кую өчен тәкъдим ителә. Әмма карарларны тормышка ашыру өчен хатын-кызларга бөтенләй башка вазгыятьтә, башка җирлектә бик озак көрәшергә туры килә әле.

Съезд ахырында Мәскәүдә булачак съездга Сәлимә Якупова, Заһидә Бурнашева, Диләрә Булгакова, Өммегөлсем Әсфәндиярова, Рауза Солтангалиева, Илһамия Туктарова, Хәдичә Таначева һәм Мәрьям Криницкаялар вәкилә итеп сайланалар.



*Россия мөселман хатын-кызлары съезды. 1917 ел, 20 апрель*

Съезд бик оешкан төстә, матур гына тәмамлана да. “Ябылганнан соң Казан ханымнар җәмгыяте тарафыннан “Сәйяр” труппасының спектакле куелды. Вәкиләләр съездан разый булып киткәнлекләрен белдерделәр, – дип яза Якуб Хәлили. – Бу съезд татар галәмендә зур шатлык һәм өмет тудырды”.

Ни кызганыч, Россиядә килеп чыккан яңа революция илдәге тәртипләрне бөтенләй үзгәртеп җибәреп, күп кенә өметләрне кисүе мәгълүм инде.

## ТАРИХЛАРДА ҖУЕЛМАСЛЫК ЭЗЛӘРЕ БАР

Татар халкының мәгариф тарихына күз салсак, анда гомерләре бик кыска, әмма кылган яхшы гамәлләре озын-озак елларны эченә алган затлы шәхесләр бик күп. Аларның берсе – Казан шәһәренең унынчы мәхәллә мәдрәсәсе имам-хатыйбы һәм мөдәррисе Салихҗан Галиев-Баруди хәзрәт кызы Әминә.



*Әминә Галиева әтисе Салихҗан хәзрәт Галиев-Баруди белән Истанбулда. 1909 ел*

1893 елның иске стиль белән 10 июнендә Казанда туган кыз бала искиткеч күркәм гаилә тәрбиясе ала. Аның бабасы Мөхәммәтҗан Ибнеәмин улы Галиев – Казанның атаклы сәүдәгәре,

1875 елдан башлап утыз елга якын шәһәр Думасы гласные, биш ел буе шәһәр Управасы әгъзасы (1875–1880), Казан шәһәренең Ятимнәр суды һәм сәүдә вәкилләре әгъзасы (1880–1890), сәүдәгәрләр старостасы һәм башка бик күп вазыйфалар башкарган кеше. Болар өстәвенә, берничә дистә ел рәттән Яңа бистәдәге татар зиратының даими попечителе дә булып, аны тәртиптә тоту өчен шактый зур суммада акча биреп барган, караучысыз калган өлкән яшьтәгеләргә ярдәм йөзеннән махсус тәрбия йорты ачкан игелекле зат та ул.

Мөхәммәтҗан Галиев, һичшиксез, күркәм гыйлем иясе булган. Җае туры килгән саен китаплар, кульязмалар сатып ала-ала бай гына китапханә булдырган, үзенең дүрт улын да белемле, мәгърифәтле итәргә тырышкан. Игелекле улларының бары берсе – Газизҗан гына әтисе кебек сәүдәгәр булып киткән. Калган өчесе – Галимҗан, Салихҗан, Габдрахман Бохара, Төркия, Мисыр һәм Гарәбстан мәдрәсәләрендә белем алып, Казан мәхәлләләрендә дин әһелләре булып торганнар, тормышларын Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итүгә багышлаганнар. Араларыннан өлкәне Галимҗан Галиев-Барудига нәселләренең исемен мәңгеләштерү насыйп булганы мәгълүм инде. Ата сүзеннән чыкмаган Галимҗан белән Салихҗанны Мөхәммәтҗан ага өйләнгәндә дә үзе Малмыж шәһәренең I нче гильдия сәүдәгәре Исхак Муса улы Үтәмешевнең кызларына – апалы-сеңелле Бибимаһруй белән Бибинәгыймәгә өйләндерә. Бәхетле никах булгандыр, диясем килә. Маһруй абыстайның иренә якын ярдәмче, аңа һәрчак теләктәш, таяныч булып яшәгәне мәгълүм. Ире Галимҗан киңәше һәм ярдәме белән Казанда аваз методы белән укытыла торган (җәдитчә) кызлар мәктәбен иң беренче булып ачкан абыстай бит ул.

Салихҗан белән Бибинәгыймә биш бала тәрбияләп үстерәләр. Әминә шул бишнең берсе инде. Башлангыч белемне ул җиңгәсе Бибимаһруйның “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе янында урнашкан кызлар мәктәбендә ала. Бибимаһруй вафатыннан соң, мәктәп атаклы мөгаллимә Ләбибә Хөсәения кулында кала. Әминә – аның да сөекле шәкерте. Ата-ана ризалыгын алып, гимназиягә кереп уку теләге булса да, килеп чыккан көтелмәгән хәлләр кыз баланың теләгенә киртә сала. Салихҗан хәзрәт, патша хөкүмәте тарафыннан сәяси гаепләнеп, сөргенгә хөкем ителә.

Инде мәгълүм булганча, XX нче гасыр башында Россия мөселманнарының, бигрәк тә татар халкы өчен иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе – милләт буларак югалудан, ягъни инкыйраздан котылу иде. Мөселманнарның 1905 елның август аенда оешкан "Иттифак әл-мөслимин", ягъни "Мөселман иттифакы" партиясенең төп максаты әнә шул мәсьәләләрне бергәләп чишү булды. Партиянең Үзәк Комитетына сайланган Галимҗан абыйсының төп таянычларыннан берсе Салихҗан булуында һич шик юк. Ул үзе дә партия программасы буенча үткәрелгән җыелышларда катнаша. Архивта сакланган документларда 1905 елның 8 ноябрендә татарның игелекле бае Әхмәт Хөсәенов йортында үткәрелгән җыелышта "Казандагы барлык мәхәлләләрнең муллалары икешәр шәкертне алып килгәннәр иде",[1] – дип күрсәтелә. Һәр эшләре, һәр адымнары полиция күзәтүе астында булган, җаннары кыйналган муллаларны гаепләргә бик зур сәбәп инде бу.

Гаепләнүнең тагын бер сәбәбе шунда – Салихҗан хәзрәт өлкән абыйсы Галимҗан үрнәгендә үз карамагындагы мәхәллә мәдрәсәсендә (ул бу вакытта Касыймия, ягъни Күл буе мәдрәсәсе) эшли, укытуга шактый үзгәрешләр кертә. Мәдрәсәдә тарих, арифметика, география кебек фәннәр укытыла башлый.

Хәзрәт үзе дә, тирән гыйлемле зат буларак, дәрес бирүгә иҗат эше итеп карый, уку-укытуга багышланган методик кулланмалар яза. 1905–1906 елларда үз мәдрәсәсендә шәкертләрнең зур җыелышларын уздыруга юл куя, ул җыеннарда дәүләт җинаятьчесе саналган Гаяз Исхакый революцион чыгышлар ясый. Бу хәл патшага тугрылыклы мәхәллә кешеләренә хәзрәт өстеннән әләк язарга мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә, Салихҗан мулла ярдәмче итеп кенә калдырыла. Әмма үз хәленең авырлыгына карамастан, 1907 елның маенда татар мөгаллимнәре өчен педагогик курслар оештыру эшендә катнаша. Курслар 2 майдан 21 майга кадәр эшли. Анда Казан, Вятка, Пермь, Уфа, Ырынбур, Түбән Новгород һәм башка губерналардан килгән мөгаллимнәр белемнәрен күтәрәләр. Аларга дин белеменнән тыш арифметика, геометрия, география, тарих, педагогика фәннәреннән дәресләр бирелә. Курслар нибары 10 көн эшләп кала. Тиешле рөх-

[1] Татарстан Республикасы дәүләт архивы (ТР ДА). 199 ф. 1 тасв. 771 эш. 17, 20 б.

сәт алмаган дигән сылтау табып, Казан губернаторы Стрижевский курсларны ябу хакында күрсәтмә бирә. Мөгаллимнәр арасында тентү үткәрелә, аларның уку әсбаплары, дәфтәрләре тартып алына, күбесе Казаннан куыла.

Шушы вакыйгалардан соң, Казан муллалары Галимҗан һәм Салихҗан Галиевлар, Габдулла Апанаев һәм сәүдәгәр Габделхәмит Казаков, революцион фирка төзүдә гаепләнеп, Вологда губернасына сөргенгә озатылалар. Казан халкы бу хәлне чын фаҗига итеп кабул итә. 1908 елның 8 нче маенда илдән сөрелгән имамнарны меңнәрчә кеше зар елап озатып кала. Ике баласы берьюлы сөргенгә озатылган Мөхәммәтҗан Галиев олы хәсрәтеннән йөрәге ярылып үлә.

Сүзебез Салихҗан хәзрәт кызы Әминә туташ хакында иде бит әле. Әтисен өзелеп яраткан, чиксез хөрмәт иткән 15 яшьлек Әминә, олыларның хуплап бетермәүләренә дә карамастан, әтисе артыннан Вологдага сөргенгә китә. Әтисенең хәлен бераз җиңеләйтү була аның теләге. Кыз баланың бу адымын каһарманлык дими ни дисең. Безнең буын Себергә сөрелгән декабристларның хатыннарына сокланып үсте. Әтисе артыннан сөргенгә барган изге йөрәкле кыз бала барлыгын без хәтта белмәдек тә. Тарихыбызда без белмәгән мондый сокландыргыч хәлләр бүтән юктыр дип әйтә алмыйбыз бит әле бүген дә. Татарның чын тарихын, затлы, зыялы шәхесләрен белеп үсәргә насыйп булыр микән киләчәк буыннарга? Кадерен белерме икән ул буын үз тарихын?

Россия мөселманнарының бердәм таләбе нәтиҗәсендә, татар язмышының аянычлы бер чоры булса да, шул ук елны хөкүмәт илдән китәргә мәҗбүр ителгәннәргә бераз ташлама ясый, калган вакытларын чит илдә үткәрергә рөхсәт итә. 1908 елның сентябрендә Салихҗан хәзрәткә Истанбулга китәргә мөмкинлек тугач, әтисе белән бергә Әминә дә юлга чыга.

Истанбулга баргач, ул атаклы Шәйхелислам Касыйм хәзрәтнең кызы Хөсния ханымнан бераз хәзерлек дәресләре алып, университет каршында оештырылган “Аналар мәктәбе”нә укырга керә. Бу мәктәпне дә уңышлы тәмамлый. Ниһаять, күптәнге теләге тормышка аша. Ул гали уку йортына – Истанбул университетына укырга керә. Университетта укыганда, гуманитар фәннәрне, бигрәк тә борынгы тарихны яратып өйрәнә, Кубрат хан хәзинәләре белән

кызыксына, туган илгә кайткач, музей ачу уе белән хыяллана. Тик укуын тәмамлый алмый, Балкан сугышы башлангач, Истанбулга юллар ябыла. Каникулга кайткан Әминәгә дә кабат Төркиягә бару мөмкинлеге бетә.

Белемгә омтылу аңа нәселдән мирас булып күчкән, күрәсең. Ул һаман укырга, белем эстәргә тырыша. Казандагы Шумкова гимназиясенә йөреп ашчылык курсларын тәмамлый, мөселман хатын-кызлар өчен дә шундый ук курслар ачу, "Аш пешерүчеләргә киңәшләр" китабын чыгару мәшәкатьләре белән йөри. Атаклы Иж-Бубый мәдрәсәсенә барып, алардагы уку тәртипләрен өйрәнә.

1914 елда Казанда кызлар өчен сәүдә (коммерция) мәктәбе ачылгач, анда дүрт ел буе дин белеме дәресләрен алып бара. Ләбибә Хөсәения мәктәбендә һәм Яңа бистәдәге Кәшшафетдин хәзрәт Тәрҗемани ачкан кызлар мәктәбендә ана телен укытырга да аны чакыралар. Ләбибә Хөсәения мәктәбе нигезендә укытучылар хәзерли торган гали (югары) мәктәп, ягъни дарелмөгаллимат ачарга тырышып йөрүчеләрнең дә иң эшлеклесе Әминә булуы мәгълүм. Аның хакында язылган истәлекләрдә Әминәнең музыкага искиткеч сәләтле, уен коралларында оста итеп уйный белүе хәбәр ителә. Ул китаплар укырга яраткан, үзенең бай китапханәсен булдырган.

Февраль революциясеннән соң оешкан "Мөселман мөгалимнәре җәмгыяте"ндә дә канатланып эшли башлый. Тик татарның саф күңелле, талантлы бу кызының да гомере бик тиз, бары 25 яшендә, 1918 елның апрелендә өзелә.

Вафатына багышлап язылган мәрасимдә аның хакында мондый сүзләр язылган: "Әминә ханым саф күңелле, мөлаем табигатьле, киң холыклы, гали рухлы булып, иптәшләре арасында кадерле урын тота иде. Уку-укыту эшләрен чын мөкатдәс, чын кирәкле бер эш дип иҗтиһад итә, кыз балаларны тәрбияләүгә зур әһәмият бирә. Аларны бик сөеп укыта, укучы кызлар каршында да иң сөекле мөгаллимнәрдән иде. Җеназасы вакытында шәкертләре аңа соңгы сәламнәрен әйтергә җыелдылар, иң кадерле, иң шәфкатьле аналарыннан аерылган кебек, һәммәсе аны егълашып күзәттеләр.

Мәйданда аның белән саубуллашырга килүчеләр бихисап күп иде. Казанда бер укытучының да җеназасына бу кадәр халык җыелганы булмагандыр.

Тәрбияле, киң мәгълүматлы, кадерле иптәшемез Әминә ханымга Алладан рәхмәт сорап, аның туфрагын җиңел, каберен киң, якты, йомшак итәргә, җаны рәхәттә булуын сорап Ходайдан ялварамыз. Сөекле Әминәбезне һәммәбез сагынабыз, аның исемен хөрмәт белән яд итәрмез".

"Кызыл Шәрык", "Укытучы" журналларында басылган бу изге теләкләргә кушылып, кызларыбыз менә Әминә кебек гүзәл шәхесләребездән үрнәк алсыннар иде дигән теләктә калам.

## КЫЗЛАР ЯЗМЫШЫ – МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

Халкыбызның гаять бай тарихлы булуын, ни кызганыч, бары соңгы елларда гына аңлый башладык шул. Тарихыбызның, андагы шәхесләрнең, шул исәптән зыялы кызларыбызның да тормыш юлларын гаять дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуы нинди аяныч нәтиҗәләргә китерде.

XX гасыр башы… Татарның зыялы ирләре Шәрыктан килгән олы гадәтне кайтарып, хатын-кызны нинди биеклеккә куя алганнар. Бу мәкаләмдә тормыш юлларын өйрәнеп, ачып һәм талантларына, тырышлыкларына сокланып, хәйран калып яшәргә мәҗбүр иткән өч бертуган кызлар – Гамбәр, Шәмсекамәр һәм Суфия Коләхмәтовалар хакында язам. Бу кызлар үзләренең илаһи куәтләрен замандашларының сәламәтлеген саклауга багышлаганнар.



*Шәмсекамәр Коләхмәтова. 1903 ел*

Советлар чорында иҗатына зур бәя бирелгән, халык бәхете өчен көрәшүче дип хаклы рәвештә аталып йөргән Гафур Коләхмәтовның кыз туганнары алар. Сабын кайнату остасы дип дан алган Юныс Коләхмәтов һәм Газизә абыстай гаиләсендә 9 бала туа. Газиз, Гафур, Каюм, Муса, Габделмәннан, Мөхәммәтәмин исемле ир балалар (әйтеп үтим, Газиздән башкалары барысы да Татарская учительская школада укыганнар) һәм өч кыз бала. Олысы – Гамбәр, уртанчысы – Шәмсекамәр һәм кечесе – Суфия.

Алар XX йөз башында Пензадан Казанга күчеп киләләр. Башта Юныс олы улы Газиз белән Үтәмишевләрнең Яңа бистәдә урнашкан кечерәк кенә сабын кайнату заводына эшкә урнаша, соңрак гаиләсе дә күченә. Пензадагы тормыш хәлләре ачык түгел, әмма

олы кызы Гамбәрнең һәм өлкәнрәк ир балаларының, Казанга килгәнче үк, заманы өчен яхшы белем алулары ачык билгеле. Шунысы да мәгълүм: кызлар барысы да кул эшләренә бик оста булганнар һәм күңелләреннән моның белән горурланганнар да. Чөнки Казанның иң бай йортларыннан заказлар аларга килгән.

Татарстан дәүләт архивында Гамбәр апаның шәхси эше саклана. Анда аның 1874 елның 21 гыйнварында тууы, белемне йортта, гаиләдә алуы һәм, Казан укытучылар семинариясендә имтихан биреп, укытучы дипломы алуы хакында әйтелгән. Рус, татар, француз телләрендә иркен сөйләшкән кыз баланың шәхси тормышы да язмыш сынауларына шактый бай, нәкъ талантлы кешеләрнеке кебек, гыйбрәтле.

Милләте башкорт дип язылса да, гел Казанда яшәгән морза Шәйхелгаттар Гобәевның офицер улы Мәхмүт Солтан гашыйк була аңа. Гаилә хуҗасы Шәйхелгаттар бу вакытта инде вафат, ә менә тол калган булачак кайнана килененең “сабын кайнатучы хәерче кызы” булуын бер дә теләмәгән. Ул вакытта офицерга мещан сословиесендәгеләр белән никахлашу закон белән тыелган булган. Әмма кызының бәхетле булуын теләгән ата, өяз шәһәре Свияжскига барып, сәүдәгәрлеккә язылуга ирешкән (һичшиксез, ришвәт биреп, Россиядә башкача булмый).

Яшьләр өйләнешәләр, әмма үзләре бик бәхетле булсалар да, кайнанага бу эш ошамаган. Ачуыннан ул хәтта үз баласы өстеннән Петербургка шикаять тә яздырып җибәргән. Шул әләк нигезендә Солтанны Казаннан Сембергә җибәрәләр.

20 нче елларда Казанда яшәгән Зөһрә апа Баимбетова (70–80 елларда Мәскәүгә баргач, аның белән еш очраша идем) Солтан белән Гамбәр хакында болай дип сөйләгән иде. “Солтан үз бәхетенә әнисенең шулай каршы төшүен бик авыр кичерә. Чиксез яраткан Гамбәре белән уртак балалары Равил туа. Ачуыннан ярсыган әнисе генә аларны тынычлыкта калдырмый. Ул язган әләкләр аркасында штабс-капитан дәрәҗәсеннән бөтенләй гади солдат итеп төшерелү куркынычы тугач, Солтан атылып үлә. Бу хәл 1903 елның 31 мартында була һәм ул Сембер зиратына күмелә. Сөекле иренең үлеменнән соң Гамбәр бик нык авырый, улы Равил хакына гына исән кал-

мады микән? Равиле, ялгышмасам, үскәч Башкортстанның беренче сынаучы-очучысы булды дип хәтеремдә калган".

Гамбәр апага кайгысын җиңәргә әтисе йортындагы җылы мөнәсәбәт тә булышкандыр, дип уйлыйм. Баласын тәрбияләргә дә әнисе, туганнары ярдәмгә килә. Үзе, кайгысын җиңеп, 1905 елда Казан университеты каршында ачылган акушерлар хәзерли торган институтка керә һәм табиб дипломы ала[1].

Бәхетенә очраган Солтаны белән шулай тигез, матур яшәргә язмаган Гамбәр апага. Гаиләсендә дә, дус-ишләре арасында да чиксез хөрмәт тоеп үскән кыз баланың соңгы тормышы хакында мәгълүматым юк. Әмма Уфага китеп, шунда яшәгәндер дип уйларга нигезем бар. Чөнки аны яраткан каен сеңелләре Рокыя белән Өммегөлсем – икесе дә табибәләр, Уфада гомер иткәннәр. Равилне дә бергәләп тәрбияләгәннәрдер дип уйлыйм. Рокыя апа Совет хакимияте елларында хезмәте өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән, СССР Югары Советына депутат та булып сайлана алган әле.



*Гамбәр Коләхмәтова. 1905 ел*

Шәмсекамәр – кызлар арасында иң йомшак күңеллесе, ашсу әзерләгәндә дә, йорт эшләрендә дә әнисенең беренче ярдәмчесе. Энеләре дә, йомышлары булса, аңа әйткәннәр, ул һәркемгә яхшылыктан башканы теләмәгән дә, белмәгән дә.

Татарның зыялы гаиләләрендә урнашкан гадәт буенча, этиәнигә каршы сүз әйтергә кыймаган кыз баланы кияүгә этисе бирә. Белмим, сәүдәгәр гаиләсенә бирсәм, кызымны бәхетле итәм дип уйлады микән Юныс ага. Әмма аракы эчәргә бик яраткан, тупас мөгамәләле бер егеткә көчләп биргән ул кызын. Шәмсекамәрнең

[1] ТР ДА. 977 ф. 563 тасв. 6 эш. 2–3, 7 б.

тормышы мәхшәргә әверелгән. Көн саен исерек иренә ничек тә ярарга белмәгән ул. Баласы тугач, бәлки арабыз төзәлер, бәлки яшәп китәрбез дип өметләнсә дә, барып чыкмый. Ире исереп кайткач, яңа туган баласын да тартып алып идәнгә ыргыта. Бәхетенә, йомшак юрганга төрелгән балага зыян килми. Кызы Гайшә Габделхәмит кызы Шәрипова үсеп җиткәч, күренекле тәрҗемәче, язучы булып танычла. Аның “Семья Гафура” дигән китабын, бәлки, әле өлкән буын укучылар хәтерлидер дә.

Ул вакытта хатынның ирдән аерылып китүе гаеп эш саналган әле. Кайнана-кайнаталарының елап-елап үгетләүләренә карамастан, Шәмсекамәр ире йортыннан китә. Әмма баланы тәрбиялисе, үстерәсе бар бит. Шул вакыт аңа абыйсы Гафурның дусты, табиб Искәндәр Котлыбаев фельдшерлар курсына керергә булыша. Ходай биргән чиксез сәләте аңа бу һөнәрне дә бик тиз үзләштерергә ярдәм итә. Ул чын табибә булып җитешә. Казан хәтле Казанда хатын-кыз табибәләр бармак белән генә санарлык заман бит әле бу. Татар хатыннары врачларга хәтта ирләре белән бергә дә барып күренергә оялганнар. Шәмсекамәргә шуңа күрә эш җитәрлек була. Шулай үз көнен үзе күрә ул, кызын тәрбияли. Халык белән шулай аралашу кыюлык та бирә аңа. Ул хәтта 1907 елның 11 апрелендә хатын-кызлар өчен куелган спектакльдә дә катнаша.

Бу тамашаның тарихы болай була. Учительская школаны тәмамлап, хәзерге Биектау районының Ямаширмә авылында укытучы булып эшләгән энесе Каюм ярдәм сорап килә. Ул бу елны ашлык уңмавын, күп кенә гаиләләрнең ачыга башлауларын сөйли. “Балалар бик ачыга” дип кайгыра. Шул вакыт Габдулла Кариев хатын-кызлар өчен спектакль куярга тәкъдим итә. “Килүчеләр күп булыр, чөнки татар хатыннарының да тамаша күрәселәре килә бит, тик уйнаучылар да хатын-кызлар гына булсын”, – ди. Уйнар өчен Гаяз Исхакыйның “Өч хатын белән тормыш” дигән әсәре алына. Казан тарихында беренче тапкыр булган бу тамашага чынлап та хатын-кызлар күп килә. Аларны ирләре озатып куя, әмма үзләрен кертмәгәнгә ачулары да бик килә. 1907 елның 11 апрелендә куелган бу спектакль зур уңыш казана. Мыеклар ябыштырып ирләр ролен уйнаган Шәмсекамәр дә, сеңлесе Суфия да үзләрен сәләтле артистка итеп танытаалар. Хаклы рәвештә татар театрының атасы саналган

Габдулла Кариев аларга рәхмәт әйтә. Заманы өчен шактый зур акча булган 67 сумга азык-төлек алып, Ямаширмә авылына җибәрәләр.

1889 елда җиденче бала булып дөньяга килгән Суфия Коләхмәтова хакында романнар язып булыр иде. Тик язмам бик озынга китте кебек, кыскача гына язарга мәҗбүр булам.



*Суфия Коләхмәтова. 1905 ел*

Ул үсеп җиткәндә, әтисе һәм олы абыйлары Газиз дә үлеп китәләр. Гаиләдәге 5 баланы тәрбияләү Гафур өстендә кала. Белем аласы, апалары кебек табибә буласы килгән Суфияны укытырга гаиләнең матди хәле авырая. Яшьтән үк эшчәнлеге һәм зирәклеге белән аерылып торган кыз, гаиләгә ярдәм итү ниятеннән, Пороховой бистәсендәге абыйсы укыткан мәктәпкә каравылчы булып эшкә урнаша. Ул мичкә ягарга да, мәктәпнең идәннәрен дә юарга тиеш була. Утын яру, ишек алларын себерүгә энеләре булышкач, Суфия Гафур абыйсының дәресләренә кереп утырырга да мөмкинлек ала. Үзлегеннән укып, 3 нче ирләр гимназиясендә өлгергәнлек аттестатына бик яхшы билгеләренә имтихан да бирә.

Ә 1908 елда ул Петербургның Хатын-кызлар югары медицина курсларына кабул ителә. Әмма Суфияга 5 ел буе үзәк шәһәрдә түләүле уку йортында укыр өчен кирәкле акча табу мәсьәләсе килеп баса. Аллаһы Тәгалә талантлы, тырыш кызга бу юлы да ярдәм итә дими, ни дисең. Беренче курста күренекле язучыбыз Фатыйх Әмирхан бирә Суфияга акчаны. Икенче елны бөек шагыйребез Габдулла Тукай булыша. Шулай укыр өчен дә, квартира өчен дә, гомумән, уку һәм яшәү өчен мөмкинлек туа. Соңгы курсларда уку өчен кирәкле акчаны аңа булачак ире релислам Агиев табып бирә. Бу вакытта Фәхрелислам үзе дә Казанда укып йөри. Әмма ул

бәхетлерәк, аңа укыр өчен туганы акча кызганмый. Менә шул акчаларны ул Суфияга җибәрә.

1914 елда ул дипломлы табибә булып Казанга кайта. Бу вакытта I Бөтендөнья сугышы башланып китә. Казанга бик күп яралыларны кайтара башлыйлар. Казанның могътәбәр байлары, дин әһелләре Галимҗан Баруди һәм Габдулла Апанаевлар тырышлыгы белән, мөселман яралылары өчен махсус лазарет ачалар. Менә шул лазаретка киләчәктә зур галим булып танылачак Әбүбәкер Терегулов белән Суфия Агиева табиблар итеп чакырылалар.



*Фәхрелислам Агиев. 1908 ел*

Тик кеше бәхете озакка барамыни. Күп тә үтми, Ф.Агиевка “Бишек җыры” исемле әсәр язганы өчен “бик кыска вакытта Казаннан китәргә” кушыла. Суфия белән Фәхрелислам (берсе табибә, икенчесе укытучы) Пенза өлкәсенең Юнә авылына китәргә мәҗбүр булалар. Әйбәт кенә яшәп китәләр. 1916 елда алар янына инде сәламәтлеге бөтенләй начарланган Гафур да килә. Никадәр тәрбияләсәләр дә, ярдәме тими. Инде мәгълүм булганча, татарның олуг затларыннан саналырга тиешле Гафур Коләхмәтов 1918 елның 1 апрелендә (иске стиль белән) сеңлесе һәм кияве кулында җан бирә.

Фәхрелисламы Сталин палачлары кулыннан корбан булгач, Суфия үзе дә кулга алынып концлагерьда газап чигә. Азат ителгәч, Алма-Атага китә һәм сеңлесе Гайшә белән соңгы көннәренә кадәр шунда яши. Кайчан җир куенына кергәнен төгәл белә алмадым, тик 1971 елда, 82 яшендә истәлекләр язганы мәгълүм.

Менә шулай, гомерем буе мине сокландырган, тормышымның авыр сәгатьләрендә язмышларын укып гыйбрәт алырга этәргән меңнәрчә татар кызлары хакында тагын бер язмам бу. Шунысы

куанычлы, XX йөз башында гыйлем белән талантның кадерен белгән, халык аңын яктырту өчен хәләл малын, көчен кызганмаган шәфкатьле затларыбыз ярдәмендә алар гыйлем-мәгърифәт иясе булганнар. Бу шәфкатьлелекне тормышның хәзерге бизмәне белән үлчәп аңлатып булмый.

Элегрәк укымышлы кызлар хакында “И, аларның аталары бай булган” дип сөйләнсә, сабын кайнатучы кызлары – Гамбәр, Шәмсәкамәр, Суфияларның үз алдына куйган максатларына ирешүдә үткән юлларын каһарманлык дими, ни дисең? Бөтен татар милләтенә хас һәм бергә берләштереп торган сыйфатлар ич болар.

# ТУКАЙ ДАИРӘСЕНДӘ – МӘГЪРИФӘТЧЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР

Габдулла Тукай – бөек халыкның бөек улы, үз улы. Тирән тамырлары белән халкыбызның азатлык өчен көрәшенә чорналган иҗатында ул татар хезмәт ияләренең һәм милли зыялыларының иң яхшы өмет һәм омтылышларын гәүдәләндерде. Аның хатын-кызларга, аналарга дан җырлаган, кешеләрнең акылын һәм хисен әсир итә алган әсәрләре кемнәргә генә мәгълүм түгел икән! Шагыйрь күңеленең мондый гүзәллеккә, мондый югарылыкка ирешүендә, бәлки, аның үзенә таныш булган, аралашкан, хөрмәткә лаек хатын-кызлар да сәбәп булгандыр.

Сүзебезне булачак шагыйрьне дөньяга тудырган, күкрәк сөтен имезеп яшәү көче биргән һәм, иң мөһиме, баласына шагыйрьлек таланты бүләк иткән изге ана – Мәмдүдәдән башлыйк. Әйе, Тукайга иҗади сәләт, шагыйрьлек таланты әнисеннән күчкән. Чөнки Мәмдүдә апа кирәк чакта шигырь белән җавап бирә торган, сүзгә оста хатын булган.

Ни кызганыч, Мәмдүдәнең язмышы бик күп татар хатыннары кебек үк фаҗига белән тулы. Мәгълүм булганча, башта 19 яшьлек кызны 43 яшьлек Мөхәммәтгарифка кияүгә бирәләр. Бу никахтан 1886 елның 26 апрелендә уллары Габдулла (тулы исеме Габдуллаҗан) туа. Шул ук елның 29 августында Гариф мулла вафат була. Иренең үлеменнән соң, Мәмдүдә белән аның нәни улына Кушлавычта урын бетә, алар Өчилегә – Зиннәтулла хәзрәт янына кайталар. Тик биредә дә Мәмдүдәнең эчәр суы, ашыйсы ризыгы аз булган. 1888 елның 22 декабрендә этисе аны, ягъни 23 яшьлек Мәмдүдәне, хәзерге Балтач районы Сасна пучинкәсенең 69 яшьлек Мөхәммәтшакир исемле мулласына бирә.

Шакир мулла яшь һәм чибәр Мәмдүдәдән бик көнләшкән, еш кына кыйный торган булган. Шул кыйналулардан бу бәхетсез җан 1890 елның гыйнварында үле бала таба һәм үзе дә вафат була.

Үләр алдыннан Мәмдүдә үз янына Габдулланы китерүләрен сорый. Улы килгәч: “Әй, балам, мин сине үстерә алмадым, бәхил

бул”, – дип Габдулланы әкрен генә сөя. Озак та үтми, газапланып җан бирә.

*Күз яшьләрен дә кипмичә, егълап вафат булган Әни!*
*Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше!?*
*Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,*
*Һәр ишектән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы.*
*Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабереңташы*
*Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы…*

Шагыйрьнең иң эчке дөньясын ачып, җаннарны тетрәткән бу шигыре беренче мәртәбә 1914 елның 29 ноябрендә “Вакыт” газетасында басылып чыккан.

Нәни Габдулланы башлап гыйлем дөньясына алып кергән Маһруй абыстайны искә алып китү дә урынлы булыр. Уртача буйлы, сабыр табигатьле, җайлы гына сөйләшә торган Маһруй абыстай Габдулла күңеленә дә җылы хисләр белән кереп калган. Солдатка каралырга кайткач, Тукай аның янына күрешергә күчтәнәчләр белән килгән һәм саубуллашканда: “Мин хәзер китаплар язам. Сезгә дә китапларымны җибәрермен әле”, – дигән. “Күпме какканны вә сукканны күргән” ятим йөрәк шәфкатьле җаннарны үз итмичә, аларның тормышларына битараф булып, кайгы-шатлыкларын бүлешмичә яши аламы соң?!.

Инде мәгълүм булганча, XIX йөзнең соңгы яртысында аеруча үсеп киткән мәгърифәтчелек хәрәкәте татар хатын-кызларының “уянуы”на да зур этәргеч биргән. Алар, кулларына каләм алып, әдәбият мәйданына чыга башлаган. Алай гына да түгел, әдәбият һәм мәгърифәт юлында җиң сызганып эшкә керешүчеләр артканнан-арта барган. Габдулла Тукай – хатын-кызларның мондый тәрәккыятькә аяк басуларын чын күңелдән хуплаучыларның берсе. “Фикер” газетасында (1905 елның ноябрендә чыга башлый) Фатыйма Госман кызы Коләхмәтева хакында мәкалә басылып чыккан. Татар халкының күренекле әдибе Гафур Коләхмәтевнең ерак туганы булган бу сәләтле кыз Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә мөгаллимәлеккә имтихан бирә. Мәкаләдә имтихан алучыларның Уральск каласында бик билгеле, укымышлы затлар булуы, шулай булса да, кыз баланың, каушап калмыйча, барлык сорауларга да ачык җавап бирүе хакында әйтелә.



*Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская*

“Фикер” газетасы хатын-кызлар язган мәкаләләргә дә ешрак урын бирә башлаган. Ачинск шәһәреннән мөгаллимә Фәрханә Алушева (1886–1958) – иң актив язучыларның берсе. Ул үз мәкаләләрендә хатын-кызларны ачыктан-ачык азатлык өчен көрәшкә чакырып язган.

XIX йөзнең ахыры – XX йөзнең башы – татар яшьләренең иҗтимагый-сәяси активлыгы күтәрелү, рухи җанлылыгы көчәю чоры да. Әлеге хәрәкәттән татар кызлары да читтә калмый. Аларның күбесе дөньяви фәннәр укытылган мәдрәсәләргә, рус кызлары өчен ачылган уку йортларына кереп укый башлый, хәтта югары уку йортларын тәмамлаучылар да күренә. Рус мәктәпләрендә укучы яшьләрнең мәдәни хәрәкәте шактый киң төс ала, һәм ул 1903–1904 елларда татар шәкертләре арасында барган ислах хәрәкәте белән янәшә бара.

1907 елның көзендә Тукай Уральскидан Казанга күчеп килә. Шагыйрь иҗатында бу вакыйганың зур өметләр, тирән уй-кичерешләр белән бәйле булуы күренә. Казанга килүенең беренче көннәреннән үк, Тукай үзенә фикердәш һәм ышанычлы дусларны табарга тырыша. Тиз арада ул Х.Ямашев, Г.Коләхмәтев, Г.Камал, Ф.Әмирхан һ.б. алдынгы карашлы зыялылар белән якыннан аралашып китә. “Әл-Ислах” газетасы тирәсендәге әдәби көчләр – ислахчы яшьләр арасында көннәрен үткәрә.

Тукай үз заманындагы алдынгы фикерле хатын-кызлар белән дә аралашып яшәгән. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел. Бу хакта шагыйрь хакында язылган истәлекләрдән дә укып беләбез. Шагыйрьнең замандашы нашир Тимерша Соловьевның улы Фоат Саллави язган сүзләр моны раслый: “Без “Болгар”дагы Тукай абый яшәгән бүлмәнең каршысындагы номерда тора идек… Еш кына Тукай янына … Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Болгарская, Хөсәен Ямашев белән Хәдичә апа, китап нашире Шиһаб Әхмәрев белән хатыны Әминә Әхмәрева, әниемнең кече сеңлесе

Закирә апа белән ире журналист Борһан Шәрәф […] киләләр иде. Тукайның хәлен белешергә, татар кызларыннан беренче булып, гимназия тәмамлаган апалы-сеңелле Әминә, Мәдинә Терегуловалар һәм Габитовалар (Зәйнәп, Рабига – *Т.Б.*) да килә иде. “Шәрык” клубында, “Яңа клуб”та, “Эрмитаж”ның җәйге театрында, Панаев бакчасында әдәби-музыкаль кичәләр оештыруда җиң сызганып йөрүче Гөлсем Камалова, Гайшә Богданова, Әминә Мөхетдинова, Заһирә Әхмәрева, татар кызларыннан беренчеләрдән булып югары белем алган Мәрьям Акимбетова һәм соңыннан гражданнар сугышында катнашкан һәм икесе дә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән апалы-сеңелле Мәрьям, Гайшә Саиновалар (Мулланур Вахитовның туганнан-туган сеңелләре) – болар барысы да Тукайны олылаучылар, килеп, даими рәвештә аның хәлен белешеп торучылар иде”.

Исемнәре телгә алынган хөрмәтле затларның күбесе әдәби һәм мәдәни тарихыбызны белгән укучыларга таныштыр дип беләм. Шулай да кайберләре хакында кыскача гына әйтеп үтәсем килә.

Рабига Шәрәфетдин кызы Габитова (1989–1966). Әтисе Кытайның Син-Цзян өлкәсендә Голжа шәһәрендәге Россия илчелегендә озак еллар хезмәт иткән; үзе укыган кеше булып, күп кенә көнчыгыш телләрендә сөйләшә алган. Ул вафат булгач, гаиләсе Казанга кайтып төпләнгән. Кызлары Зәйнәп һәм Рабига – “Шимбә” түгәрәген оештыручылар. Рабига 1906 елда Казанда ачылган хатын-кызларның югары курсларына укырга керә. Ф.Әмирханның истәлекләрендә аның әдәби кичәләрдә, спектакльләрдә катнашуы, анда Габдулла Тукаев шигырьләрен укуы хакында әйтелә. Бу хакта “Йолдыз” газетасында да хәбәрләр басылган. Ул сәхнәгә Тарханова тәхәллүсе белән чыккан. Рус-япон сугышында (1904) һәлак булган сөйгәненә биргән вәгъдәсенә тугры калып, гомере буе ялгыз яшәгән. Укытучы булып эшләгән. Янгын вакытында укучы баланы коткарырга теләп утка кергән. Баланы коткарган, әмма, ни аяныч, үзе алган яраларыннан үлгән.

Сәхибҗамал Гыйззәтулла кызы (1885–1974) – беренче татар хатын-кыз артисты. Сәхнә псевдонимы Волжская. Сәхнә эшчәнлеген “Сәйяр” труппасында 1907 елда башлый. Татарстанның атка-

занган артисты (1926). Шагыйрь аның гүзәл эшчәнлеген шигъри юллар белән мәңгеләштерә:

*Күр, ничек иртә кояш чыкса, җиһанда нур тула;*
*Һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззәтуллина.*
*Бу икәүгә тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:*
*Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә.*

Зәйнәп Хәсәни (1887–1967) – үз гомерендә татарның игелекле байларыннан саналган, милләте өчен хәләл акчасына 13 мәчет һәм 7 мәдрәсә салып калдырган Ногман хаҗи Габделкәримов кызы. “Халидия” мәдрәсәсен тәмамлаган. Әтисе өй укытучысы яллап, аны рус, француз телләренә, музыкага өйрәттергән. Өйләрендә зур гына китапханә булып, анда татарча, төрекчә китаплар белән бергә, рус һәм Европа халыкларының классик әдәбиятларын да табарга мөмкин булган.

Үсеп буйга җиткәч, Зәйнәп Сибгатулла хаҗи улы Әхмәтгәрәй Хәсәнигә (1883–1933) кияүгә чыккан. Әхмәтгәрәй югары белемле – рус, төрек, француз, гарәп телләрен яхшы белгән. Язучылык, тәрҗемәчелек белән дә шөгыльләнгән. Ул – Тукайның иң якын дусларының берсе. Ф.Әмирхан, Г.Гобәйдуллин, Г.Тукай һәм Г.Коләхмәтев 1912 елда Әхмәтгәрәйне әдәби журнал чыгарырга күндерәләр. Журналны чыгару өчен чыгымнарны үзенә бирнә итеп бирелгән акчадан Зәйнәп ханым түләгән.

Габдулла Тукай журнал өчен махсус шигырь язган һәм ул шигырь 1912 елның 15 декабрендә беренче санның тышлык битендә басылып чыккан.

*Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән,*
*Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге нам белән,* –

ди шагыйрь һәм татар яшьләренең 1905–1907 еллардагы эшчәнлегенә тарихи бәя бирә.

Зәйнәп Хәсәни – Габдулла Тукай хөрмәт иткән зыялы хатын-кызларның берсе. Шагыйрь журналның җаваплы сәркатибе булган Зәйнәп ханым белән еш очрашып, фикер алышып яшәгән. Аның соңгы көннәре дә Хәсәниләр белән бәйле. Вафаты алдыннан соңгы хатны да ул Зәйнәпкә яза: “8 нче санга бар кадеремне җибәрдем. Беренче корректурасын үземә күрсәтсәгез икән”, – ди. Бу хат 1913 елның 28 мартында язылган.



*Мәһруй Мозаффария*

Күпме кешегә изгелек эшләгән, репрессия елларында һәлак булган Әхмәтгәрәенең, 5 баласының үлемен кичергән бу ханым, үзенә куркыныч янаган вакытларда да, хаксызга җәберләнгән дистәләрчә әдәбиятчыларыбызның фотоларын, кулъязмаларын саклап калган. Ф.Әмирхан белән Г.Тукайның, Хәсәниләр дачасына кунакка барулары хакында Ф.Әмирхан истәлекләреннән дә укырга мөмкин.

Тукай даирәсендәге мәгърифәтче хатын-кызларыбызны искә алганда, Фатыйха ала Аитованы (1866–1942) онытырга хакыбыз юк. Үзенә бирелгән бирнә акчасына башта – дүрт, соңрак сигез сыйныфлы кызлар мәктәбе, мәктәп янында читтән килеп укучылар өчен – пансион, ә 1916 елда татар кызлар гимназиясе ачкан, мәгариф тарихында тиңдәшсез кеше ул Фатыйха ханым. Аның олы улы Исмәгыйль Габдулла Тукай, Фатыйх һәм Ибраһим Әмирханнар белән якын дус булган. Әнә шулар аша Фатыйха апа Тукай иҗаты белән якыннан танышкан. Ф.Аитова мәктәбен тәмамлаучыларның истәлекләренә караганда, Г.Тукай шигырьләрен мәктәптә укучылар бик яхшы белгән. “Рокыя апа Мөштәриева безгә җыр өйрәтә, – дип яза Газизә Әхмәтова. – Тавышы бик матур. Ул безгә шагыйребез Габдулла Тукай турында сөйли, аның шигырьләрен укый җырлап күрсәтә. Аннан бергәләп “И туган тел”не җырлыйбыз”.

Фатыйха Аитова мәктәбе турында укучысы Рокыя Габдрахманова истәлеге дә игътибарга лаек. “Беркөн безнең сыйныфка” Фатыйха апа керде дә: “Мәшһүр шагыйребез Габдулла әфәнде Тукаев бик каты авыру хәлдә, Клячкин шифаханәсендә ята. Хәзер укучылар арасыннан иң алдынгылар аның янына барыр”, – диде. – Безнең кызлар арасыннан дүрт кызны сайлап алды, шунда мин дә

эләктем… Г.Тукай үлгәч, аның җеназасы үткәрелгән мәйданга Аитова мәктәбе кызлары килеп тезелгәннәр, башка мәктәптә укучыларны да шуларга куштылар”.

Габдулла Тукайның хатын-кызлар мәгарифен олы йөрәгенә никадәр якын алганлыгын, бу эштә һәртөрле ярдәмне күрсәтергә әзер торуын раслаучы бер фактны язмыйча булмый. Аның, инде әйтеп киткәнчә, якын дусты Гафур Коләхмәтевнең бертуган сеңлесе Суфия (1890–1972) 1908 елда ирләр гимназиясендә өлгергәнлек аттестатына имтихан бирә. Ул Петербургтагы Югары медицина курсларында (курслар институт программасы белән эшли) уку турында хыяллана, әмма акчасы булмый. Туганы Гафур да бу вакытта матди яктан авыр яшәгәнлектән булыша алмый. Суфияга I курста уку өчен Ф.Әмирхан ярдәм итә. Икенче елда бу ярдәм Тукай белән бергә оештырыла. Суфия 1914 елда Казанга югары белемне табибә булып кайта.

Кызларга белем алу, алар өчен дөньяви мәктәпләр ачу зарурлыгы хакында Тукайның уз иҗатында күпме язганлыгын искәртеп китү дә артык булмас.

Гомере буе Тукайны хөрмәт итеп яшәп, шагыйрьнең соңгы сәгатьләрендә янына барып йөргән, хәлен белеп торган шәфкатьле ханым – атаклы мөгаллимә, шагыйрә Мәһруй Габделвәли кызы Мозаффария (1873–1945). Ул элеккеге Казан губернасы Тәтеш өязе Олы Торма авылында туган. Мәһруйның әтисе – мулла, ә әнисе Габдулла Тукайның Уральскидагы остазы Мотыйгулла хәзрәтнең апасы булган. Ул әти-әнисеннән заманы өчен яхшы гына гыйлем-тәрбия алган һәм төрек, фарсы, гарәп телләрен өйрәнгән. 1891 елдан туган авылында кыз балалар укыта башлаган. Әтисе ихтыяры белән 18 яшьлек кыз, үзеннән 40 яшь чамасы өлкән Хуҗаәхмәт муллага кияүгә чыгып, Казанга килгән. Торган йортлары “Болгар” номерларының күршесендә булган.

Мәһруй үз заманының алдынгы карашлы кешеләре белән аралашкан, “Әл-ислах” газетасына да язышкан. Үз истәлекләрендә ул: “Мин тормыштан артка калмаска тырыштым. Беренчеләрдән булып, чапанны ташладым һәм 1901 елдан алып матбугат белән таныша башладым. “Тәрҗеман” газетасын алдырам. Үзем дә газета-журналарга язышa башладым”, – дип яза.

М.Мозаффария 1901–1917 елларда Хәдичә Әхмәрованың татар кызлары өчен фәннәрне рус телендә укыта торган мәктәбендә һәм Фатыйха Аитова ачкан кызлар мәктәбендә дә татар теле укыткан. Татар кызларының яңалыкка, мәдәнияткә, ирекле тормышка омтылышларын чагылдырырга ярдәм итеп килгән.



*Зәйнәп Хәсәни*

“Әл-ислах” газетасын чыгаруда якыннан катнашкан Г.Тукай Маһруй Мозаффариянең “Мәшһүр хатыннар” дигән шигырен үзе редакцияли. Шагыйрь хатын-кызлардан шагыйрәләр үсеп килүенә куана. Шигырь газетаның 1907 елгы 1 декабрь санында басылып чыккан.

Шагыйрәнең тормыш юлын җентекләп язып тормастан, (укучыларның күбесенә таныштыр дип уйлыйм) аның һаман укытучылык, язучылык эшендә, балалар арасында гомер үткәрүен генә әйтәсе килә. Маһруй Мозаффариянең улы – атаклы композитор Мансур Мозаффаров, кызы Мәхмүдә – Фатыйха Аитова мәктәбендә мөгаллимә, ә Мәхмүдәнең ире – Тукайның якын дусты, китап ширкәтен оештыручы, журналист Әхмәт Урманчиев. Тукайның Урманчиевлар гаиләсе белән аралашып яшәве хакында истәлекләр шактый.

Сүзебез Маһруй Мозаффария хакында иде бит әле. Маһруй апа 1911 елның 24 августында – Кадер кичәсе көнне укучы кызлары белән әдәбият кичәсе үткәрергә тели һәм Тукайдан балалар өчен берәр шигырь язуын үтенә. Шагыйрь шунда ук “Бу кадер кич – елда бер кич, Барча кичләр изгесе”, дип башланган шигырен язып бирә. Ул шигырь 1928 елга кадәр сакланган һәм соңыннан архивка тапшырылган.

1913 елның 31 мартында Маһруй Г.Тукай белән күрешү, хәлен белү өчен Клячкин шифаханәсенә бара. Тукай аны күргәч, бик шатлана, алып килгән катыгын да яратып эчә. Маңгаена чыккан салкын тирләрен Маһруй ханым сөлге белән сөртеп алгач, сулышын бүләбүлә: “Рәхмәт, Маһруй ханым, җаным рәхәт тапты”, – дип, аңа соңгы сүзләрен әйтә.

Маһруй ханым шагыйрьнең үлеме хакында 1913 елда “Мәктәп” журналында язып чыга. Анда мондый юллар бар: “Аның аз гыйбарәле, күп мәгънәле хатын-кыз галәменә даир булган берничә шигыре безнең йөрәгебезгә ялкын кебек тәэсир итте, безне кузгатты. Безнең башкалар кебек хокуклы инсан идегебезне үзебезгә аңлатты, хатыннар авызыннан хокук җырын җырлата башлады. Шул шигырьләр тәэсире илә безнең сүнгән хиссиятебез баш күтәрде, балкыды. Инде ул янар, мәңгегә сүнмәс, шуның илә бергә безнең шагыйребез дә яшәр. Аның җисме үлсә дә, рухы мәңге-мәңге терек булыр. Без яшәрбез, милләт яшәр, вә милләт илә берлектә ул да яшәр!”

Шагыйрәбезнең югары бәясен тарих раслады. Боларга өстәп, шуны да әйтәсем килә: Маһруй ханым Г.Тукайның кара савытын, китапларын һәм кәрзинен кадерләп саклаган. 1945 елда, вафат буласын сизгәндәй, аларны улы Мансурга биргән. Мансур ага Мозаффаров, әнисенең әманәтен үтәп, бу кадерле истәлекләрне СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына тапшырган.

Кайбер истәлекләрдә Г.Тукай хакында: “Хатын-кызлар белән аралашырга яратмый иде”, дигән сүзләрне укырга туры килә. Бу сүзләр белән килешеп бетәсем килми. Ул – яшь, өйләнмәгән кеше. Шуңа күрә кызлардан оялу – әхлагы иманлы яшьләр өчен бик табигый хәл. Ә шагыйребезнең матур әхлагы хатын-кызларга булган олы хөрмәтендә аеруча ачык чагыла.

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ГҮЗӘЛ ЭНҖЕСЕ ФАТЫЙМА ДӘҮЛӘТКИЛДЕЕВА

Татар халкының гыйлем-мәгърифәт тарихына күз салсак, күпме талантлы шәхесләребезне, аларның милләтебез хакына кылган гамәлләрен белмичә, инде онытыла язган шәхесләребез бик күп әле. Әмма хәзерге буыннарның ул зыялыларыбызның азмы-күпме билгеле булганнарыннан да һаман ераклаша баруы, аларның гыйбрәтле язмышлары белән кызыксынмауларын белү тагын да аянычрак хәл икән.

Мин, XIX йөз ахыры – XX йөз башында яшәгән һәм милләтебезгә игелекле гамәлләр күрсәткән хатын-кызларыбыз хакында уйлап, искә төшергәндә шундый фикергә киләм: нинди генә дәрәҗәләргә ирешсәк тә, без алар янында бик кечкенә икәнбез, аларга безнең кул җитәрлек түгел икән. Намус, әхлак, сафлык, вөҗдан мәсьәләләрендә бигрәк тә.



*Фатыйма Дәүләткилдеева. Мәскәү, 1930 ел*

Шундый бөек затларыбызның берсе – Фатыйма Дәүләткилдеева хакында язасым килде. Мәгариф өлкәсендә гел югары үрләргә омтылган, татар кызлары арасында беренчеләрдән булып фән дөньясына аяк баскан кыз ул.

1911 елда Казан университеты каршында ачылган Хатын-кызлар югары курсларына кабул ителгән документында аның хакында “Девлеткильдеева Фатима Сеид-Оскаровна – дочь князя, магометанского вероисповедания, родилась 18 апреля 1886 года” дип язылган. Алар Уфа өязенең Күгел (Марьино) авылында яшәгәннәр. Дәүләткилдеевларның тарихта

XVI йөздән билгеле булуларын, Касыйм, Темников, Кадом өязләрендәге зур җирбиләүчеләрдән саналганлыкларын әйтеп үтсәк тә артык булмас төсле. Балаларын өйләндергәндә, кияүгә биргәндә күбрәк татар морзалары Еникеевлар, Кугушевлар белән аралашырга тырышканнар икән.

Фатыймага 8 яшь тулганда әтисе үлеп китә. Ни сәбәптәндер, әниләре Фатыйма белән бергә олы кызын да Уфада Хәйрия җәмгыяте оештырган приютка (ятим балалар йортына) бирә. Укуда искиткеч сәләтле тырыш кыз Уфада ачылган Мариинск (2 еллык), Казандагы Ряхина гимназияләрендә белем ала. Гимназияне тәмамлагач, Уфа ир балалар гимназиясендә имтихан биреп, "Рус булмаган мәктәпләрдә укытучы булып эшли ала" дигән шәһадәтнамә ала. Октябрьгә кадәр рус милләтеннән булмаган укытучыларга рус мәктәпләрендә укытырга рөхсәт ителмәгән. Мондый рөхсәтне татар кызы Сара Шакулова 1913 елда Парижда Сорбонна университетын тәмамлап кайткач та ала алмаганы мәгълүм инде.

Гимназияләрдә иң яхшы укучылардан саналган Фатыйма шулай "дипломлы мөгаллимә" була. 1903 елда ул, кардәше Суфия Җантурина ачкан Килем авылындагы кызлар мәктәбендә рус теле һәм дөньяви фәннәр укыта башлый. Мәгарифне иман эше итеп санаган мөгаллимә биредә кызларга рус теле белән беррәттән татар, гарәп телләреннән дә, география, тарих, математика, табигать фәннәреннән дә укыта. Кызларга әдәплелек, кул эшләре, бакчачылык, йортны алып бару кебек иң кирәкле мәгълүматларны да бирә. Көнкүрештә йомшак мөгамәләле, тиз аралашучан, киң һәм кече күңелле Фатыйма бик тиз кыз балаларның иң сөекле укытучысына әйләнә. Бу вакытта аңа халык тормыш-көнкүрешенең авыр социаль һәм иҗтимагый сәбәпләрен аңлауга байтак мөмкинлекләр ачыла. Шуңа күрәдер дә 1905 елдан соң сизелерлек җанланып киткән татар хатын-кызлар хәрәкәтенә нык якыная. Ул газета-журналларда Көнбатыш һәм рус хатын-кызларының тигез хокук өчен көрәшләре хакында язылган хәбәрләрне укый. Милләттәшләре арасында да шундый хәрәкәтне киңрәк җәелдерергә хыяллана. Үзенең дә тагын да зуррак белем аласы, хәтта фән өлкәсендә сынап карыйсы килә.

Ниһаять ул, югарыда күрсәтеп үткәнчә, Казандагы Хатын-кызлар югары курслары студенткасы. Бу курсларның институт прог-

раммасы буенча эшләгәне, укытучыларның да барысы да диярлек университет галимнәре булганы мәгълүм инде. Фатыйма тарих һәм иҗтимагый фәннәр төркеменә (факультетына) керә.

Уку түләүле. Уку өчен дә, яшәү өчен дә акча кирәк. Кечкенәдән үз көнен үзе күрергә өйрәнгән кыз, Казанда кыз балалар өчен ачылган рус-татар башлангыч училищесында да, Ләбибә Хөсәениянең кызлар мәктәбендә дә рус теле укыта. Тырышлыгына ис китәрлек. Эшли-эшли укуына карамастан, 1917 елда бик яхшы билгеләр белән тәмамлый ул Югары уку йортын. Өстәвенә укыган елларда татар матбугатына мәкаләләр дә язып тора, җәмәгать эшләрендә, яшьләр түгәрәкләрендә ихластан катнаша. Февраль революциясеннән соң, татар тормышын айкап чыгарган вакыйгаларда ул инде сәяси өлгергән, иҗтимагый-социаль хәрәкәтне яхшы ук төшенгән кеше буларак катнаша.

Татар хатын-кызлар хәрәкәте тагын да киңрәк колач ала. Хәрәкәтнең иң актив эшлеклеләре (алар арасында Фатыйма да бар) киләчәктә үсеш, хәрәкәт юлларын билгеләү өчен корылтай уздыру хакында киңәшләшәләр. Корылтайны оешкан төстә үткәрү өчен “Мәркәз бюро” төзелә.

Бу эшчәнлек матур нәтиҗәгә китерә. 1917 елның 20 апрелендә тантаналы шартларда Казандагы “Новый клуб” бинасында Бөтенроссия мөслимәләренең беренче корылтае ачыла. Коралтайны “Мәркәз бюро” рәисе Хәдичә Ямашева-Таначева ачып җибәрә. Чиксез дулкынланган залга карап, ул үзе дә шул хисләрне зал белән бергә кичерә. Дулкынланмаслык та түгел бит. Тарихта беренче тапкыр татар хатын-кызлары ирекле рәвештә үзләренең киләчәк тормышлары хакында сөйләшергә җыелалар. Бу мәртәбәле корылтайга Россия, Кавказ, Кырым, Төркестан, Польша хатын-кызларыннан 71 делегат килә. 300 дән артык хатын-кыз “дөньяда күрелмәгән хәлне күрү, ишетү өчен килеп баштан ахырга кадәр чын ихлас белән утырдылар”, – дип яза “Сөембикә” журналының баш мөхәррире Якуб Хәлили. Корылтайда хатын-кызларга кагылышлы күп кенә докладлар тыңланып, карарлар кабул ителгәч, алдагы көннәрдә эшне оешкан төстә алып бару өчен “Мөслимәләр җәмгыяте” төзелә. Фатыйма, әйткәнемчә, корылтайны оештыру эшендә, докладлар буенча фикер алышуларда катнаша.

Әмма ул бит укытучы. Мөгаллимнәрнең төрле оешмалары да корылтайларын уздыруны максат итеп куялар һәм үз араларыннан иң булдыклы, сәләтләре белән танылган мөгаллимнәрне корылтайга делегат итеп сайлыйлар да. Корылтайны оештыру, уздыру өчен зур тырышлыкларын куйган алдынгы фикер ияләре Әхмәтҗан Мостафин, Газиз Гобәйдуллин, Исхак Рәхмәтуллин, Фатыйма Дәүләткилдеева, Гыйльмнур Нугайларны олы хөрмәт һәм зур рәхмәт сүзләре белән искә алыйк.

Бу корылтай, 1917 елның 20 апрелендә, шулай ук тарихта беренче мәртәбә, зур күтәренкелек шартларында, Казанның "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе бинасында ачыла. (Әйтеп үтим, мәдрәсә бинасына бу хакта истәлек тактасы куелса, фидакарь мөгаллимнәребез рухына нинди матур хөрмәт билгесе булыр иде). Аңа Россиянең төрле почмакларыннан 100 дән артык делегат килә, алардан тыш төрле газета-журналлардан тагын шулкадәр хәбәрчеләр җыела.

Корылтайны Казан мөгаллимнәре исеменнән "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең уку-укыту бүлеге мөдире Әхмәтҗан Мостафин үзе ачып җибәрә, шунда ук үзе рәис итеп тә сайлана. Аның ярдәмчеләре һәм сәркатипләр итеп Исхак Рәхмәтуллин, Габдулла Ибраһимов (Шнаси), Сәлах Камал, Гыйльминур Нугай, Фатыйма Дәүләткилдеевалар күрсәтелә.

Корылтайның нинди матур, эшлекле шартларда үтүе хакында язып чыккан идем инде. Тик Бөтенроссия укытучыларының Газиз Гобәйдуллин җитәкчелегендә "Мәркәз бюросы" сайлануын һәм анда да Фатыймабыз сайлануын күрсәтеп үтәсем килә. Нинди атаклы мөгаллимнәр – Габдулла Шнаси, Әхмәтҗан Мостафин, Мөхетдин Корбангалиевләр белән бергә бит (!)

Съезд (мөгаллимнәр үзләре шулай съезд дип атыйлар) 27 апрельгә кадәр дәвам итә һәм Мәскәүдә 1 нче майда ачылачак "гомуми мөселман" съездына вәкилләр сайлый. Алар арасында мөгаллимәләрдән дүрт кеше: Фатыйма Дәүләткилдеева, Мәрьям Мөштәриева, Мәрьям Морадимова һәм Гыйльминур Нугайлар бертавыштан күрсәтелә. Биредә һәм моннан соң үткәрелгән мөселманнарның барлык съездларында да катнаша Фатыйма. "Мәркәз бюро" әгъзасы буларак, мөгаллимнәрнең эш, тормыш шартларын үзгәртү эшенә кушыла. Алар тырышлыгы белән күп кенә

төбәкләрдә мөгаллим-мөгаллимәләр өчен җәйге курслар ачыла. Укытучыларның икенче съездын үткәрүгә хәзерлек эшләре башлана. Анда да Фатыйма башлап йөрүчеләрдән. II съезд 1917 елның август аенда Казанда, хәзерге Ратуша бинасында үтә. Өченче съезд Октябрьдән соң 1918 елның маенда эшли. Аларда катнашучылар мөселман халыкларының мәгарифен яхшырту хакында мөһим карарлар кабул итеп, дәртләнеп эшкә тотынсалар да, Совет власте урнашу белән өметләре дә, тормышлары да чәлпәрәмә килә.

1918 елның июнендә Фатыйма Уфага кайта һәм Зыя Камали (икетуган апасы Гайшәнең ире) җитәкләгән "Галия" мәдрәсәсендә ир балаларга рус теле, тарих, педагогика укыта башлый. Уфаны кызыллар алгач, мәдрәсә ир балалар мәктәбе итеп үзгәртелә, анда инде Фатыймага директор вазыйфалары йөкләтелә.

1919 елда Кече Башкортстан автономиясе төзелгәч, Фатыйма Дәүләткилдееваны аның башкаласы Эстәрлетамакка эшкә чакыралар. Ул Халык Мәгариф Комиссариатының фән бүлеген җитәкли. Әйтергә кирәк, Фатыйманың тырышлыгы белән тиз араларда архив идарәсе, этнография музее, тарихи һәйкәлләрне саклау идарәләре төзелә. Башкорт балалары өчен милли мәктәпләр төзү, уку әсбаплары булдыру да аның булышлыгы белән эшләнә. Моннан тыш, 1920 елның маенда ук Башкортстанның көньяк районнарында яшәүчеләрнең тормышын, тарихи үткәнен өйрәнү өчен иҗади экспедиция оештырыла. Ул да Фатыйма җитәкчелегендә үткәрелә. Борынгы курганнар ачыла, милли кием үрнәкләре җыела, җырлар, бәетләр язып алына.

1926 елдан Фатыйма – Казандагы СССРда яшәүче Көнчыгыш халыкларының этник һәм милли мәдәниятләре фәнни-тикшеренү институты аспиранты. Ул күптәнге хыялы – фән белән шөгыльләнүгә, фәнни ачышлар ясауга ирешкән дә кебек. Тик инде илдә вәзгыять үзгәргән. Илне индустрияләштерү, коллективлаштыру кебек үзгәрешләр башланган һәм зыялыларга һөҗүм башланган чор бит. 1930 елда ул Мәскәүдәге дәүләт үзәк этнография музее фәнни хезмәткәре булып эшли башлый. Төрки халыклар мәктәпләре өчен дәреслекләр, методик кулланмалар төзеп чыгаруда, милли кадрлар хәзерләүдә зур тырышлык күрсәтә. Хаклы рәвештә Мәскәүдә чыга-

рылган “Научные работники Москвы” исемле китапка исеме дә кертелә.

Ни кызганыч, милләтебезнең гүзәл энҗесе булырлык бу кадәр зур талантлы кызыбызның гомеренең соңгы елларындагы эшчәнлеген белә алмадым. Афәтле елларда ничек исән кала алды икән? Тик шунысы үкенечле, өлкән яшьләрдә ул үзенең милләтен “ярты татар”, “ярты башкорт” дип күрсәтергә мәҗбүр була. Моның объектив сәбәпләре ачык инде. Шулай да мондый хәл белән килешү авыр. 1920 нче елларда Татарстанда хатын-кызлар хәрәкәтенең күренекле җитәкчесе булган Зөһрә апа Баимбетова белән Мәскәүдә очрашкач, аның да үзен “башкорт” дип күрсәтүенең сәбәбен сораган идем. Ул болай дип әйтте: “И кызым, үз теләгебез белән язылдылар дип уйлама. Совет власте ныгыгач, Татарстаннан булдыклы, талантлы кешеләрне чит җирләргә күчерү башланды. Безнең кадер бетте. Ә Башкорстанга без кирәк идек әле. Әнә бит онытмыйлар. Бәйрәм саен тәбрикләп, кунакка чакырып торалар. Күпләр исемнәр, орден-медальләр алды. Дөнья бу, кызым. Исән калганыбызга Аллага рәхмәт әйтәбез бит әле”.

Дөнья бу, туганнар, бик дөрес. Күпме талантлы шәхесләребезнең әнә шундый фаҗигаләре белән дә тулган дөньябыз бу. Әмма алар безнеке, аларга догаларыбыз барсын, рухлары шатлансын.

Уфадан Фатыйма Дәүләткилдееваның рәсемен һәм истәлеген җибәргән Флюра Римовна Адаменко-Дашкинага рәхмәтемне белдерәм.

## КЕМНӘРЕҢ САГЫНДЫРА…

*И элиты почти нет. Великаны ушли.*
*Светлана Алексиевич,*
*белорус язучысы, Нобель премиясе лауреаты*

Татар хатын-кызлары хәрәкәтен өйрәнгәндә, нинди генә язмышларга юлыкмыйсың да, кемнәргә генә сокланмыйсың. Нәкъ җырдагыча:

*Кемнәрең бар, кемне уйлыйсың,*
*Кемнәрең сагындыра…*

Әйе, тормыш юлларын өйрәнгәндә, кылган гамәлләренә сокланган затлы, зыялы хатын-кызларыбызны сагынам. Үзләрен күреп белмәсәм дә сагынам. Күңелемнән алар янәшәсенә үземне, замандашларымны куеп карыйм, тик булмый, туры килмибез. Юк икән, XIX–XX гасыр башы алиһәләре бөеклегенә җитеп булмый икән. Бу аерманы күбебез аңлап җиткерә алмыйбыз әле. Ни кызганыч, аларның күбесе тарихыбызга кереп, тиешле урыннарын ала алмасалар да, кайберләре “безне дә онытмагыз” – дигән кебек һич көтмәгәндә очраклы рәвештә генә булса да, үзләрен белгертеп куялар. Менә Баишевлар нәселендәге кызлар белән дә нәкъ шулай булды.

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында эшләгән вакытымда Мәскәүдән килгән олуг тарихчы галимебез Шамил Фатыйх улы Мөхәммәдъяров белән бик аз гына сөйләшеп алырга мөмкин булган иде.

– Шамил ага, әтиегезне хөрмәт белән искә алабыз, тормыш юлын бераз беләбез дип уйлыйбыз, ә әниегез кем булган? – дип сорадым аңардан.

– О-о, минем әниемнең кыз фамилиясе Баишева, ул атаклы Баишевлар нәселеннән, Өммегөлсем исемле иде. Ул да, тагын биш кыз туганы да заманында югары белем ала алганнар, тормышларында яхшысын да, яманын да күргән кешеләр, – диде ул. Шул урында сүз өзелде, башка сөйләшә алмадык. Ә күңелем кубып, җилкенеп калды. Чөнки минем 2003 елда басылып чыккан “Ступени образования до Сорбонны” дигән китабымда Октябрьгә кадәр рус



*Гөләндәм Баишева*

кызлары өчен ачылган төрле-төрле уку йортларында белем алган Баишева фамилиясендә 6 кыз искә алына. Эзли торгач кайберләре хакында мәгълүматларны таптым. Тормыш юллары үземә гыйбрәтле тоелгач, укучыларга да тәкъдим итәргә булдым, чөнки мәгърифәтчелек тарихында якты эзләре бар аларның.

Пензада яшәгән сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Баишев гаиләсендә алты кыз – Гайнелхәят, Өммегөлсем, Шәмсекамәр, Мәрьям, Гөләндәм һәм Зәйнәп исемле кызлар үсә. Мөхәммәтҗан ага кызларының язмышлары чит җирләр, ягъни Азәрбайҗан, Төркестан, Казан губернасы белән бәйләнер дип уйлагандырмы, юктырмы – анысы билгесез. Әмма кызларын ничек тә гыйлем-мәгърифәт ияләре булсыннар дип зур тырышлык куйган ул игелекле җан.



*Гайнелхәят, Шәмсекамәр Баишевалар*

Сүзне Гайнелхәяттән башлыйк. 1905 елда Пенза гимназиясен алтын медальгә тәмамлап, Петербургта хатын-кызлар өчен ачылган Югары педагогия курсларына (институт программасы белән университет галимнәре укыткан уку йорты) укырга керә бу кыз бала. Бу вакытта биредә Казаннан килгән татар кызлары Әхмәрова (ире буенча Дәүләткилдеева) Маһипәрвәз һәм Суфия Коләхмәтовалар да укый. Алар таныш булмаганнардыр дип уйларга һич нигез юк. Курсларны тәмамлагач, Гайнелхәят Пулководагы сәнгать мәктәбендә эшли башлый. Әйтеп китик, кыз баласының уңышларына сөенгән Мөхәммәтҗан ага куанычыннан корбан чалырга була, әмма бармагына ялгыш кына пычак тиеп китә. Киселгән урынга ниндидер үлән ябып караса да, файдасы булмый. Бармакка инфекция керү сәбәпле, бик тиз генә үлеп тә китә.

Әтисенең шулай вакытсыз үлеме Гайнелхәятнең тормышына да кискен үзгәрешләр кертә. Ул гаиләдә олы бала, төрле-төрле уку йортларында, төрле шәһәрләрдә укып йөрүче сеңелләре өчен дә үзен җаваплы сизә. Әнисе Казан шәһәренә күчеп яши башлый. Бәлки, башка сәбәпләр дә булгандыр. Шул вакыт Азәрбайҗанның Ганҗә шәһәрендәге кызлар мәктәбенә яхшы хезмәт хакы белән чакыру килә аңа. Гайнелхәят риза була һәм бу җылы якка килүенә һич тә үкенми.

Тарихи мәгълүматларга караганда, бу чорда Азәрбайҗанда татар гаиләләре күп була. Күбесе нефть чыгару, балык тоту эшендә булсалар да, татарның гомер-гомергә мәгарифкә булган мәхәббәте аларны тирә-якта яшәүчеләрдән аерып торган. Яшәгән һәрбер урында татар мәктәпләре ачылган, һәрберсе баласын укытырга тырышкан. Яхшы, тырыш эшләгәч, бәлки мохтаҗлык та ул кадәр көчле булмагандыр дип ышанам, чөнки тормышлары иркенрәк булгандыр дияргә җирлек бар. XX гасыр башында ук бу гаиләләрдә ислам хорафатлары кими башлап, татарларның кыз балалары үзләренең фикер хөрлеге, яңа тормышка омтылышлары белән башкаларга үрнәк булганнар. Укымышлы, эш сөючән, тыйнак, күркәм ана булырдай татар кызларын азәрбайҗан егетләре үзләренә алырга тырышулары һич тә гаҗәп түгел. Шуңа күрә дә Азәрбайҗанның зыялы егете Нәсиббәй Усуббәев та Гайнелхәятне бер күрүдә

ошатып, тормышта мәңге бергә булырлык яр итеп сайлый. Алар өйләнешәләр. Әмма бәхетләре генә озакка бармый.

Инде мәгълүм булганча, Октябрьдән соң Азәрбайҗанда да төрле-төрле үзгәрешләр була. Азатлыкка омтылган халык үз идарәсен төзи. Тик Россия хөкүмәте моңа юл куймый. (Ул вакыйгаларны иркенләбрәк аңлатсам, мәкалә озынга китә). Азатлык хәрәкәте җитәкчеләренең күбесе юк ителә, Азәрбайҗан хөкүмәтенең мәгариф министры Усуббәев Нәсиббәй дә атып үтерелә. Гайнелхәятне кайгылы чагында ялгыз калдырмаска теләп, янына кайбер сеңелләре килеп яши башлыйлар.

Азәрбайҗан Совет республикасы төзелгәч, югары белемле Гайнелхәятне Бакуга чакыралар. Чөнки белемле кадрлар кайда да җитешми, аларга кытлык заманы. Ул Мәгариф комиссариатында инспектор вазыйфаларын башкара, бер үк вакытта кызлар гимназиясендә математика фәнен укыта.

Аның моннан соңгы педагогик һәм фәнни эшчәнлеге Баку университеты белән бәйле. Анда ул эшчеләр факультетын (рабфакны) оештыручы, аның җитәкчесе, югары математика кафедрасы доценты булып хезмәт итә. Хезмәттәшләре арасында үзенең белеме, югары әхлагы һәм искиткеч акылы, сәләте белән зур хөрмәт казана. Тик кайгы ялгыз йөрми, кешегә бер килсә, тиз генә җибәрер димә, озакламый Гәйнелхәят бердәнбер кызын да җир куенына сала. Бердәнбер баласын күмгәч, ничекләр исән кала икән аналар, дип, бик еш уйланам.

Кайгы-хәсрәтләреннән, ялгызлыгыннан алҗып, ул Ташкентта табибә булып эшләгән сеңлесе Зәйнәп янына күчеп яши башлый. Бераз хәлен җиңеләйтүгә өметләнә. Финанс-икътисад институтына эшкә урнаша. Тик кызының кабере, Нәсиббәе белән бергә узган яшьлеге, Бакуның истәлекле, кадерле урыннары үзенә тарткандыр, 1944 елда ул яңадан Бакуга күчә. Монда кайткач, шөкер, педагогия институтына үзе яраткан педагоглык эшенә урнаша алган, студентларга югары математика фәнен укыта башлаган. Тик "халык дошманы" хатынының югары белеме, эш тәҗрибәсе, осталыгы күпләрнең көнчелегенә сәбәп була. Аның өстеннән әләкләр язу күбәя, аны эштән чыгаралар. Моның өстәвенә, вакытлы матбугатта хәтта аңа янаган мәкаләләр күренә. Шундыйларның берсе "Баку эшчесе"

дигән татар газетасында басыла. Анда бер Әбүбәкеров дигән мескен җан “Аларны фаш итәргә кирәк, нишләп аның сеңлесе, ягъни Гөләндәм Баишева да мединститут тәмамлагач шул ук институтта эшләргә калдырылган. Наркомсобес үз араларын чистартырга тиеш”, – дигән өндәү белән чыга. (“Баку эшчесе”, 18 ноябрь, 1937 ел).

Мондый вазгыятьтә Гайнелхәят элек үзендә укыган укучысы Берияне искә төшергәндер дип уйлыйм. Ул, чыннан да дөреслек эзләп Мәскәүгә барган, тик юкка. Таба алмаган ул үзе өметләнгән дөреслекне. Аптырагач, Казанга килә. Биредә аның табибә сеңлесе Өммегөлсем яши, эшли. Аның ире Фатыйх Гариф улы Мөхәммәдъяров Татарстанның беренче сәламәтлек саклау министры. Тик үзе дә бер тапкыр Солтангалиевчелектә гаепләнеп, Мәскәүнең Бутырка төрмәсендә утырып чыккан. Бу вакытта Казаннан читкәрәк китеп яшәргә мәҗбүр булган (Шамил абый сөйләгәннәрдән).

Татарстанның мәгариф министры Гайнелхәятне Мамадыш районында укытучы итеп эшкә урнаштыра алган. Пенсия ала башларга да ярдәм иткән. 22 ел педагогик стажы булган, Петербургта укып белем алган укытучыга У.Т. Контюков шулай ярдәм итә алган. Рухына сүзебез дога булып барсын.

Мамадыштан Гайнелхәят янәдән Ташкентка күчеп китә. Әмма бер җирдә дә җанына тынычлык таба алмый. 1952 елда гүзәл яшьлеге, бәхетле еллары узган, сөекле ире, бердәнбер кызының каберләре урнашкан Баку каласына әйләнеп кайта. Әмма гомере чикләнгән булган икән. Шулай итеп, татар халкының талантлы кызы, мактаулы хезмәтләре белән азәрбайҗан халкының да хөрмәтен казанган, үз баласына әйләнгән Гайнелхәят Баишева 1955 елда бакыйлыкка күчә.

“Татарстанда яшәгән булса” дип уйлыйм да, куркып китәм. Никадәр талантлы кызларыбыз юк ителде бит ул елларда. Күрергә язмасын.

Сүз башыбызда Мөхәммәтҗан гаиләсендә алты кыз булганын әйтеп үткән идек. Мәкаләдә кайберләрен искә алып үтик. Әмма халкыбызның бу кызларын ничә генә кабатлап искә алсак та, артык булмас. Бүген алар исән түгел, тик дәвамчылары – балалары бар. Газетаны укысалар, әниләре белән горурланганыбызны күреп шат-

лансыннар. Үзләре дә Баишевлар данына тап төшермәсеннәр дип телик. Димәк:

Гайнелхәят белән Шәмсекамәр – педагоглар. Әле нинди генә педагоглар. Гайнелхәят хакында аз гына мәгълүмат булды кебек. Шәмсекамәр үзе хакында сүзебезне көтә. Математиканы белүе яратып укытуы, өстәвенә Көнбатыш һәм Шәрык мәдәниятеннән яхшы мәгълүматлы булуы белән сокландырган ул замандашларын. Хезмәттәшләре аны “аяклы энциклопедия” дип йөрткәннәр. Рәхмәт аңа, урыны җәннәттә булсын.

Гөләндәм, Зәйнәп, Мәрьям, Өммегөлсем – барысы да табибәләр. Аларның табибә булып китүләренә, баштарак кызларны университетларның медицина факультетына гына алу белән дә аңлатып була төсле. Әмма кызларның мәдрәсәдән соң, рус кызлары өчен ачылган гимназияләрдә укып, университетларга имтиханнар тотып керә алуларына сокланмый мөмкин түгел. Үз телләрен бервакытта да онытмыйча, татар булып яшәгәннәр, барысы да җәмәгать эшләрендә катнашып, татар дөньясы эчендә кайнаганнар. Аларга карап сокланганнар, аларны үзләренә хатынлыкка алуны төрки дөнья егетләре бәхет итеп санаганнар. Өйрәнергә иде кызларыбызның тормыш юлларын. Әле дөньяга чыгуны көтеп яткан мактаулы җаннарыбыз күпме!

Әнә алар сагындыра, бүген безгә алар җитми.

# КЫРЫМ ЭНҖЕСЕ

Октябрьгә кадәр татар кызларының югары белем алуда күргән кыенлыклары һәм, максатларына ирешкәч, милләтебезгә кылган игелекләре хакында язганда бу тиңдәшсез батырлыкны бәһаләргә сүзләр таба алмыйм. Нинди көчле каһарманлык таләп ителгән алардан. XIX гасыр үтеп барган чорда да (!), патша Александр II нең 1870 елның 26 мартында “Правила о мерах образования населяющих Россию инородцев” дигән указы чыккан һәм бу документта Төньяк халыклары, Себер, Урта Азия, кавказлылар, татарлар һәм еврейлар “неполноправные инородцы” дип бәяләнгәннәр. Бу халыкларны кимлектә, хурлыкта тоту царизмның төп сәясәте булуы хакында сөйләмиме? Татарларның гасырлар дәвамында дөньяви мәктәп ачудан да мәхрүм ителеп яшәүләре шул сәясәт нигезе бит инде. Шул ук вакытта, дөньяви белем бирүче урыс уку йортларының ишекләре татарлар өчен, аерым очракларны исәпкә алмаганда, гел ябык булуы да тарихи факт. Менә шуңа күрә дә “инородецларның” фән һәм дөньяви белем йортларына кереп укый алулары бәһаләп бетерә алмаслык каһарманлык та шул. Шунысы куаныч, рус кызлары өчен генә башкалада югары уку йортлары ачыла башлап, 15–20 ел үтүгә үк, кызларыбыз аларга кереп укый да алганнар, диплом да алып чыкканнар. Бу хакта “Ступени образования до Сорбонны” дигән китабымда яздым инде, шөкер. Ул хезмәтем шул каһарман кызларыбызның исемнәрен мәңгеләштерүдә бер адым булсын. Мондый батыр йөрәкле кызларыбызның исемнәре билгеле булса да, тормыш юллары хакында бик аз язылды әле. Ә уйласак, алар безнең горурлыгыбыз, милли хәзинәбез, тормышыбызның матур мактанычы.

Менә шундый гүзәл кызларның берсе Кырым татары кызы Диләрә Булгакова. Ул 1895 елда Ялтадан ерак түгел Дерекой (Дөрекәй) авылы дворяннарыннан саналган Али морза Булгаков һәм Зөһрә Солтан ханым гаиләсендә туа. Диләрәдән башка гаиләдә тагын өч бала – Бәхтияр, Котлыяр һәм Гөлнар үсеп килә. Гаиләнең тоткасы Али морза Таврия губернасы земство идарәсендә Евпатория өязеннән һәм берүк вакытта Таврия дворяннар җыелышында

Ялта өязеннән депутат булып сайланган мөхтәбәр зат. Кырым татарлары арасында үзенең зыялылыгы белән хөрмәт казанган зат булуы өстенә, иганәчелек белән дә шөгыльләнеп, халкына күп кенә игелекләр эшләгән. Шәфкатьлелек һәм мәгърифәтчелек сыйфатлары Али Булгаковның балаларына да күчкән икән.

Булгаковлар гаиләсенә һәм, гомумән төрки халыкларда мәгариф тормышын үзгәртүгә зур өлеш керткән зыялы Исмәгыйль Мостафа улы Гаспралы һәм аның хатыны Зөһрә Әсфәндияр кызы Акчуринаны искә алмый китеп булмый. Алар чыгарган “Тәрҗеман” газетасы битләрендә хатын-кызларга, аларның азатлыгына багышланган мәкаләләр даими чыгып тора. Бу ике гаиләнең дусларча аралашып яшәүләре шик тудырмый. Диләрә белән Шәфика Гаспралы яшьтәшләр диярлек. Һәр ике гаиләдә балалар матур тәрбия алып үсәләр. Гаиләләрдә нәзакәтле мөнәсәбәт урнашып, үз туган телләреннән тыш гарәп, фарсы, рус, француз телләрендә иркен сөйләшә алуларын әйтеп китсәм дә урынлы булыр. Диләрә белән Шәфиканың дуслыгы Октябрьдән соң да дәвам иткәнен дә искәртеп китәм.



*Диләрә Булгакова (басып тора)*

Диләрә 1910–1914 елларда Петербургта хатын-кызлар өчен махсус ачылган Югары педагогия курсларында (институт программасы белән эшләүче) укый. Бу елларда Диләрә белән укыган татар кызларының исемнәрен атап үтәм. Менә ул мактаулы кызларыбыз: Сәгадәт Еникеева (Ташкент), Гөлсем Камалова (Чистай), Тәнзилә Котлыярова (Касыйм). Мәхфүзә Максудова (Петербург), Рокыя Юнусова (Петербург), Хәят Баишева (Пенза), Мәймүнә Шәфигуллина (Троицк), Сәлимә Якубова (Баку), Гөлсем Әсфандиярова (Ташкент), Мәрьям Акимбитева (Сәмәрканд) һәм Хәят Мәмлиевалар. (Казан кызларының исемнәре язылмаганга күңелсезләнмик, алар Югары медицина

курсларында укыганнар). Күпме киртәләрне үтеп, (югарыда әйтелгәнчә, бары тик рус кызлары өчен генә ачылган уку йортларында) башкалада уку бәхетенә ирешкән бу һәм бүтән кызлыбызның тормышлары, хыяллары әдәбиятыбызда да чагылыш тапты. XIX йөзнең соңгы елларында әдәбиятка килгән әдип һәм мөхәррир Фатыйх Кәриминең (1870–1937) "Хыялмы, хакыйкатьме?" хикәясе – моның ачык мисалы. Әсәрдә, укучы кызның Думадагы мөселман депутатлары белән кулга-кул тотынышып, халык, милләт файдасы өчен эшләргә ниятләве хакында языла. "Бәнем максудым – үз ватаныбыз булган Русиядә торып, милләттәшләремә хезмәт итмәк, – ди ул. – Петербургта укучы мөселман кызлары барымыз унсигез кадәрле. Үземезгә махсус бер милли кружок ясадык вә ошбу нәрсәләргә карар бирдек:

− Үз арамызда ана телемездән башка һичбер телдә сөйләшмәскә вә ана телемезне онытмаска; төрле татар гәзитләре вә яңа әдәбият миллия рисаләләре (милли әдәбият китаплары) алдырып, шуларны укырга; милләтемезнең әфкяре, әхвале вә истикъбале (киләчәге) хакында төшенергә вә тарих миллиямезне үгрәнергә.

− Без табибә, акушерка, мөгаллимә булып, мөселманнар күп булган йирләргә барачакмыз, үземезнең мөгаләмәбез вә әхлакымыз илә анларны мәктәпкә вә укырга мәхәббәт иттерәчәкмез…"

Кызларыбызның үз алларына шундый максатлар куюында XIX йөзнең ахырында әдәбиятка килеп, зур әдәби һәм публицистик мирас калдырган язучы, сәясәтче, милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе, олы шәхесебез Гаяз Исхакыйның (1878–1954) тырышлыгы зур. Ул үзе чыгарган "Ил" газетасында" "Хатын-кыз өстәле" дигән бүлек ачып, даими рәвештә хатын-кызларга багышланган язмаларны чыгарып тора. Югарыда исемнәре аталган кызларыбызның күбесе – "Өстәл"нең даими авторлары да.

Менә шундый шартларда формалаша Диләрәнең тормышка мөнәсәбәте. Аны якыннан белүчеләр кыз баланың бәләкәй чагында ук фикерләү сәләте көчлелеген, тирә-якка, кешеләргә карата җитди, төптән уйлаган үз фикере булганлыгын әйтә торган булганнар. Аның әдәбиятны, сәнгатьне теләсә кемне сокландырырлык нечкә сиземләвен, матур итеп сөйли белүен дә күрсәтәләр. Бу сыйфатлар

аның рухи затлылыгыннан, образлырак итеп әйтсәк, “аксөяклелегеннән” килгәндер дип уйлыйм.

Кырымга кайткач, Диләрә хыялларын тормышка ашырырга керешә. Бигрәк тә хатын-кызларны мәгариф өлкәсенә, уку һәм укыту эшләренә тарту өчен җиң сызганып эшли башлый ул. Озакламый Ялтада аның җитәкчелегендә хатын-кызлар комитеты оеша. Комитетның исеме дә үз максатын ачыклап тора – “Ени аят” (“Яңа хәят”). Менә шул яңача тормышка хәзерләү өчен махсус курслар оештырыла. Курсларда наданлыкны бетерү белән бергә хатын-кызларның тормышта тигез хокуклы булырга тиешлекләре аңлатыла, укымышлы ханымнар белән очрашулар үткәрелә, төрле-төрле темаларга лекцияләр тыңлана. Әмма Россиянең башка төбәкләрендәге шундый хатын-кыз оешмаларының эш тәҗрибәләре белән танышу, фикерләр уртаклашу мөһимлеге көннән-көн үзен сиздерә.

Ниһаять, бөтен өметләрне балкытып, якты апрель аеның 24 се көнендә (1917 ел) Казанның “Новый клуб” бинасында Бөтенроссия мөслимәләренең беренче корылтае ачыла. Кызыл әләмнәр белән бизәлгән бина хөррияткә, тигез хокук өчен көрәшкә, бөтендөнья хатын-кызларын берләшүгә өндәгән лозунглар белән тулы була. Корылтайда Эчке Россия, Кавказ, Кырым, Төркестан, Польша сайлаган 71 вәкилә залда чиксез дулкынлану кичереп утыралар. Алардан тыш дөньяда күрелмәгән бу хәлне “күрү, ишетү өчен тагын өч йөздән артык хатын-кыз килеп баштан-ахырга кадәр чын ихлас белән утырдылар”, – дип яза “Сөембикә” журналының баш мөхәррире Якуб Хәлили.

Корылтай хатыннарның шәригатьтә хокуклары; аларның гаиләдә тоткан һәм тотачак урыннары; сәяси хокуклары; иҗтимагый тормышта тоткан урыннары; Учредительное собраниягә катнашулары кебек көн кадагында торган мәсьәләләрне тикшерә. Сайланып килгән вәкиләләр арасында Кырымның мәшһүр кызлары Диләрә Булгакова белән Шәфика Гаспралы да утыра.

Корылтайның исеме хатын-кызлар соравы буенча съезд дип атала башлый. Съездда, алга куелган мәсьәләләрне тикшереп карарлар кабул иткәч, эшне оешкан төстә алып бару өчен биш кешедән Мәркәз бюро оештырыла. Аңа Сәлимә Якубова, Заһидә Бурнашева, Диләрә Булгакова, Өммегөлсем Әсфандиярова һәм Рауза Солтанга-

лиевалар бертавыштан сайланып куелалар. (Мәркәз бюро башта Мәскәүдә эшләргә тиеш булса да, соңрак Казанга күчерелә). Мәркәз бюро әгъзалары һәм янә 3 кеше: Хәдичә Ямашева-Таначева, Илһамия Туктарова, Мәрьям Криницкаялар Мәскәүдә шушы 1917 елның 1 маенда ачылачак Бөтенроссия мөселманнары съездына да вәкилә итеп сайланалар.

Россия мөселманнары съездында Төркестан, Кырым вәкилләре, урыннарда халык мәгарифен үстерүдә булышлык сорап, Казан вәкилләренә үтенеч белдерәләр. Кырым татарларына ярдәм итү йөзеннән Илһамия Туктарова белән Зәйнәп Әмирханова шулай Симферополь шәһәренә юллама алып киләләр.

Съездларда алган тәэсирләр, өметләр белән коралланган яшьләр хатын-кызлар арасында колачлы эш җәелдерәләр диясем килә. Бакчасарайда хатын-кызлар комитеты оештырыла. Аның эш планы Мәркәз бюро күрсәтмәләрен истә тотып төзелә һәм уңышлы гына эшләп тә китә. Симферополь шәһәрендә хатын-кызлар өчен И.Гаспралы исемендә укытучылар хәзерләү мәктәбе ачыла; кыз балаларны башлангыч мәктәпләргә тарту, укый-яза белмәгәннәр арасында эшләү, газеталарга мәкаләләр язу – алар башкарган эшләрнең бик азы гына әле. Алар яшь буынны туган халкына намус белән хезмәт итәргә, аның бай тарихын, мәдәниятен, казанышларын өйрәнергә, милләтнең өметле киләчәге өчен нәтиҗәле көрәшкә рухландыралар.

Өметләре дә акланган кебек була аларның. 1917 елның августында Кырымда мөселман хатын-кызлары Үзәк Комитеты оеша. Диләрә Булгакова аның әгъзасы, бүлек мөдире. 1918 елда Кырым милли парламентына Диләрәнең якын дусты Шәфика сайлана. Эшләрен хуплап, ярдәм итеп торучы дуслары да табыла.

Ләкин язмыш аларның изге омтылышларын тормышка ашыруга киртә сала. Большевиклар власте Кырымда, соңрак Кавказда ныгып, илдә дәһшәтле вазгыять урнашканнан соң, һәрбер йогынтылы хәрәкәтләр, милли көчләр көрәш мәйданын берәм-берәм калдырып китәләр. Мондый шартларда Диләрәгә дә туган җиреннән аерылып китүдән башка чара калмый. Ул Бакуга күчеп китә.

Кыз баланың шәхси тормышы хакында язмадым. Ул өлкәдә дә язмышы – йөрәк ярасына тиң. Үзе кебек зыялы татар егетләре белән өч тапкыр тормыш корып карый ул. Сайлаганнары да зыялылардан,

фикердәшләреннән була. Тик сәяси репрессияләрдән берсе генә дә котылып кала алмый аларның. Төрле елларда төрлечә сәбәп белән фаҗигале язмышка дучар булалар.

Диләрә Бакуда, Әзербайҗан авылларындагы мәктәпләрдә рус теленнән дәресләр бирә. Рус телен камил белгәнгә, дәресләре үрнәк итеп куела. Сугыш башлангач, мәктәпләрдә дәресләр кыскара, күп кенә мәктәпләр ябыла. Янында аның тәрбиясендә әнисе, балалары да була. Матди хәле бик кискенләшә. 1943 елның 23 октябрендә Кырым татарының гүзәл шәхесе дөнья белән саубуллаша. Язмышның талантлы, юньле шәхесләргә ник болай рәхимсез икәнен кем белә?

## “ВӘГЪДӘ – ИМАН” ДИГӘН…

Сугыш вакытында разведчикларга менә мондый эчтәлекле күрсәтмәләр бирә торган булалар һәм аларны үтәү бик мөһим булган: “Берәр авылдан чыгып киткәндә, артыңа борылып кара. Күргәннәрең, кире кайтканда, сиңа дөрес юнәлеш күрсәтеп торырлар”. Бу киңәшләр, үткән тарихыбызга да һаман-һаман борылып карап, дөрес нәтиҗә чыгарыр өчен дә мөһим икән. Дөрестән дә, күпме генә фәнни хезмәтләр язылып, халыкара конференция материаллары матбугатта дөнья күрсә дә, татарның затлы-зыялы шәхесләре, шул исәптән укымышлы кызлары язмышына да җитдирәк карау, барлау зарурлыгы һаман кимеми әле.

Шушы җәһәттән, XX гасыр башында ук югары белем алып, илнең иҗтимагый тормышында билгеле бер урын тоткан Рабига Шәрәфетдин кызы Габитованың тормыш юлын искә төшерү дә һич тә артык булмас төсле. Саф намуслы, тормышында һаман яктыга, югарыга омтылган, замандашларының хөрмәтенә хаклы рәвештә лаек булган кыз баланың матур гамәлләре хакында кайбер истәлекләр сакланган.

Ул 1889 елның 6 гыйнварында Шәркый Төркестанның Голҗә шәһәрендәге Россия илчелегендә консул булып хезмәт иткән Шәрәфетдин Габитов гаиләсендә туа. Шәрәфетдин киң мәгълүматлы, белемле, укыган кеше булып, күп кенә көнчыгыш телләрендә сөйләшә алган. Рабига туган чорда аларның гаиләсе Ташкент шәһәрендә яшәгән, әмма әтиләренең вафатыннан соң гаилә – әниләре Гафифә, балалары Гариф, Исмәгыйль, Зәйнәп, Рабига Казанга кайтып, Первая Гора урамындагы 31 нче йортта яшәгәннәр.

Рабига 1905 елда Казанда Мариинская гимназияне уңышлы тәмамлагач, 1906 елның 23 ноябрендә шәһәрдә яңадан торгызылган Югары хатын-кызлар курсларының тарих-филология факультетына укырга керә. 1918 елга кадәр эшләгән бу курсларда укыган тагын 12 татар кызының исемнәре архивта сакланган.

Курсларда уку срогы дүрт ел, укыту тәртипләре нәкъ университеттагыча: шул ук фәннәр өйрәтелә, курс һәм диплом эшләре язуга да таләпләр бер үк. Укулар атнага 5 көн буена кичке 17 сәгатьтән 21

сәгатькә кадәр алып барылган. Моның сәбәбе ачык. Бердән курсларның 1913 елга кадәр махсус бинасы булмый. Укулар шәһәр биржасында (Бауман урамындагы элекке “Бүләкләр” кибете), 3 нче гимназия (Горький урамындагы 3 нче мәктәп) биналарында һәм университет аудиторияләрендә алып барылган. Бүлмәләр һәм аудиторияләрнең кичке сәгатьләрдә генә буш булганы аңлашылса кирәк.

Курслар өчен түләү бәяләре заманы өчен бик югары булган. Шунлыктан, күп кенә курсисткаларның көндезләрен эшләп акча табарга мәҗбүр булулары да мәгълүм. Әтисе вафатыннан соң гаиләнең матди ягы бик авырлашканга күрә, Рабига да үзе эшләп акча табарга мәҗбүр булган һәм курсларны бары 1918 елда гына тәмамлый алган. Аның бу тырышлыгы мактауга лаек. Ул һөнәре буенча “Рус теле укытучысы” дигән диплом ала.



*“Шимбә” түгәрәге. Утырганнар: сулдан беренче Рабига Габитова*

Мөселман кызларына бары тик рус кызлары өчен генә ачылган югары уку йортларына керүнең никадәр авыр булганын үз хезмәтләремдә бераз язган идем. (Кара: Татар кызлары мәгърифәт юлында. – Казан, 2001 һ.б.). Меңнәрчә киртәләрне җимереп мондый уку йортларында югары белем ала алган татар кызларын каһарманнар димичә ни дияргә соң? Алар барысы да алган белемнәре белән милләтебезгә игелекле хезмәт итү бурычын да үз өсләренә алганнар бит әле. Һәм һәркайсысы халкыбыз язмышы белән үз язмышын тыгыз бәйләгән, шул бурычны намус белән үтәгән.

Сүзебезне дәлилләү өчен узган гасыр башында сәяси һәм иҗтимагый карашлары киңәеп-үсеп киткән яшьләр хәрәкәтен генә искә төшерик. 1903-04 елларда шәкертләр арасында барган ислах хәрәкәте белән параллель рәвештә, рус мәктәпләрендә укучы татар яшьләренең мәдәни хәрәкәте шактый киң төс ала. Бу хәрәкәт 1904 ел башында “Шимбә” исемендәге түгәрәк оештырылу белән билгеле (исеме шимбә көн җыелудан алынган). Түгәрәкнең беренче җыелышы Шаһбазгәрәй Әхмәров йортында уздырыла һәм анда Әминә Терегулова, Суфия, Сара, Ильяс Әхмәровлар, Зәйнәп, Рабига Габитовалар, Гайшә Богданова (барысы да гимназия укучылары), Нәби һәм Мулланур Вахитовлар, Фатыймаи-Зөһрә, Зәйнәп, Солтан Саиновлар, Әхнәф Мамлиев, Сөләйман Чанышевлар катнашалар. Соңга таба түгәрәк әгъзалары 39 кешегә җиткән, алар арасында шәкетләр саны да күбәйгән. Түгәрәктә рус һәм көнчыгыш классикларының әсәрләрен өйрәнү белән бергә, яңа татар әдәбияты әсәрләрен укып өйрәнүгә дә зур игътибар бирелгән. Моның белән бергә алар, һичшиксез татар халкының, мәгарифенең киләчәге турында, аның иҗади югарылыкка ирешүенә өметләнгәннәрдер. Түгәрәктә беренче башлап укылган татарча әсәр Заһир Бигиевның “Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә” романы булган. Түгәрәккә йөргән яшьләр полициянең даими күзәтүе астында булуларын да әйтеп үтик.

1905–1906 елларда түгәрәкнең эше тагын да җанланып китә. Бу елларда аны марксистик әдәбият өйрәнү түгәрәге итәргә тырышылган икән. Инде мәгълүм булганча, бу эшнең башында Мулланур Вахитов торган. Утырышларның берсе Хөсәен Ямашев квартирасында үткәрелгән. “Түгәрәк нибары ике тапкыр гына җыела алды, – дип яза Рабига үзенең истәлекләрендә. – Бу эш тә полиция аркасын-

да туктатылды”[1]. Бу җәһәттән, хәзер бер дә искә алырга яратмасак та, әйтеп китү һич тә артык булмас. Россиядәге беренче революция алдыннан Казан РСДРП Комитеты татар эшчеләре арасында татарча листовкалар һәм прокламацияләр таратуны оештыра. Бу прокламацияләрне гектографта басып күбәйтүчеләр нәкъ менә Әминә Терегулова һәм Рабига Габитовалар була.

“Шимбә” түгәрәгенең тагын бер әһәмиятле башлангычы – татарча өй спектакльләре оештыру. Бу спектакльләр, гадәттә, укучыларның кышкы ял вакытында үткәрелгән. Башта берничә тапкыр русча, соңрак татарча спектакльләр куелган. Татар телендә беренче өй спектакле 1903 елда Габитовлар квартирасында куелган. Балаларының матур омтылышларына каршылык күрсәтмәгән Гафифә ханымны рәхмәт белән искә төшерик.

“Гариф Габитов фатирында 1905–1906 елларда ай саен яки ике айга бер спектакль куелды. Биредә хатын-кыз рольләрен хатын-кызлар уйный башладылар, – дип яза Вафа Бәхтияров. Зур рольләрне башкаручылар: Шәмсекамәр, Суфия Коләхмәтовалар, Рабига, Зәйнәп Габитовалар”[2].

Олуг әдибебез Фатыйх Әмирхан үзенең “Сәхнәмезнең ун яше мөнәсәбәте белән” дигән мәкаләсендә беренче спектакль нәкъ менә 1903 елда куелды дип күрсәтә. Ф.Әмирханның “татар сәхнәсенең бу дәвере хакында сөйләгәндә Габитовлар гаиләсен гомумән… зикер итми китәргә мөмкин түгелдер” дип аларга, ягъни бу гаиләгә аерым басым ясап әйтүе дә шактый әһәмияткә ия. Язучы Рабигага бер роман язуын, аның геройлары арасында “Шимбә”челәр дә булуын, Рабиганың үзен Нәсимә исемле гимназистка итеп алуын да сөйләгән. Алай гына да түгел Ф.Әмирханның әсәрләрендә очрый торган гимназисткалар һәм башка укымышлылар “Шимбә” кичәләрендә күренгән шәхесләрне искә төшерәләр. Языла башлап та тәмамланмый калган “Урталыкта” исемле романында бу нәрсә аеруча ачык сизелә.

Ф.Әмирхан “Шимбә”челәр белән бергә спектакльләрдә үзе дә катнашкан кеше. Дусты Ризван Алушига 1904 елның 9 февралендә язган хатында ул болай дип күрсәтә: “Студентлар вә гимназист-

[1] Габитова Р. Беренче адымнар // Көрәштәшләр. Казан, 1972. 23 б.

[2] Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан, 2005. 38 б.

калар илә үткән ел башында татар лисанында ике уен уйнадык. Берсе – “Кызганыч бала”, берсе “Гыйшык бәласе”. Мин “Кызганыч бала”да Хәлил, “Гыйшык бәласе”ндә Габделхәмит әфәнде булып уйнадым”[3]. Бераз элегрәк, 1903 елның 22 декабрендә шул ук Р.Алушига язган хатында ул: “Хәзер, иптәш минем эш тәрәкъкыйдә: узган ел син кызыгып йөргән Р.Габитова вә башка гимназисткаларны култыкларыннан тотып йөримез, чөнки студентлар берлә ихтилятым (аралашуым) күп”, – ди[4].

Култыклашып йөрүне укучылар гаепләмәсләр дип уйлыйм. Аны бу чордагы яшьләрнең бер-берсенә нәзакәтле мөгамәләсенең матур бер чагылышы гына дип бәялик.

Рабига Габитовага күпләрнең гашыйк булып, яшерен мәхәббәт тотып йөрүләре хакында олуг тарихчы галимебез (хәзер мәрхүм) Рәфыйк Нәфыйк улы Измайлов: “Аңа өйләнү бик күп зыялы егетләребезнең хыялында йөргән. Әмма Рабига Рус-япон сугышына китәр алдыннан бер егеткә вәгъдәсен биргән булган. “Вәгъдә – иман” дигән ул һәм гомере буе шул сугышта вафат булган сөйгәненә биргән вәгъдәсенә тугры калып ялгыз яшәгән”, – дип сөйләгән иде. Ни кызганыч, ул егетнең исеме никтер хәтеремдә калмаган. Рабига апа хакында язуымны да Рәфыйк ага Измайлов сораган иде.

Рабига Габитовага татарның булачак беренче тарихчы профессоры Газиз Гобәйдуллин да гашыйк була. Тик “вәгъдә – иман”. Рабига тәкъдимне кире кага. Г.Гобәйдуллин соңрак Рабига Казаковага өйләнә. Замандашлары истәлегеннән белгәнебезчә, нәкъ менә Рабига исемле булганы өчен.

Тик керсез күңеле олы мәхәббәтне йөрәгендә йөрткән, рус, француз, татар, гарәп, немец телләрендә иркен сөйләшә ала торган, милләтебезнең йөзек кашы булган бу кыз бала үз гомерендә бәхетле була алганмы соң? Юктыр.

Башта татар тамырына балта чапкан Октябрь революциясе, аның нәтиҗәсе булган гражданнар сугышы, соңрак ачлык фаҗигасе, “сыйныфлар” дип, “халык дошманнары” дип юк ителүгә күпме дучар булган еллар – халкыбыз тормышының иң авыр еллары. Шәхес культы елларында күпме дусларын, туганнарын югалтып, берөзлек-

[3] Әмирхан Ф. Әсәрләр. 4 том. Казан, 1986. 226 б.
[4] Шунда ук. 224 б.

сез куркып, калтырап яшәүләр эчендә Рабига кебек кыз бала бәхетле буламы соң?

Үлеме дә нинди фаҗигале бит. Ул гомере буе Казан мәктәпләрендә укытучы булып эшләгән. Үзе эшләгән мәктәп бинасы яна башлагач, бер укучысын коткарырга дип ут эченә ташланган. Укучысын коткарган, әмма үзенә ут капкан һәм авыр яралардан сәламәтләнә алмаган, үлгән. Бу хәл 1966 елда булган. Бу олы йөрәклелекне бәяләрлек сүзләр таба алмыйм.

Тик шунысы үкенечле. Мин Казан педагогия институтын 1966 елда тәмамладым. Язучылар, затлы шәхесләр белән очрашуларга бик теләп йөри идек. Татар театр сәнгате, тарихы белән тыгыз бәйләнгән, беренчеләрдән булып рус телендә югары белем ала алган татарның мактауга лаек кызы Рабига апа Габитова белән ник бер генә тапкыр очрашырга язмаган булды икән? Аны күреп бер сөйләшү, тормышында булган хәлләрне тыңлау безгә яшәргә, эшләргә нинди гүзәл этәргеч булган булыр иде.

Тарих раслаганча, халыкның бөек шәхесләренә язмыш гаять авыр газаплар, сынаулар һәм җәфалар китерә. Ни өчен икән? Кем белә? Сагыш һәм горурлык белән искә алырга гына кала инде безгә. Киләчәк буыннар да андый шәхесләребезне белсеннәр, онытмасыннар иде.

## ЯЗМЫШЛАРЫН БЕЛҮЧЕЛӘР БАР МИКӘН?

*Бара милләт зәгыйфь, абыныр-абынмас,*
*Сүнә яшьләрдә ут кабыныр-кабынмас.*

*Г.Тукай*

Россиянең XX гасырдагы тарихы да – сугышлар тарихы: рус-япон сугышы (1904–1905), I Бөтендөнья империалистик (1914–1918), Балкан сугышлары (1912–1913), Бөек Ватан сугышы (1941–1945) һәм өстәвенә узган ике революция (1905, 1917). Сугышлар тынган арада төрле сәбәпләр белән үз халкына каршы ут ачу… Ни әйтергә теләгәнем билгеле инде, акылга сыйдырып аклап бетерүе кыен.

Үткән саннарның берсендә шул сугышлар вакытында яралыларга медицина хезмәтен күрсәткән фидакяр җаннарның берсе – татар кызы Тальковская Зөләйха Искәндәр кызының фаҗигале язмышы хакында язган идек. Тик ул да ялгыз түгел, аның кебек үз тормышларын куркыныч астына куеп, фронтларда, лазаретларда ярдәм кулы сузучы кызларыбыз күп безнең.

Армиядә табиблар, шәфкать туташлары, санитарлар булмаса йөз меңнәрчә яралылар яңадан сафка баса алмаслар иде. Сугышта яраланучылар гына да түгел бит әле, төрле авырулар, төрле эпидемияләр белән көрәшү дә алар өлешенә төшкән бәла. Тулы булмаган мәгълүматларга гына карасак та, ис китәрлек: Гражданнар сугышы вакытында Кызыл Армиядә тиф белән 1 миллион 300 мең сугышчы үлгән. Сугыш авырлыкларын ирләр белән бертигез дәрәҗәдә диярлек хатын-кызлар да күтәргән: сугыш уты эчендә дә, тыштарак тылда да. Боларны һәрберебез уйлый белә кебек.

Сугышта яралыларны дәвалау, яңадан сафка бастыру өчен намус белән тырышкан медицина хезмәткәрләре хакында бераз язылды. Соңгы елларда гражданнар сугышында корал тотып ирләр белән бер сафта аклар ягында да, кызыллар ягында да көрәшкән рус кызлары хакында күп кенә язмалар дөньяга чыкты. Ә татар кызлары хакында ник аз соң язмалар? Алар да Россия язмышын үз халкы язмышыннан аерып карамыйча, үзләренеке итеп сафка бастылар ич.

Коллыкка төшсәләр дә, үч сакламаган бит халкым. Илгә афәт килгәндә руслар белән бергә булган, авырлыкларны бергә кичергән. Динебездән, гыйлем-мәгърифәтебездән көчләп аеруга да, хокукларыбыз чикле булуга да карамастан дияр идем.

Менә сугышларда катнашкан табибәләребез дә, шәфкать туташларыбыз да шул язмышларыбызны кичергән кызлар. Гражданнар сугышында алар да аклар ягында да, кызыллар ягында да булдылар. Аларга үрнәк булучыларыбызның – табибәләребез, шәфкать туташларыбыз, санитаркаларыбызның гражданнар сугышына кадәр дә булганлыгы билгеле. Башта күпме каршылыклар кичереп табибә була алган батыр кызларыбызны искә алыйк әле.

Әйтеп үтик, табиблар хәзерләүче уку йортларына рус кызларын алырга да бик ашыгып, колач җәеп тормаган Россия. Бары тик Америка, Франция, Италия кебек илләрнең университетларына хатын-кызларны күпләп ала башлагач кына мәсьәлә уңай хәл ителгән.

1872 елда Россиянең хәрби министры Д.А. Милютин тәкъдиме белән Медико-хирургия академиясе каршында "акушеркалар" курсы ачыла. 5 ел укыганнан соң, курсларны тәмамлаучыларның 25-е Россия-Төркия сугышына җибәрелә. Хатын-кызларның үз-үзләрен аямыйча күрсәткән батырлыкларына һәм медик буларак осталыклар күрсәтүләренә карамастан, курслар 1882 елда Академиядә ябыла һәм Николаев исемендәге Хәрби госпитальгә күчерелә.

Илдә табиблар җитешмәвен дәлилләп күрсәтеп, таләп итә торгач, ниһаять 1897 елда Петербургта махсус Хатын-кызлар медицина институты ачыла. Уку йортына гимназия тәмамлаучыларны һәм "домашняя учительница" дипломына ия булучыларны алалар. Керү имтиханнары да игътибарга лаек, хәзерге БДИ (ЕГЭ) бирүчеләр өчен бигрәк тә кызык булыр төсле. Димәк, башта рус телендә сочинение, латин телендә язылган әсәрнең тәрҗемәсе һәм грамматик анализы телдән, немец яки француз теле буенча, арифметика, алгебра, геометрия, тригонометрия һәм тагын физика, тарих, география фәннәреннән имтихан куелган.

Уку йортына кергән татар кызларының барысы да мәдрәсә күләмендә Ислам дине тәгълиматын да белгәнлекләрен искә алсак, алар белән чагыштырганда күбебезнең шыр надан булганыбызны да танымый булмастыр. Әйтеп китик, институтлар да, курслар да бары

тик рус кызлары өчен генә ачыла. Тик илдәге алдынгы карашлы галимнәр тырышлыгы белән “тулы хокуклы булмаган инородецлар”га да укырга керергә мөмкинлек туа.

Аллаһы Тәгалә ул вакыттагы татар кызларына сокланргыч тырышлык биргән. Иң беренчеләрдән булып, 1891 елда ук Касыйм шәһәре кызы Разия Котлыярова (ире буенча фамилиясе Сөләйманова) югары белемле (дипломлы) табибә булып чыга. Аягы җиңел була аның, шөкер. Октябрьгә кадәр тагын 20 гә якын татар кызы башкалада укып табибә булырга ирешәләр. Аларга укырга керергә җиңел булгандыр дип уйлаудан Алла сакласын.



*Разия Сөләйманова (Котлыярова). Оренбург, 1917 ел*

Сүзебезне Разия ханым Котлыяровадан башлаган идек. Аның булдыклылыгына, тырышлыгына баш имичә калып булмый. Мөселман кызы булгач, уку дәверендә нинди генә каршылыкларга очрамый бу кыз бала. Әмма үз дигәненә ирешә. Императрица Мария Федоровнага хәтле барып җитсә җитә, табибә дипломын алып чыга ала. 1892–1900 елларда Касыйм өязендә эшли, тиф, холера авыруларына каршы көрәш оештыра. Үзе тиф белән авырый, бәхеткә исән кала. 1902 елда Оренбургта яши, хатын-кызлар өчен дәвалау пункты ача, бу вакытта мөселман хатын-кызлары ир врачларга күренә алмыйлар әле, чөнки тәннәре гаурәт. 1904–1905 еллардагы рус-япон сугышы яралыларын карый, дәвалый. Кызыл Хач җәмгыяте аның тырыш хезмәтен билгеләп медаль белән бүләкли.

Халыкка түләүсез лекцияләр оештырып, медицина буенча башлангыч белемнәр бирү, татар кызлары өчен гимназиягә керергә хәзерлек курслары оештыру дисеңме, Оренбург татар хатын-кызлары җәмгыяте оештыруны башлап йөрүе дисеңме – барысы да ул гүзәл

ханым эше. Әле өстәвенә мәктәпләрдә укучы ярлы балаларны бушлай дәвалый, уку йортларын гел тикшереп тора, шәһәр аптекаларында ярлылар өчен даруларны 30% ташлама белән сатуны оештыра. I Бөтендөнья империалистик сугышы вакытында шәһәр лазаретларында яралыларны дәвалый, качакларга ярдәм күрсәтә, сугышка алынучыларның гаиләләренә даими ярдәм күрсәтеп тора. Бу кадәр олы йөрәклелек кайдан, нинди тәрбиядән килде икән бу изге җанга. Бүген дәвалау учреждениеләренә барып, табибларга күренергә куркып, коты очып торган күпме авырулар бар. Разия кебек табибәләр, бу хәлләрне белә торган булса, каберләреннән чыгар иде.

Шушы яхшылыклары өчен 1917 елда Оренбург хатын-кызлар җәмгыяте аның исемендә стипендия булдырып, медицина уку йортларында белем алырга теләгән кызларга ярдәм оештыра. Үзе 1917 елның 1 маенда Мәскәүдә үткәрелгән беренче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда катнаша. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр милләтебезнең азатлыгы, бөтенлеге өчен көрәшә. Урыны җәннәттә булсын.

Язмамда искә алмый булдыра алмаган, тырышлыгы белән сокланып туймаган тагын бер олуг җанлы кызыбыз – Әминә Батыршина. Ул Петербургтагы Югары курсларны 1898 елда тәмамлый һәм Бакуда табибә булып эшли. Биографиясе дә бик кызык.

Ул югары белем алуына Хәнәфи докторга бурычлы (ярдәмче дисәм дөресрәк булыр) була. Батыршин Хәнәфинең этисе Өлек Батыршин 1812 елгы Ватан сугышында, мишәр-типтәр гаскәре сафында катнаша. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен капитан дәрәҗәсе алып кайта. Башкортстанның Эстәрлетамак өязендәге Алагуат авылында яши һәм вафаты да шунда. Әтисенең батырлыгын искә алып булса кирәк, улы Хәнәфине Казандагы 1 гимназиядә казна хисабына укыталар һәм ул укуын дәвам итеп, 1868 елда врачлык дипломы да ала. Оренбург, Ташкент шәһәрләрендә һәм Төркестан хәрби округында гаскәри врач булып эшли. Өйләнмичә картая, әмма үз эшен дәвам итүгә өметләнеп Әминә исемле ятимә кызны тәрбиягә ала. Өмете аклана.

1898 елда Әминә югары белемле табибә булып җитешә. Баку шәһәрендә үзен бик оста белгеч итеп таныту белән бергә, җәмәгать эшләрендә дә актив катнашып китә. Ул – мөселман хатын-кызлар

җәмгыятенең бик актив әгъзасы. Бакуда рус телендә чыккан “Каспий” газетасына әледән-әле мәкаләләр бастыра. Бу газетаның кайбер саннары Казан университетының Н.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклансан.

Әминә Казан белән, милләттәшләребез белән дә аралашкан булса кирәк. Казан хәлләре, татарлар тормышыннан хәбәрдар булып яшәве шуның дәлиле. Казан губернасында әледән-әле кабатланып торган ачлык вакытында “Каспии” газетасында бу хакта белдерүләр бастырып, ярдәм оештыруда даими катнашып торганы күренә. Казанда яшәгән атаклы галимә Гөлнар ханымның (Ольга Сергеевна Лебедева) Римда француз телендә дөнья күргән “Мөслимәләр хөррияте” исемле әсәрен рус теленә тәрҗемә итеп, шул ук “Каспий” газетасында бастыра. 1907 елда бу әсәрнең татарчага тәрҗемәсе “Бәянел-хак” газетасында басылып чыга.

Халкыбызның мондый гүзәл кызларының батырлыкларына сокланып, Петербург, Мәскәү, Казан, Уфа, Оренбург архивларыннан исемнәрен барлап, “Ступени образования до Сорбонны” (Казан, Алма-Лит, 2003) дигән китабымда күрсәтеп чыгарган идем. Китапка кертелгән исемнәр әле тулы түгел. “Бәлки тулыландырып язып чыгучылар булыр әле” дигән өметем көннән-көн киселә бара. Язмышларын барлыйсы иде барысының да. Нинди гыйбрәтлеләре күп бит араларында.

Шул ук табибәлек дипломын Женевада укып алып чыккан Зәйнәп Габдрахманова, Сафия Сыртлановаларның язмышлары, эшчәнлекләре игътибарга лаек түгелме?

Сафия – мәшһүр мәгърифәтче галим Хөсәен Фәезхановның бертуган энесе, язучы, тәрҗемәче Габделгалләмнең оныгы. Немецның фольклорчы галиме фон Мендега кияүгә чыга. Бу галимнең Бөек Ватан сугышында әсир төшкән татарлар янына килеп йөрүе билгеле. Татарча оста сөйләшеп, татар җырларын, мәкальләрен дә язып алуы хакында язылган материаллар бар.

Октябрьдән соң Казан дәүләт университетының медицина факультетына йөздән артык татар кызы укырга дип өметләнеп килә. Аларның күбесе сыйнфый яктан туры килми, чөнки тырыш сәүдәгәр яисә мулла баласы. Күбесен университеттан укырга

кергәннән соң да куып чыгаралар, күбесен укуны тәмамлар алдыннан төрле сәбәпләр белән китәргә мәҗбүр итәләр.

Бу кызларның фаҗигале язмышлары хакында минем яралы йөрәгемнең хәле җитми. Башкаларга әйтеп карасам да, нигәдер, кызыксынучылар күренми. Милләтебезнең байлыгы, горурлыгы бит алар, югыйсә.

Күп кенә районнарда укучылар алдында чыгышлар ясаганда һәрбер милләтнең баласы туганда ук бер тамга белән тууы хакында сөйләгәнем булды. Бу хакта 2017 елның, ялгышмасам февраль аенда, “Московский комсомолец”та да язып чыктылар. Аңнарлык кешегә аңларга була: туганда ук Аллаһы Тәгалә тамга куеп милләтеңне һәм синең шул милләт кешесе буларак өстеңгә төшкән бурычыңны төгәл билгеләп куйган дигән сүз бит инде бу. Ә бүген безнең милләт балалары ни эшли?

Ник хөрмәтебез кимеде үз милләтебезгә? Ник элекке заманда безнең кызларыбыз шулкадәр милләт җанлы булып, милләтебезнең киләчәге хакына тырышканнар соң? Ник онытабыз икән аларны? Әмма алар сагындыра, бүген безгә алар җитми.

## МИЛЛӘТ, КИЛӘЧӘК ХАКЫНА

XX йөз башында татар хатын-кызлары хәрәкәтенең аяз күгендә кабатланмас йолдыз булып балкыган, халкыбызның данын тарих мәйданында, ерак илләрдә шаулаткан кызларыбыз бар. Аларның исемнәрен олы хөрмәт белән атап үтәм: Чистайда туып үскән Өммегөлсем Камалова, Петербургтан Рокыя Юнысова, Ташкенттан Мәрьям Якупова, Ростовтан Мәрьям Поташева. Дүртесе дә Петербургтагы Хатын-кызлар югары педагогия курслары студентлары. Дүртесе дә Балкан сугышы вакытында төрек кардәшләребезгә үзләре теләп ярдәмгә баралар һәм “Һиляле Әхмәр” (“Кызыл Ай”) хәрби лазаретларында шәфкать туташлары булып эшлиләр.



*Балкан сугышы шәфкать туташлары*

Петербургта бу чорда укучылар арасында татар яшьләре аз булмый һәм аларның илдә барган вакыйгаларда катнашулары да, иҗтимагый көрәшләргә тартылулары да мәгълүм. Казан губерна жандармерия идарәсе башлыгы Калининның Петербург охранкасына җибәргән донесениесендә мондый юллар бар. “Петербургта укучы мөселман яшьләре түгәрәкләргә оешалар икән… Барысы да мәгърифәтчелек аркылы мөселман яшьләрен милли азатлык рухында тәрбияләргә хыялланалар…”[1].

1912 елда Петербургның җир идарәсе бинасында уздырылган җыелышка укучы татар яшьләрен (шул исәптә кызларны да) чакыралар. Биредә “Нур” газетасы журналисты Кәбир Бәкер Балкан сугышында җиңелүгә дучар булган Төркия мөселманнарына ярдәм итәр өчен татар яшьләре төркеме туплау кирәклеге хакында сөйли. Чыгышының ахырында шәфкать туташларыннан да бу эштән баш тартмауларын үтенә. Югары курсларда укучы дүрт татар кызы Төркиягә барырга ризалык бирә. Исемнәрен тагын бер мәртәбә әйтеп үтәм: Педагогия курсларының физика-математика бүлеге студенткасы Гөлсем Камалова, Психико-неврология курсларының педагогика бүлегеннән Рокыя Юнысова белән Мәрьям Паташева һәм Медицина курсларыннан Мәрьям Якупова.

Алар 1912 елның 7 ноябрендә изге ният белән юлга чыгалар. Одесса шәһәренә җиткәч, Оренбургта чыга торган “Вакыт” газетасы нәшире, мөхәррире, язучы, галим Фатыйх Кәрими каршы ала. Бу очрашу кызларның бәхетенә булган дип уйлыйк. Чөнки Ф.Кәрими Төркиядә аларга ярдәм итеп, безнеңчә әйтсәк “күз-колак” булып йөрүне үз өстенә ала. Россия илчелегенә алып барып килүләрен дә рәсмиләштерә. Әлегә төрек телен камил белмәгән кызларны княгиня Елизавета Николаевна Оболенская ачкан хастаханәгә билгеләр. Татарның иң зыялыларыннан булган Фатыйх Кәриминең кызларга күрсәткән хөрмәтле мөнәсәбәте Ислам дөньясында хатын-кызның нинди югарылыкта булырга тиешлеген дә күрсәтү әле ул.

Кызларыбыз да сынатмый. “Истанбул мәктүбләре” дигән хезмәтендә Ф.Кәрими болай дип яза. “Хастаханә һәйәтләре вә табиблар безнең Русия мөселманнарыннан гаять разый вә мәмнүннәр.

[1] ТР ДА. 199 ф. 1 тасв. 948 эш. 85 б.

Безнекеләр үз мәсърафлары (чыгымнары) илә килеп шулкадәр тырышып хезмәт итәләр”[2].

Кызлар шәфкать туташы булып эшләү белән генә чикләнмиләр. Төркиянең җәмәгать тормышында актив катнашалар һәм хәтта хатын-кызлар хәрәкәтен оештыруда башлап йөрүчеләр булалар. Фронтка ярдәм максатында хатыннар арасында иганә җыюга өндәп, “Мөдәфәгаи миллия” (“Милләтне саклау”) оешмасына мөрәҗәгать белән чыгалар. Үзләрен сугыш мәйданына якын кыр лазаретларына җибәрүләрен сорыйлар. Аларның һәр чыгышы, һәр адымы төрекләр арасында соклану, яклау, хуплау белән каршылана. Аларны төрле җәмгыятьләр үзләренә чакыралар, чыгыш ясауларын үтенәләр. Мисал өчен, 12 ноябрьдә “Шәкертләр җәмгыяте” чакыруы буенча оештырылган очрашуда “Петербургтан килгән Кәбир Бәкер, Шәриф Әхмәтҗан, Фатыйх Рәхимов һәм “Төрек йурды” мөдире Йосыф әфәнде Акчура катнашты”, – дип яза Ф.Кәрими. Гөлсем биредә чыгыш ясап, Россиядәге уку тәртипләре, “мәгариф юлындагы хәрәкәт хакында мәгълүмат бирә”[3].

Гөлсем үзе төрек хатыннары җәмгыяте “Тәгаләи нисван”га баргач алган тәэсирләре хакында “Болар хакында һәммәсен язсам, диңгезләр кара, җир йөзе кәгазь булса да җитмәс… Ишектән без барып кергәч, һәммәсе аякка калыктылар вә алкышлап безне каршыладылар…” – дип яза[4].

1913 елның ноябрендә аның Истанбул университетында уздырылган җыенда 6 мең төрек хатын-кызы алдында ясаган чыгышы, сөйләгән сүзләре бүгенге көндә дә кыйммәтле.

“Мин бу мөнбәргә сезгә вәгазь әйтү, акыл өйрәтү өчен менмәдем, – ди ул. – Бәлки сезгә Русиядәге миллионнарча туташ вә сеңелләребезнең сәламен ирештерү, мондагы хәсрәтләр өчен аларның да күзләре яшьле, калебләре канлы буларак, сезнең кайгыларыгызны уртаклашуларын белдерер өчен чыктым.

…Ханымнар! Бүген гайрәт вә тырышлык күрсәтә торган көнебездер. Тарихларда күренәдер ки – Ватан вә милләтнең хәле мөшкеллеккә төшкәч, аларны күп мәртәбәләр хамиятле ханымнар вә

---

[2] Мирас. 2001. №3. 103 б.

[3] Мирас. 2001. №10. 86 б.

[4] Шура. 1913. №7. 203–204 б.

галиҗәнаб аналар коткарганнар. Без дә алардан үрнәк алыйк, гыйбрәтләник! Кулдан килгәнне эшлик вә киләчәк нәселләрнең ләгънәтләреннән котылыйк!”

Кайтыр көннәре якынлашкач, Ф.Кәрими кызларны мәчеткә алып барырга рөхсәт ала. Мәчеткә төрек солтаны җомга намазына йөри икән. Кызларны хөрмәтләп, солтан кулын күтәреп сәламли. Баш вәзир Мәхмүд Шәүкәт паша барысы белән кул биреп күрешә һәм “Мөселман хатын-кызларының зур калебле, галиҗәнаб икәнлеген сез гамәлдә күрсәттегез”, – дип күп рәхмәтләр әйтә. Кызлар үзләре хакында иң матур тәэсирләр, гүзәл истәлекләр калдырып, Төркия белән саубуллашалар. Тик Россиягә кайткач, аларны курслардан чыгаралар.

Бу кызлар үзләре нинди гаиләләрдә, нинди тәрбия алып үскәннәр соң? Алар хакында бераз искә төшерик. Г.Камалова 1889 елда Чистайның Россия күләмендә мәшһүр ишаны, күренекле мәгърифәтче һәм II гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтзакир Габделваһаб улы Камалов гаиләсендә туа. Закир Камалов 1882 елда үз акчасына Чистайда зур гына мәдрәсә сала һәм шул мәдрәсәнең 46 ел буе мөдәррисе булып хезмәт итә. Тырыш хезмәте өчен зур көмеш медаль белән бүләкләнсә дә, гомеренең соңгы елларында ачыктан-ачык татар халкы мәнфәгатьләре өчен көрәшкәне өчен хакимият тарафыннан эзәрлекләнүләргә дучар булган галим. Бу мәдрәсәдә укып белем алган Риза Фәхретдин, Фатыйх Кәрими, Гаяз Исхакый һ.б. исемнәрен генә атау да мәдрәсәнең тоткан юлын ачык аңлата төсле.

Өммегөлсем Мөхәммәтзакир кызы хакында язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллованың “Язмыш җиле” романы чыкты[5]. Бездә генә түгел, әсәрнең Төркиядә дә басылып чыгуы һәм яратып укулуы күңелле вакыйга. Укучыларыбызга Гөлсемнең тормыш юлын шул китаптан укып белергә тәкъдим итәм. Кызларның башкалары хакында билгеле булган кайбер истәлекләрне язып үтәм.

Инде югарыда күрсәткәнчә, Петербург ахуны Мөхәммәтзариф Юнысов кызы Рокыя, гимназия тәмамлагач, Бакуда Ә.Тагиевның кызлар мәктәбендә ике ел укытучы булып эшли. 1912 елда Психоневрология курсларына (институтына) укырга керә һәм Төркиядән кайткач, 1914 елны тәмамлый.

[5] Туфитуллова Р. Язмыш җиле. Казан: Татар. кит. нәшр., 2020.

Инде белгәнебезчә, татар сәүдәгәрләре, мөгаллимнәр чит ил уку йортлары белән танышып, алардагы укыту эшләре торышын өйрәнеп мәдрәсәләрне үзгәртеп кору эшенә керешәләр. XX гасыр башында сәүдә эшләрен киңәйтү генә түгел, яңа завод-фабрикалар ачу, алар өчен җитештерү җиһазлары әзерләү кирәклеге көннән-көн ныграк сиздерә башлый. Шушы максатта дин гыйлеме белән беррәттән дөньяви фәннәр дә заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә укытылырга тиешлеге дә аңлашыла төсле. Ниһаять 1910–1912 елларда Мөхәммәтшәриф Яушевның тол хатыны Гайния Яушева Троицк шәһәрендә (барлыгы 40 мең кеше яшәгән) заманча укытучылар хәзерләү максатында яңа белем йорты салдыра, төрле яклардан белгечләр чакыра. Уку йортының программалары, уставы Оренбург уку округында тикшерелә һәм 1915 елның 19 маенда гыйлем йорты ачырга рөхсәт алына.

Дарелмөгаллиматның беренче директоры безнең сөекле кызыбыз Рокыя Юнысова була. Уку йортын ачканда ул сүзен саф татар телендә “Балалар – безнең киләчәгебез. Балалар нинди булса, киләчәгебез дә шундый булачак. Балаларның бездән иң ләтыйф (йомшак, нәфис), иң нәзек мөгаләмә көтәргә хаклары бар”, – дип башлый. Аның янәшәсендә Германиядә белем алган ирле-хатынлы З.Рахманкулов, Ф.Бакиров, К.Рәсүловлар басып торалар. Дин белемен укытыр өчен Иж-Буби мәдрәсәсен таратканда кулга алынудан котыла алган Мөхлисә Бубины да Гайния ханым үзе чакыра. Белем йортына беренче елда 62 укучы (студент) кабул ителсә, соңрак аларның саны 179 га җитә. Укучылар арасында Троицкидан тыш Ташкент, Уфа, Петропавловск, Атбасар һ.б. шәһәрләрдән килүчеләр күп була.

Укытыла торган фәннәр дә игътибарга лаек: Коръән, ислам дине тарихы, татар, гарәп, рус телләре, география, табигать белеме, арифметика, алгебра, геометрия, гомуми тарих, рус һәм татар тарихы, анатомия, гигиена, физика, химия, дидактика, педагогика тарихы, методика, матур язу, рәсем, кул эшләре, йорт тоту эшләре, музыка, җыр һәм әхлак дәресләре. Әмма бу уку йортының бәхете кыска була. Яңалыкны күреп, күзәтеп торган түрәләрнең эчен пошырып торган белем йорты Октябрьдән соң элеккечә яшәүдән туктый. Бу шәһәрдә калса, Төркиядә (чит илдә) булган, югары белемле

мулла кызына ни буласы билгеле инде. Рокыя Троицкидан китә. Гомере дәвамын олуг рәссам-скульпторыбыз Бакый ага Урманче истәлекләрендә күрәбез[6]. Рокыя Троицкидан Казанга килә, дип яза Бакый ага. Соңыннан Төркестан ягына барып, Нугай Курганда[7] яши. 1974 елларда исән иде әле. Кайда яшәсә дә, укытучы һөнәрен ташламас ул милләтебез кызы дип уйлыйсы килә.

1887 елда Ташкентта Исмәгыйль сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килгән Мәрьям Якупова үсеп җиткәч татар мәктәбендә һәм рус гимназиясендә укый. 1910 елда Петербургта Медицина курсларына кабул ителә. Төркиядән кайткач, укуын дәвам итә һәм тәмамлап Ташкентка кайта һәм шунда ук табибә булып эшләү белән бергә, актив җәмәгать эшенә керешә. Аңа үзе кебек тынгысыз җанлы татар мөслимәләре Сәгадәт Еникеева, Әминә Терегулова-Яхина, Заһидә Бурнашева (Гыйффәт туташ) булыша. Нәтиҗәдә 1920 елда Ташкентта беренче Акушерлык техникумы ачыла һәм Мәрьям 1927 елга кадәр шушы уку йортында укыта. Бер үк вакытта Үзбәк хатын кызлары институтында да курслар алып бара. Соңгы эш урыны – 1 нче поликлиника булган икән. (З.Бурнашева (Гыйффәт туташ) истәлегеннән).

Үзбәкстанның мактаулы табибәсе татар кызы Мәрьям Якупова 1971 елда бакыйлыкка күчә. Әйтеп үтик, – Бакый ага Урманче Мәрьям Якупова һәм аның гаиләсе белән таныш булган икән[8].

Мәрьям Рәхмәтулла кызы Поташева хакында мәгълүмат бик аз. Ул Төркиядән кайткач, Психоневрология институтында укуын дәвам иттерә. Ике ел (1913–1914) буе Г.Тукай исемендәге стипендия алырга лаек дип табыла[9]. Институтны уңышлы тәмамлый. Үзенең

[6] Бакый Урманче: шәхес һәм иҗат (шәхси архив фондыннан) / төз., гарәп шрифт. текст, гамәлдәге язуга күч., кереш мәкалә авт. Зөфәр Мөхәммәтшин. Казан: Рухият, 2003. 136–137 б.

[7] Бүгенге Үзбәкстан республикасының Ташкент өлкәсе Ахангаран районы Нугай Курган поселогы.

[8] Бакый Урманче: шәхес һәм иҗат (шәхси архив фондыннан) / төз., гарәп шрифт. текст, гамәлдәге язуга күч., кереш мәкалә авт. Зөфәр Мөхәммәтшин. Казан: Рухият, 2003. 133, 137 б.

[9] Баһаветдинова Х.З. Мөселман хәйрия җәмгыятьләре тарихыннан (Г.Тукай исемендәге стипендиатлар) // Гасырлар авазы–Эхо веков. 2021. №2. 111–112 б.

истәлекләрендә Бакый ага Урманче 1928–1930 елларда Мәрьямнең Казанда яшәвен искә ала. “Ире Габдрәшидев Татарстан нәшриятында бухгалтер булып эшли”, – дип күрсәтә[10].

Кызларыбыз хакында язылган мәгълүматлар аз. Шунысы күңелне әрнетә.

Менә шулай. Гомерем буе мине сокландырган, тормышымның авыр сәгатьләрендә язмышларын укып гыйбрәт алырга этәргән татар кызлары хакында тагын бер язмам бу. Шунысы куанычлы, XX йөз башында гыйлем белән талантның кадерен белгән, халык аңын яктырту өчен көчен кызганмаган шәфкатьле затларыбыз ярдәмендә меңнәрчә кызларыбыз мәгърифәт иясе булганнар. Язарга иде алар хакында, алар безнең горурлыгыбыз бит. Ни кызганыч, бу шәфкатьлелекне тормышның хәзерге бизмәне белән үлчәп, аңлатып кына булмый.

[10] Бакый Урманче: шәхес һәм иҗат (шәхси архив фондыннан) / төз., гарәп шрифт. текст, гамәлдәге язуга күч., кереш мәкалә авт. Зөфәр Мөхәммәтшин. Казан: Рухият, 2003. 137 б.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МӘГЪРИФӘТЧЕ КЫЗЫ ФАТЫЙХА АИТОВА

Татар хатын-кызларына мәгариф өлкәсендә күрсәткән игелекле ярдәме тиңдәшсез булган Фатыйха Габделвәли кызы Яушева-Аитова хакында күпме сөйләсәк тә, язсак та артык булмас.



*Фатыйха Аитова гаиләсе белән. 1914 ел*

Ни кызганыч, Фатыйха ханым хакында язылган мәкаләләремдә аның туган елы ялгыш 1866 ел дип күрсәтелеп килде. Ниһаять, Троицк һәм Чиләбе шәһәрләре архивыннан дөрес мәгълүматлар ала алдык. Аларда Фатыйха ханымның тууы 1869 елның 5 гыйнварында, ә Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитов белән никахы 1887 елның 1 нче маенда булды дип язылган. Бу дөреслекне табуда күрсәткән ярдәме өчен язучы һәм тәрҗемәче Вера Хәмидуллинага олы рәхмәтемне белдерәм.

Фатыйха апаның туган халкына күрсәткән игелеген хәзерге тормышның гадәттәге бизмәне белән үлчәп, күнегелгән бәһаләр

беләп бәяләп тә, аңлатып та булмый. Бу изге күңелле хатынның кадерен, бөеклеген ачып бирә алмасам, рухы мине кичерсен иде, дигән теләктә калам.

Инде белгәнебезчә, Фатыйха апа чыгышы белән борынгы Яуш морза нәселеннән. Үз нәүбәтендә Яуш морзаның 1552 елда Казан шәһәрен Явыз Иван гаскәреннән саклаучылар арасында булганы да ачык билгеле. Яушның токымы Гайсә Йосыф улы Троицк каласына Татарстанның хәзерге Әтнә районы Иске Мәңгәр авылыннан килеп урнашкан икән. Гайсә үзе дә, балалары Әхмәтҗан, Закирҗан, Мөхәммәтҗан, Хәкимҗан, Мөхәммәтлатыйф, Шакирҗаннар да бик уңган, гайрәтле эш сөючән кеше булганнар. Аларның үз тырышлыклары белән нинди зур дәрәҗәләргә ирешеп, ничек мал табулары да, ничек милләтебезнең киләчәген кайгыртып үз малларыннан даими өлеш чыгарып торулары тарихыбызда язылган[1]. Шушы мөхтәрәм затларыбыздан Әхмәтҗан Яушевның улы Габделвәли, ягъни Фатыйха апаның әтисе һәм аның изге гамәлләре хакында төрки дөньяның күренекле галиме, мәгърифәтче һәм тарихчы Габделбари Баттал язмаларыннан укып белергә мөмкин[2].

Сүзебез мәгариф тарихының алтын баганасы булырдай Фатыйха Габделвәли кызы Яушева-Аитова хакында иде бит әле.

Матурлыгы, уңганлыгы белән күпләрне сокландырган кыз Казан бае Сөләйманга чыкканда бары бер шарт куя: гаиләдән приданга биреләчәк акчага татар кызларын укытыр өчен заманча итеп мәктәп салдырырга һәм Фатыйхага шул мәктәптә үзе теләгәнчә җитәкчелек итәргә комачауламаска. Моңа кадәр өч тапкыр өйләнеп, өч хатыны да бала тудырганда үлгән Сөләйман шунда ук риза була. Сөләйман Мөхәммәтҗан улы Аитов Казанның эре сәүдәгәрләреннән берсе. Шуңа күрә сәүдәгәрләр банкының идарә әгъзасы, 1897–1901 елларда шәһәр Думасы гласные, өстәвенә танылган иганәче дә. Ятим балалар йортларына даими ярдәм күрсәтеп, Бишбалта бистәсе мәчетен төзүгә дә, ваба белән авырган кешеләр өчен хастаханә төзүгә дә зур чыгымнар тоткан кеше. 1896 елда Казан

[1] Ислам на Урале. Энциклопедический словарь. Вып. V. М.-Нижний Новгород, 2009. С.415–418.

[2] Габделбари Баттал – Габдулла Баттал-Таймас: фәнни-популяр җыентык / төз.: Заһидуллина Д.Ф. Казан: Җыен, 2023. 294–307 б.

университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы булып торуы Сөләйман Аитовның мәгариф өлкәсендә дә киң мәгълүматлы зыялы булуы хакында сөйли.

Әйтеп үтим, Фатыйха белән Сөләйманның туенда ата булып олуг галимебез Шиһабетдин Мәрҗани утыра. Фатыйха гомер буе Шиһабетдин хәзрәтне үзенең рухи атасы итеп санаган.

Фатыйха апа татар кызларына гыйлем бирү белән бергә югары әхлак тәрбиясе бирүне, киләчәктә милләткә хезмәт итүчеләрне хәзерләргә омтылган. Гади акыл белән генә бәһаләп булмастай эш бу. Бу изге эшен 1897 елда Казанның Сукно бистәсендә татар кызлары өчен башлангыч мәктәп ачудан башлый ул. Шиһабетдин хәзрәт киңәше белән ярлы, ятим кызлар күбрәк тартылганын күрсәтеп китик. Чөнки мәктәп кызларга төрле һөнәрләр өйрәтүне күздә тотып ачыла. Бу эшнең мөһимлеген, кирәклеген аңлатып язган үтенечләре архивта сакланган әле.

1909 елда мәктәп дүртъеллык һәм 1914 елда сигез еллык итеп үзгәртелә.

Аитова мәктәбе хөкүмәт органнары каршында дини башлангыч мәктәп санала. Рөхсәт бирелгәндә дә дин сабаклары гына укытылырга тиеш дигән шарт куела. Фатыйха апаны француз гувернанткасы тәрбияләсә дә, ислам дине кануннарын кечкенәдән канына сеңдергән, затлы нәсел тәрбиясе алган зыялы. Мәктәбендә намаз укыр өчен намазлыклар җәелгән махсус бүлмә дә булдырылып, һәрбер укучы кызга намаз уку мәҗбүри булуы да шул хакта сөйли бит инде.

Әмма ләкин заман кешеләргә башка таләпләр дә куйган. Дин белән бергә дөньяви фәннәр өйрәнү кирәклеге акылы төзек һәркемгә ачык аңлашылган. Шуңа күрә мәктәптә, оешкан көненнән алып, дөньяви фәннәр дә укытыла башлый. Ә инде мәктәпне бик еш тикшереп йөдәткән инспекторлар килгәндә, укучы кызлар дөньяви китапларны бик тиз генә яшерергә дә өйрәнгәннәр. Ана теле, гарәп телләре белән беррәттән, мәктәптә француз яки немец теле өйрәнүне дә кирәк тапкан Фатыйха апа. 1913 елны француз теле укытыр өчен ул Петербургның атаклы мулласы Садретдин хәзрәт кызын – Бестужев курсларын тәмамлаган һәм Казанның атаклы табибы Ис-

мәгыйль Усманов белән яңа гына никахланган Гөлгамбәр ханымны чакырган.

Фатыйха апа укыту эше яхшы сыйфатлы булсын өчен күрше Ләбибә “Хөсәения” мәдрәсәсенең дә, 1911 елга кадәр иң алдынгылардан булган “Иж-Бубый” мәдрәсәсенең дә эш алымнарын ныклап өйрәнгән һәм үз мәктәбендә уку-укыту өчен бөтен шартларны булдыруга бар көчен куя алган. Ул укучы кызларга тормышка яраклы һөнәр бирү турында да ныклап уйланган. Казанның атаклы ашсу осталарын мәктәп укытучыларына үзләре генә белгән аш-су хәзерләү серләрен өйрәтергә чакырган, ә алар бу серләрне укучыларга өйрәткәннәр. Кул эшләренә өйрәтү мөгаллимәсе булып Шумкова һөнәр гимназиясен тәмамлаган Вера Сергеевна Моисеева эшләгән. Һөнәр белеме буенча мәктәптә имтихан биргәннән соң, кызлар Казан һөнәр управасына барып сынау үткәннәр һәм аларга “Тегү остасы” дигән исем һәм документ бирелгән.

Җыр-музыка өйрәтүгә дә игътибар ителә мәктәптә. Җыр дәресләрен биредә намуслы хезмәте өчен соңрак, Совет власте елларында, Ленин ордены белән бүләкләнгән Оркыя Мөштәриева алып бара. Аның хезмәт җимеше булган бары ике генә талантлы затларыбызны – Мәрьям Рахманкулова белән Сара Садыйкованы искә алып үтим. Рухлары шатлансын.

Мәктәптә кара такта, парталар куелган, стенада карта эленеп торган. Дәресләр расписание нигезендә алып барылган һәм аларны үткәрү өчен махсус бүлмәләр җиһазландырылган. Уку елы ахырында, тантаналы шартларда, имтиханнар үткәрелгән. Аларга шәкертләр генә түгел, ата-аналар һәм шәһәрнең мөхтәрәм затлары да чакырылган.

Мәдрәсәнең бай китапханәсе дә булган. Аны татар, рус, гарәп, фарсы, төрек телендәге әдәби әсәрләр, Россиядә һәм чит илләрдә басылып чыккан газета-журналлар тәшкил иткән. Укучылар махсус формадан, ягъни куе көрән күлмәк, кара алъяпкыч, ак яулыктан, ә бәйрәм көннәрдә ак алъяпкыч һәм калфактан йөргәннәр. Дөрес, бу формалар да гадәткә җиңел генә кереп китә алмый. Ул вакытта да, хәзерге бай хатыннар кебек, кызларын ярлыраклар белән бертөсле кием кидерүгә каршы чыгучылар булган. Фатыйха апа бу очракта акыл белән эш иткән. Гает бәйрәмендә кызларны үз өенә эниләре

белән бергә кунакка чакырган һәм “Сөләйман абзыегызның сезгә гает бүләге” дип форма өчен кирәкле материалны шунда өләшкән. “Мәктәпкә шул өс-баш белән йөрерсез”,– дигән. Казанның зур бае биргән бүләк булгач, беркем дә баш тартырга кыймаган инде. Шулай форма тегелгән. Мөгаллимәләр зәңгәр күлмәктән һәм энҗеле калфактан йөргәннәр. Мәктәпнең даны арта, абруе үскәннән-үсә барган.

Мәктәптә уку түләүле булуын искәртеп китәм. Ярлы, фәкыйрь кешеләрнең балаларына ярдәмне үзе оештырган Фатыйха апа. Ярлырак балаларга мәктәптә уку әсбаплары, көн саен сөт бушлай бирелгән, кайберләре уку өчен түләүдән азат та ителгән әле.

Фатыйха Аитова укучы кызларны ил, халык тормышына битараф булмаска, ә хәлдән, кулдан килгәнчә җәмәгать эшләренә дә катнашырга өйрәткән икән. Шуларга мисал итеп, кызларның ак чәчәкләр ясап, туберкулез белән авыручыларга ярдәм йөзеннән, урамнарда шул чәчәкләрне сатып йөрүләрен, ә Беренче бөтендөнья империалистик сугышы башлангач, фронтка җибәрер өчен эчке киемнәр, кечкенә капчыклар һәм янчыклар тегү эшенә тартылганнарын искә алам. Беренче тапкыр җибәрелгән шундый бәләкәй капчыклар эченә 1 кадак шикәр, 1 әчмуха чәй, ярты кадак сабын, 1 тартма папирос, 1 кәгазь инәләр, 1 кәтүк җеп куелган, дип күрсәтә “Сөембикә” журналы[3].

Сугыш вакытында Фатыйха ханымның мактап искә алырлык тагын бер фидакарьлеген – Казанда 1914 елда мөселман яралылары өчен махсус хастаханә ачуда башлап йөрүен яза “Сөембикә”: “Фатыйха Аитова, Зәйнәп Хәсәниләр хатыннарның мәҗлесләрен оештырып иганә акчалары җыюны башлап җибәрделәр. Бик тиз арада җыелган акчаларга хастаханә өчен 50 койка, һәр койкага 3 пар эчке кием, 2 җәймә, 3 мендәр тышы, 3 сөлге, 1 одеал, 1 халат, йомшак туфлилар, кружка, кулъяулык һәм башка вак-төякләр әзерләнде. Фатыйха ханым хәтта бик матур чигүле намазлык һәм тәсбих та куйды. Әйберләр Гайшә Юнисова һәм Зәйнәп Хәсәниләр йортында тегелде.囗Эштә иң якын ярдәмчеләр булып Хөршидә Килдешева, Әсма һәм Сара Даутовалар, Нәфисә Юнисова, Әсма Юзиевалар

[3] Сөембикә. 1914. №1. 12 б.

торды"[4]. Хастаханә бик тиз генә ачылган һәм аңа табиблар итеп Петербург Хатын-кызлар медицина югары курсларын тәмамлап диплом алган Суфия Коләхмәтова, киләчәктә татарның иң шөһрәтле табибы булып танылачак Әбүбәкер Терегулов һәм шәфкать туташлары итеп Мәрьям, Гайшә Саиновалар яхшы хезмәт хакы белән куелалар[5].

Кызларның, гает бәйрәмнәрендә байлар йортына барып, Коръән укуларына да каршы килми Фатыйха апа. Киресенчә, матур тавышлы, оста укучы кызларны үзе үк тәкъдим иткән әле. Коръән укыган өчен бүләкләр кызның үзенә, ә сәдака акчалары мәктәп файдасына булган.

Мәктәпнең даны еракларга тарала. Анда инде Казаннан гына түгел, күрше шәһәрләрдән дә килеп укырга теләүчеләр арткан. 1913 елда ук укучылар саны 200дән артып киткән. Читтән килеп укучылар өчен мәктәп янында пансион ачылган.

Җәй җитү белән Фатыйха Аитова укучыларын Казан тирәсенә ялга алып чыга торган була. Бу эшкә шәһәр байларын да тарта, алардан җигүле атлар сорый. Аитовларның Кабан күле буендагы матур дачаларында укытучы, укучы кызлар өчен күңелле ял көннәре оештырыла. Шундый ялларның берсендә укучылар күренекле әдип Фатыйх Әмирхан белән очрашалар. Габдулла Тукай, Фатыйх Әмирхан Аитовларның Исмәгыйль исемле уллары белән якын дуслар булуын әйтеп китсәм дә урынлы булыр төсле.

Мәгариф эшендә гел югары үрләргә омтылган Фатыйха апа үз укучыларын тагын да зуррак сыйныфларда укыту һәм бигрәк тә Европа гимназияләре кебек уку йорты ачу теләге белән яна. Шуңа күрә ире Сөләйман белән чит илләргә сәяхәт кылырга чыкканда бергәләп Берлин, Прага, Мюнхен һ.б. шәһәрләрдәге кызлар гимназияләренә керәләр, программалар, уку методикасы белән танышалар. Күп кенә экспонатлар һәм уку әсбапларына кадәр алып кайтырга тырышалар. Әмма гомер буе татар халкын наданлыкта тотарга бөтен тырышлыгын куйган патша хакимияте эшкә гел аяк чала. Казан чиновникларыннан рөхсәт ала алмагач, Аитова олы улы Исмәгыйльне алып (улы Исмәгыйль, хәзергечә әйтсәк, югары белем

[4] Сөембикә. 1914. №1. 12 б.

[5] Шунда ук.

алган егет) Петербургка бара. Анда Мәгариф министрлыгына, Дәүләт Думасы депутатларына кадәр барып җитә. Зур мәшәкатьләр белән Казанда татар кызлары өчен хосусый урта мәктәп ачарга рөхсәт ала. Ниһаять, татарның әле ир балаларына да гимназия ачылмаган вакытта, 1916 елның 29 октябрендә бик матур бәйрәмчә шартларда татар кызлары гимназиясе ачыла. 1915 елда Фатыйханың Троицкида яшәүче туганы Гайния Яушева да кызлар өчен мөгаллимәләр хәзерли торган югары мәктәп ача.

Уку йортларының чын бәһасен андагы укытучылар билгели. Гимназиягә укытучылар чакырганда, Фатыйха апа зур таләпчәнлек күрсәтеп, аларга зур өметләр баглаганын яшерми. Мәктәп ачылганнан бирле бергә эшләп сыналган дусты Зәйнәп Хәсәни гимназиядә дә укыту эшләре попечителе вазыйфасын башкара. Биредә Казан университетын тәмамлаган Газиз Гобәйдуллин – тарих, Казан Югары курсларында укучылардан Мәрьям Гобәйдуллина – география, Мәрьям Акимбитова – рус теле, Сорбонна университетын тәмамлаган Сара Шакулова – математика, татар теле дәресләрен күренекле әдибә Маһруй Мозаффария, табигать фәнен Мәрьям Мөштәриева, дин сабагын Нәкыя Гайнуллина һәм педагогия өлкәсендә танылган башка белгечләр алып бара.

1917 ел вакыйгаларының да үзәгендә булган Фатыйха апа. 1917 елның апрелендә үткәрелгән Бөтенроссия мөселман хатыннарның беренче корылтаенда да, укытучылар корылтайларында да актив катнаша. Еллар үткәч, корылтайларда никадәр өмет белән сөйләнгән сүзләрнең тормышка ашмауларын уйлап, йөрәге телгәләнгәндер аның.

Фатыйха Аитова гимназиясен патша Россиясе шартларында берүзе ача алган. Шуның белән бәхетле. Татар милли университетын без мөстәкыйльлек дип аталган чорда йөзләрчә кеше тырышып та ача алмадык. Мәгариф өлкәсендә бүгенге көннәрдә дә Фатыйха Аитовага тиңнәр булмавы нәкъ менә шул шартлар белән бәйле түгел микән?

Фатыйха Аитованың куәтле таланты таң калдырса, яклау-саклауга мохтаҗ булган җан сабыйлыгы тетрәндереп җибәрә. Аның фани дөньядагы гомеренең соңгы көннәренә ишарә итеп әйтүем бу.

Совет власте урнашу белән алар “хокуксыз”ларга әйләнә. Бар мөлкәтләре тартып алына. Гимназия икенче баскыч совет мәктәбе итеп игълан ителә. Фатыйха апага анда урын бетә. Югары белем алырга өлгермәгән уллары Якубка да гали уку йортларының ишеге ябыла. Ишле гаилә булып, гөрләп яшәгән йортлары тартып алына. Алар кодалары янына сыенырга (уллары Йосыф хатыны Мәрьямнең әти-әниләре), аларның бер бүлмәле кечкенә квартираларында яшәргә мәҗбүр булалар. Соңрак, бу кадәр җәберләргә түзә алмыйча, чит илгә китәргә теләп Омскига кадәр баралар да, язмышка буйсынып, тагын әйләнеп кайталар.

Боларга өстәп, Татарстанда коточкыч ачлык башланганын да искә төшерсәк, гаиләнең нинди аяныч хәлдә калуын аңлау кыен түгел. Сөләйман аганың рухы җәннәттә булсын, ачлык кими башлаган 1922 елны бакый дөньяга күчә ул.

Фатыйха апа бәхетен югалткан Казаннан Бакуга күчеп китә. Улы Якуб белән килене Мәүлүдәне электр техникумына укырга урнаштыра. Бакуда ничек яшәүләре мәгълүм түгел, аннан кайткач әле бер улының, әле икенчесенең гаиләсендә яшәргә мәҗбүр булган. Чөнки Совет власте аңа бер тиен дә пенсия билгеләмәгән.

Икенче Бөтендөнья сугышы башланганда ул Мәскәүдә улы Якуб янында була. Шул ук 1941 елда аңа инсульт була, ул параличлана. Улы-килене эвакуациягә китәләр. Бер як гәүдәсе бөтенләй хәрәкәтләнмәгән Фатыйха апаны Казанга, репрессияләнгән улы Йосыфның хатыны Мәрьямгә кайтаралар. Бу вакытта Фатыйха апаның уллары Ибраһим да, Йосыф та Сталин лагерьларында мәхбүс булып яшәргә мәҗбүр. Әле ничек үзе репрессияләнүдән котылып калды икән?

“Фатыйха дәү әни 16 ай буе безнең кечкенә бер бүлмәбездә сандык өстендә хәрәкәтсез ятарга мәҗбүр булды. Өй еш кына салкын була, озак ятудан тишелгән урыннары юешләнә иде. Янына йөргән дусларыннан Зәйнәп апа Хәсәнине хәтерлим. Дәү әни 1942 елда дөньядан китте”, – дип искә алды Фатыйха апаның оныгы Диләрә апа (хәзер мәрхүмә, урыны җәннәттә булсын).

Аллага шөкер, Фатыйха апаның изге эшләре онытылмады дияр идем. 1993 елда Казаныбызда кызлар гимназиясе яңа бинада ачылды. Бу эштә атаклы драматург, язучы Дәүләт Советы депутаты

Туфан Миңнуллин, мәгариф министры Энгел Фәттахов, “Сөембикә” журналы редакторы, “Ак калфак” хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе Роза Туфитулловалар зур тырышлык күрсәттеләр.

Уку йортына Фатыйха Аитова исеме бирелде. Зур куанычыбыз булып гимназиядә Фатыйха ханымга багышланган, аның тормыш юлын яктырткан музей төзелде. Башлап йөрүчеләр: мин фәкыйрегез – Тәминә Биктимирова, журналист һәм язучы Вера Хәмидуллина, гимназия директоры Илһамия Тимеркаева һ.б. булдык. Музей ачуда искиткеч зур ярдәме өчен Энгел Нәвап улы Фәттаховка тагын-тагын зур рәхмәт.

Гимназиягә баргач, күңел шатлана, зур, якты залларында тәртип, уку йортларына хас күңел күтәренкелеге, чиста-пөхтә кызлар.

Директоры Зөммәрә Нәгыймованың тырышлыгына сокланырлык. 2023 елның 24 ноябрендә гимназиянең 30 еллык юбилеен да искиткеч матур итеп оештыра алган иде. Олы рәхмәтебез булсын аңа. Фатыйха апаны искә алуыбыз каберләрен нурландырып, рухларын шатландырса иде.

# ОНЫТМАДЫК СИНЕ, ЗӨҺРӘ АПА

Кандидатлык диссертациям 1920–1926 елларда Идел буе өлкәләрендәге хатын-кызлар хәрәкәтенә багышланган иде. Бу хәрәкәт җәмгыятькә файдалы булып яшәү өчен көрәшне, тырышлыкны аңлата. Минем алда шул катлаулы чордагы вазгыятьне аңлату һәм бу көрәшне оештыруда башлап йөргән хатын-кызлар хакында язу бурычы торды. Аллага шөкер, тигез, матур тормыш төзәргә өметләнеп, үз-үзләрен аямыйча, намус белән эшләгән хатын-кызларыбыз хакында архивларда да мәгълүматлар бар иде әле, исәннәренең кайберләре белән очрашырга да насыйп булды. Аларның берсе – үзем күреп белгән, аралашкан һәм гомерем буена сокланып яшәгән Зөһрә Мөслимова-Баимбетова иде. 1919–1921 елларда Татарстаныбызда яшәп гражданнар сугышында үлем белән күзгә-күз очрашкан, республикабызда татар хатын-кызлары хәрәкәтен җитәкләгән, ачлык вакытында меңнәрчә балаларны чит өлкәләргә озатып, ач үлемнән коткарып калган бөек шәхес ул.

Архивта аның кулы белән язылган мәгълүматлар сакланган. Күргәч, язуының матурлыгына, әмма бигрәк тә үз чоры вакыйгаларына мөнәсәбәте, хатын-кызлар хәрәкәте алдында торган эшләргә, катлаулы бурычларга карашы, фикер тирәнлегенә сокланып туя алмый идем. “Исән булса, их, бер күреп сөйләшәсе иде” дигән теләгем дә көчәйгәннән-көчәйде.

Ниһаять, Мәскәүдә яшәгәнен белеп, адресын таптым да хат яздым. Хатыма җавап бирмәде. Заманында Казанда Зөһрә апа белән бергә эшләгән Н.А. Ванькովага мөрәҗәгать итәргә булдым. Ул үз җавабында: “Янына барып йөри күрмә. Ул чукрак, аягы аксак, беркемне дә кабул итми”, – диде. Әмма мин Зөһрә апаны табарга, ни хәлдә булса да күрешергә булдым.

Таптым. Квартирасына кердем дә, авызымны ачып шаккатып карап тордым. Чәчләрен матур итеп үргән, бик ачык, матур төстәге крепдешин күлмәктән “мөләем бер апа (“карчык” дияргә тел бармый) миңа карады да, көлеп җибәрде.

– Ник аптырадыгыз, Ванькова сөйләгән карчыкны күрергә уйлаган идегезме? – ди. – Ул Сезгә генә түгел, бөтен кешегә дә минем хакта шулай сөйли, ә менә мин әле Аллага шөкер.

Чынлап та хәле Аллага шөкер: чукрак та, аксак та түгел, кыяфәте дә соклангыч чибәр иде.

Зөһрә апа янына берничә тапкыр бардым, мине бик якын күрде, рәхмәт. Урыны җәннәттә булсын. Татарстан, Казан хәлләрен сорап туймый иде. Ул вакытта бездә чыккан газета-журналларны да алдырып, укып барганын күреп хәйраннар калдым. Укыганда болай күз йөртеп кенә түгел, кызык дип тапкан хәбәрләрнең астына сыза-сыза укый. Тарихыбызны, шәхесләребезне белгәненә дә ис китәрлек иде.

Ул үзе 1899 елда Уфада туа. Әтисе Әхтәм Җиһангир улы Мөслимов авылдан чыгып Урал шахталарында эшләп имгәнгән, соңрак Уфада төпләнеп балта остасы булып эшләгән. Әнисе Фәрхи апа яшьтән ятим калып, 7 яшендә Курков дигән урыс гаиләсенә бала карарга килгән һәм 17 яшенә кадәр аларда яшәгән. 17 се тулгач, Әхтәм абзыйга кияүгә чыккан. Матур гына гомер иткәннәр, 9 балалары булган.

Олы балалары Зөһрәне мәдрәсәдә ике ел укыткач, кыз балалар өчен ачылган рус-татар училищесына биргәннәр. “Укыса, бәлки безнең кебек чиләнмәс, тормышы җиңелрәк булыр”, – дип уйлый әти-әнисе. Училище янында интернаты да, яхшы укучыларның яшәве дә дәүләт хисабына булган. “Рус кызларына караганда да күбрәк тырышырга туры килде, татар телендә сөйләшергә дә рөхсәт итмәделәр. 30 баладан училищены бары алтыбыз гына укып бетердек. Мин классыбызда иң яхшы укучы идем”, – дип искә алды Зөһрә апа.

1913 елда училищены тәмамлагач, ул шул елда Уфада ачылган өч еллык укытучылар курсына кабул ителә. 1916 елда “учительница народных училищ для инородческих детей” дигән диплом ала. Рус булмаган милләт балаларына гына рус теле өйрәтергә хокукы булган, димәк.

Яшь укытучының эше Караякуп волостеның Арслан авылында земство карамагындагы башлангыч училищеда башлана. Яратып

башкара үз эшен, тик озак эшләми, илдә инде барыбызга да мәгълүм үзгәрешләр башлана.

Февраль революциясеннән соң урнашкан Вакытлы хөкүмәт хатын-кызларны тигез хокуклы гражданнар дип игълан итә итүен. Әмма хатын-кызларга бу "тигез хокуклылык" дигән төшенчәне аңлатырга кирәк була әле. Зөһрәгә менә шул эш тапшырыла. Тик моңа каршы чыгучылар күп, "ничек инде шәригать кушмаганны, хатын-кыз ирләр белән бертигез булсын" диючеләр Зөһрәнең һәр эшенә аяк чалалар. Җыелышларны куып таркаталар, төрлечә яныйлар.

Зөһрә апа мөфти Галимҗан Барудига ярдәм сорап бара (1917 елда I Бөтенроссия мөселманнары съездында Г.Баруди мөфти булып сайлана һәм Уфада урнашкан Диния нәзарәтендә эшли башлый). Мөфти Зөһрәне бик җылы кабул итә һәм "Хакимият рөхсәте белән генә түгел, Диния нәзарәтенең дә рөхсәте һәм тәкъдиме белән хатын-кызларның тигез хокуклыгын аңлату эшен алып бару тапшырыла" дигән кәгазь (документ) бирә.

1918 елның маенда Зөһрә большевиклар партиясенә керә һәм шунда ук Губерна мөселманнар комитетына эшкә чакырыла. Төп эше шул ук хатын-кызлар арасында агитация, пропаганда белән бәйле була. Вакыйгалар бик тиз алмашынып, кешеләр язмышлары да шулай тиз үзгәргән чор бу. Шушы 1918 елның июлендә Мәскәүдә Советларның V съезды чакырыла. Уфа делегациясе составында татар кызы Зөһрә Мөслимова да съезда делегат булып катнаша. Бу көннәрдә Советлар властеның хәле бик мөшкел: сул эсерлар баш күтәргән көннәр, чехлар һөҗүм итеп Казанга якынлашалар. Съезда В.И.Ленин чыгыш ясап, барлык делегатларны гражданнар сугышына китәргә өнди. Башкалар белән бергә Зөһрә дә Свияжскида оеша торган 5 нче Армиягә китә.

Бөгелмәдә бу армиянең штабы урнашкан була һәм Политбүлегенең органы булган "Кызыл Яу" газетасы чыга башлый. Язмыш дими ни дисең. Зөһрә шушы газетаны оештыручыларның берсе, революциянең танылган солдаты, Уфада яшәгәндә үк үзенә гашыйк булган Гыйлемдар Баимбетовны очрата. Алар өйләнешәләр.

Зөһрә армиянең политбүлегенә агитатор итеп билгеләнә. Аның алдына солдатлар һәм якын тирәдәге авыл халкы арасында Совет власте хакында аңлату-төшендерү һәм Кызыл гвардиягә өндәү

бурычы куела. Рус, татар, башкорт телләрен камил белгән, большевиклар тоткан юлны чын күңеленнән кабул иткән кешегә, ягъни укытучыга агитация алып бару, чыгышлар ясау кыен булмагандыр. Әмма әлегә рухи, сәяси кыйблаңны белдерү бик хәтәр вакыт. Советны яклаган өчен генә дә дошман кулына эләксәң, күкрәккә йолдыз кисүләр, туганнарыңны, хәтта әти-әниләреңне асулар, хатын-кызларны көчләүләр һ.б. тарихта билгеле фактлар бит. Зөһрәнең бәхетенә ире Гыйлемдер Баимбетов янәшәсендә әле. Ул мөселманнардан махсус хәрби частьләр оештыруга бөтен көчен куеп йөри.

– Фронтка килгәндә безгә хәтта хәрби киемнәр дә бирмәделәр, – дип искә алды Зөһрә апа. Съездга нинди кием киеп килгән идек, шулай йөрергә дә туры килде. Төрле хәлләр булды инде, хәзер дә искә алырга куркыныч. Бервакыт, берничә кеше Татар Шырданы авылына крестьяннар белән җыелыш җыярга, аларны Кызыл Армиягә язылырга өндәргә килдек. Бу авылда Зыя Вакыйф дигән мөгаллим Кызыл армиягә ярдәм итә торган булган. Без үзебез белән листовкалар, воззваниеләр алып бардык. Җыелыштан соң иптәшләрем китте, мунчага керәсем килгән иде, мин калдым. Икенче көнне уракка киткән авыл кешеләре “аклар килә” дип кычкырышып, куркып кире кайттылар. Зыя миңа ат биреп озатмакчы иде, тик үзем генә китәргә дә кыюлыгым җитмәде, ахры. Мин алып килгән әдәбиятны Зыя тиз генә тирес астына күмде дә, гаиләсен алып чыгып китте. Сеңлесе минем белән калды. Берзаман бикле капкага бик яман “ачыгыз” дип бәрә башладылар. Бәхетебезгә кермичә кире киттеләр. Вакыйф күпмедер вакыттан соң гына кайтты.

Халыкны куркытып авылга басып керүчеләр Каппель отряды сугышчылары булган икән. Үз башларына булгандыр, Троцкий тиз генә аларга каршы бронепоезд җибәреп, 3 сәгать буе солдатларны да, авылны да утка тоттылар. Өч көннән соң безнең гаскәрләр килде.

Зөһрә апа, һич ялгышмыйча, 1918 елның 5–6 августында Казанның чехлар һәм аквардиячеләр кулында калуын да, 10 сентябрьдә Кызыл Армия тарафыннан азат ителүен дә дулкынланып сөйли иде. Үз күз алдында булган хәлләр бит.

Чыннан да Россиянең язмышы шушы Көнчыгыш фронт кулында булганын хәзер тарихтан укып беләбез. Лев Троцкий Свияжскига килгәндә, яңа оешкан армиядә дисциплина бик йомшак була. Солдатларның күбесе кичәге крестьяннар, заводлардан мобилизация белән килгән эшчеләрдән тора. Ул килү белән котычкыч методлар кулланып армиядә тәртип урнаштырырга керешә. “Сез – тарихчылар беләсез булыр, – дип сөйләде Зөһрә апа, – Троцкий иң беренче итеп заградительный отрядлар (сугышчылар чигенмәсен өчен юлны каплау) оештырды. Мондый нәрсәне “бөек патша Петр I Полтава сугышында беренчеләрдән булып куллана бит. Аны беләсездер инде (гафу итсен Зөһрә апа, белми идем), 29 августта 2 нче номерлы Петроград полкы Каппель гаскәрләре кысуга каршы тора алмыйча позицияләрне ташлап китә башлады. Ачуыннан ярсыган Троцкий шунда ук полк комиссары Пантелеевны һәм командир Гнушевны атарга боерык бирде. Сугышчыларны тезеп куйдылар да, һәр 10 нчы кешене аттылар. Күз алдыбызда 41 кеше юк ителде, кызым. Мин алар арасында, алар күз алдында йөргән кеше бит. Ничек онытыйм. Мәетләрне суга ыргыттылар да, катерларның винтлары белән бәрдереп тә үттеләр әле. Күрергә язмасын. Мин бу хәлләрне тыныч кына кичерә алмадым, авырдым. Ярый әле, ирем Гыйлемдар да Свияжскида иде. Баштарак армиядә рус телендә генә “Гражданская война” дигән газета чыга иде. Әмма Баимбетов политбүлектә мөселманнарга аерым газета чыгару өчен тырышты. Куркып тормады. Ниһаять 1918 елның 6 декабрендә Бөгелмәдә “Кызыл яу” газетасының беренче саны чыкты”.

Зөһрә апаның искиткеч хәтеренә сокланып туя алмый идем.

Казанны алгач, кызыл гаскәрләр Сембер, Бөгелмә шәһәрләрен ала. Тик Зөһрә апа шул тетрәнүләрдән соң тиф белән авырый. Армиядән азат ителеп, 1918 елның декабрендә, Уфага әйләнеп кайта. Авырудан сәламәтләнгәч, Уфа губкомының мөселман секциясендә эшли башлый.

Тик Гыйлемдарын Казанга чакыралар. Зөһрә апа да Уфадан китәргә риза була. Алар Казанда бергә яши башлыйлар.

1919 елда Казан губкомының мөселманнар бюросы секретаре һәм бер үк вакытта татар хатын-кызлары арасында эшләү өчен губкомның хатын-кызлар бүлеге инспекторы вазыйфаларын да

башкара. Ул эшне үз тәҗрибәсенә таянып җәелдерә. Шәһәрдә генә түгел, авылларда да хатын-кызлар советлары оеша башлый. Хатын-кызлар арасында җыелышлар үткәрү, балалар бакчалары, яслеләр ачу, эшсез хатын-кызлар өчен артельләр оештыру; мәктәпләргә, рабфакларга хатын-кызларны кертү; профсоюз, кооператив оешмалары, совет органнары эшенә хатын-кызларны тарту; делегат җыелышлары оештыру һәм аларга көндәлек ярдәм күрсәтү; Кызыл Армиягә ярдәм атналары оештыру – менә шундый һәм башка бик күп төрле вазыйфаларны үтәргә Зөһрә башлап йөри, башкаларны оештыра. Ул шул еллар матбугатында чыгып килгән "Хатын-кыз сәхифәләре"нә күп санлы мәкаләләр яза. Кайберләре үзәк матбугатта да басыла. Хатын-кызлар күңелен аңлый белүе, аларның кайгы-хәсрәтләрен үзенеке итеп уртаклашуы, ярдәмче булганы өчен үз итәләр Казанда Зөһрәне һәм яратып "Таң кызы" диләр.



*Мөселман пехота командирлары курсында чыгарыш кичәсе.*
*Икенче рәттә сулдан: 2 – Шамил Усманов, 4 – Әминә Мөхетдинова,*
*7 – Сәхибгәрәй Сәетгалиев, 8 – Зөһрә Баимбетова. Казан, 1921 ел*

Шушы ук вакытта Зөһрә апага 16 нчы мөселман пехота полкы командирлары хәзерләү курсларында да дәресләр алып барырга туры килә.

1919 елның ноябрендә Казанда татар коммунистларының конференциясе үтә. Зөһрә апа биредә Мәскәүдә узачак Көнчыгыш халыклары коммунистларының II Бөтенроссия съездында сайлана. Съезда аны президиумга сайлыйлар. Биредә ул В. Ленин һәм Н.Крупскаялар белән сөйләшеп утыра алган. Крупская Уфада сөргендә булган хәлләрен сөйләгән. Ленин исә Зөһрәнең рус телендә камил сөйләшүен игътибарга алып, бик кызыксынган, Казан хәлләрен сорашкан.

Бу хакта язуымның төп сәбәбе дә аларны Зөһрә апа шулай бик үз итеп, бик җылы итеп искә алганга күрә.

1920 елда ТАССР оешкач, Зөһрә апа партиянең өлкә комитетына да әгъза булып сайлана. Мәскәүдә 1920 елның декабрендә үткәрелгән Советларның VIII съездында катнаша, хәлиткеч тавыш иясе була (право решающего голоса). Кайту белән Татарстан партия Өлкә комитеты Зөһрә апага хатын-кызлар бүлеген җитәкләүне тапшыра. Аның тырышлыгы белән 1921 елның гыйнварында Казан дәүләт университетының Актлар залында татар эшче һәм крестьян хатын-кызларының беренче съезды ачыла. “Бу съездны оештыруда күрсәткән ярдәме өчен Исхак абый Казаковны әле дә рәхмәт хисләре белән искә алам”, – дип сөйли иде Зөһрә апа. Чөнки Татарстанның матди хәле бик авыр. Мәскәү “ярдәме” белән башланган ачлык котырган вакыт бит бу. Һәркемгә нинди дә булса бүләк бирергә, күңелләрен табарга кирәк булган. “Безне кешегә санап дөньяга чыгардың, изге җандыр син” дип елый-елый аркасыннан сөючеләр күп булган аның. Съезд 22 нче гыйнварга кадәр гөрләп барган. Үзәк һәм җирле оешмалар, матбугат съездның эшенә югары бәя биргәннәр. Мәскәүдә 1921 елның 21 июненә тәгаенләнгән Шәрык хатын-кызларының I Бөтенроссия съездына доклад хәзерләү дә нәкъ Зөһрәгә тапшырылуы да очраклы хәл булмый әлбәттә.

Әйткәнебезчә, Татарстанда бу вакытта ачлык көннән-көн куркыныч төс ала. Съезд да шуңа күрә үткәрелми кала. Хатын-кызлар бүлеге мөдире Зөһрәгә хәзер гаять авыр бурыч йөкләнә. Ул – ач балаларга ярдәм күрсәтү комиссиясе рәисе, Татарстанда ачларга

ярдәм күрсәтү комиссиясе әгъзасы, Халык мәгарифе Комиссариатының социаль-тәрбия бүлеге мөдире. “Гомер буе исемнән чыкмады ул котычкыч көннәр”, – дип яза ул үзенең истәлекләрендә. Татарның пәһлевандай ирләрен Урта Азиядә Совет власте урнаштырырга җибәрделәр. Урамнарда, пристань, вокзалларда, ишегалларында, олы юлларда аунап яткан, ачтан шешенгән, сәләмә киемнәрдән, тәннәрендә җаннары көч-хәл белән сакланган балаларга ярдәм күрсәтү өчен 291 пункт ачылды. Аларда эшләү өчен хатын-кызлар бүлекләре вәкилләре, югары уку йортында укучы студентлар тартылды. Алар эшне балалар өчен дарулар, кием-салымнар, ашханәләр өчен савыт-саба, кашык җыюдан башладылар (чөнки кайбер ашханәләрдә 80 балага 1 кашык туры килгән). Нәкъ менә шул хатын-кызлар тырышлыгы белән ачлар файдасына “Балалар атналыгы”, “Кызыл Хач атналыгы”, “Ачларга ярдәм атналыгы” һ.б. оештырылган.



*Татарстанда хатын-кызлар арасында эшләүчеләрнең 2 нче Өлкә киңәшмәсе делегатлары. 22–24 февраль, 1921 ел. Аста беренче рәт сулдан уңга, 4 нче Зөһрә Баимбетова*

Икмәкле өлкәләргә озату өчен балаларны башта беттән арындырырга, мунча кертергә, өс киемнәре һәм поездларда озата баручыларны табарга кирәк булган. Балаларны икмәкле өлкәләргә озату өчен махсус санитар поездлары оештырылып, беренче поезд 1921 елның сентябрендә киткән. Зөһрә апа эшләгән дәвердә 15 мең бала ач үлемнән коткарылып, читкә озатылган.

1922 елда аны көтмәгәндә генә бу эшеннән азат итәләр. Эвакуация комиссиясен Гришина Лидия җитәкли башлый.

Зөһрә апаның тагын бер истәлеген язып үтәм. “Мине Татарстаннан эшкә дип Бохарага җибәрделәр. Киткәч тә үзем читкә озаткан балалар күз алдында торды. Юкка булмаган икән. Берничә елдан Кисловодскидан Мәскәүгә кайтып барышлый, сеңлем белән вокзалда утырабыз. Безнең татарча сөйләшкәнне ишетеп сәләмә киемле бер бала килде. Елый-елый: “Апа сез Казандагы Зөһрә апаны белмисезме? Безне Казаннан җибәргәндә, кайтарам дип вәгъдә биргән иде. Кайта алмадык бит менә. Мин монда бер байда ялчы булып хезмәт итәм, туйганчы ашаганым да юк”, – дип үзәгемне өзде. Кемлегемне әйтергә оялдым”. Бу истәлек үзе генә дә халкыбыз кичергән һәм кичереп килгән фаҗига хакында сөйли бит.

Зөһрә апаның Татарстаныбыз белән бәйле гомере, хезмәте шулай 1922 елда туктала. Әмма никтер туган Уфасын түгел, Казанны күбрәк сагына кебек тоела иде. Кемнәрне генә сөйләми, кемнәр белән генә аралашмаган бит үз вакытында. Әмма аларның күбесе репрессияләр чорында юк ителгәннәр, шуңа күрә истәлекләрен яза алмый иде. Әле үзгәртеп кору башланмаган, белгәннәрне сөйләргә рөхсәт юк иде.

Үзем бервакыт Зөһрә ападан: “Нигә дип сез үзегезне документларда башкорт кызы дип күрсәтәсез, әтиегез татар, сөйләшкәндә татар кызы икәнлегезне әйтәсез?” – дип сорадым.

– И, кызым, (ул миңа гел кызым дип әйтә иде) Татарстанда, ни кызганыч, татарларның кадере юк. Ә Башкорстан безне ничек хөрмәтли. Картайгач күңел әнә шул хөрмәтне дә өмет итә икән, – диде Зөһрә апа. Аның матур истәлеген Татарстанда да онытмасыннар иде.

Вафаты 1986 елда, Мәскәүдә. Кабергә күмелмәде, кремацияләнде. Аны белгәннәрнең балалары рухына дога кылсыннар. Татар халкына күрсәткән игелекләре үзенә савап булсын. Исеме тарихыбызда урын алсын, онытылмасын.

# БЕЗНЕҢ ҖИҺАН АПА

Ник күңелемә тынычлык бирми газаплыйлар икән 1930 елларда гаделсезгә хөкем ителгән асыл зат шәхесләребезнең фаҗигале язмышлары? Архивлар карап утырганда ник килеп чыга икән алар хакында мәгълүматлар? Еллар буе язмаска тырышып йөрим-йөрим дә тагын тотынам. Менә Хөсниҗиһан апа Байдамшина-Абрамова белән дә шул ук хәл…

Аның хакында Мәскәүдә яшәгән Зөһрә апа Баимбетова 1980 елларда бик яратып, сагынып сөйләгән иде. Зөһрә апа хакында матбугатта минем мәкаләләрем басылды. Ул – ТАССР төзелгән чорларда партия өлкә комитетының хатын-кызлар бүлеген җитәкләгән, бу эш өстенә ачлык вакытында балаларны коткару комиссиясенең рәисе дә булган хөрмәтле зат. “И, кызым, ике бик тә уңган, ышанычлы таянычларым бар иде эшемдә. Берсе Җиһан Байдамшина, икенчесе Былбыл Ильясова иде. Алар кебек һәр эшне җиренә җиткереп башкарган ярдәмчеләрем булмады минем. Яз әле шулар хакында”, – дип үтенә иде. Никтер һаман сузылды бу эш. Һәм менә 1990 елда Е.Гинзбургның “Крутой маршрут. Хроника времен культа личности” (М.: Советский писатель, 1990 ел) дигән китабында тагын Җиһан апага багышланган юлларны укыдым да хәйраннар калдым. Бөтенләй башкача бәя бирә автор Җиһан апа хакында.

Әйтеп үтим, Евгения Соломоновна Казанның югары уку йортларында марксизм-ленинизм фәнен укыта. 1937 елда кулга алына, 1955 елда аклана. Ире Павел Васильевич Аксенов (1890–1991), партия, хуҗалык, профсоюз эшлеклесе. Шулай ук кулга алына. Исәнсау әйләнеп кайткач, “Последняя вера” дигән китабын язды. Китабында татарлар хакында, бигрәк тә Осман Дивеев, Әминә Мөхетдинова һ.б. хакында хөрмәт белән язды. Рәхмәт аңа. Аны гаепләү, ялгышмасам, хатыныннан баш тартмаган, аннан ваз кичмәгән өчен башланып китә кебек.

Солтангалиевчелектә гаепләнеп кулга алынган Җиһан Байдамшина белән Е.Гинзбург Казан төрмәсенең бер камерасында очрашалар. Бу очрашу хакында “Крутой маршрут” китабында мондый юллар бар: “Нет, совсем невозможно узнать в этой до нутра потрясен-

ной женщине вчерашнюю “совнаркомку”, с ее сановитой осанкой. Она больше похожа сейчас на ту провинциальную татарскую девчонку, торговавшую папиросами в сельской лавке, девчонку, на которой лет за двадцать до этого женился Каюм Абрамов. Выражение ужаса смыла все детали показного грима. Обнажились и классовые (простая крестьянка) и национальные черты. Татарский акцент, с которым Зина боролась, проступил с особой силой, в первых же сказанных ею словах… Я никогда не симпатизировала вельможной Зинаиде…” (83 бит).

Репрессия еллары, ул вакытта рәнҗетелгәннәр хакында күп укыдым. Әмма бертөсле бәхетсезлеккә дучар булган кешеләрнең исәнсау кайткач, бер-берләре хакында начар итеп язган сүзләрен бүтән укырга туры килмәде, шөкер. Киресенчә, аерым шәхесләргә начар характеристика бирү алар гадәтендә юк төсле. Рәхмәт, рус язучысы Ю.И.Чирковның “А было все так” китабында (М.: Политиздат, 1991) татар хатыны табибә Хәдичә апа Ямашеваның Коми АССРның Ухтижим лагеренда, үзенә куркыныч янаса да, бүтән тоткыннарга ярдәм итүе хакында бик җылы сүзләр белән язылган иде.

Мин – үз милләтемнең баласы. Евгения Соломоновна сүзләре белән һич тә килешә алмыйм. Шуңа күрә Җиһан апа Байдамшинаның тормыш юлы хакында язуны бурычым дип саныйм.

Уз 1898 елда хәзерге Тәтеш районының Кече Әтрәч авылында туа. Әтисе Мортаза аганың гаиләсендә ишле бала – барлыгы 9 җан. Өлкәнрәкләр балаларга гаиләдә тормыш алып барырга булышу гадәти хәл булган бит инде. Бәләкәй Хөснижиһанга да Тәтештәге земство начальнигы гаиләсендә бала караучы да, йорт эшләрендә булышучы да булырга туры килгән.

Әтисенең китаплар белән кызыксынган кызын укымышлы кеше итеп күрәсе килгән, шуңа күрә Тәтештәге русча-татарча мәктәпкә илтеп биргән. Мәктәп үрнәк мәктәпләрдән саналган, ә аның директоры булып күренекле педагог, журналист һәм революционер булып танылып өлгергән Исхак Казаков эшләгән вакыт була бу. Җиһан үзенең тырышлыгы, сәләте белән укытучыларны, бигрәк тә Исхакның хатыны Нәфисә ханымны соклandырган. Алар Хөснижиһанны үз гаиләләренә алганнар, укуда матди ярдәм дә күрсәтеп

торганнар. 1917 елда алар киңәше белән кыска сроклы укытучылар курсларында укыган кыз бала.

1918–1919 елларда, курсларны тәмамлагач, яшь кыз Тәтеш кантонындагы Бәби авылы, Барыш, Тенкәш авылларында укытучы булып хезмәт итә башлый. Авыл укытучылары өстенә өелгән эшләрнең барысын да башкарган, барысын булдырган ул. Совет властен яклап халык арасында аңлату эшләре алып бару, үзешчән сәнгатькә яшьләрне тарту, спектакльләр, концертлар оештыру, наданлыкны бетерү мәктәбе алып бару – барысы да ул эшләгән эшләрнең бик азы гына әле.



*1920 елларда Татарстандагы хатын-кызлар оешмалары җитәкчеләре. Өченче рәттә уңнан беренче – Хөснижиһан Байдамшина-Абрамова. Зөһрә Баимбетова архивыннан*

Шушы елларда Татарстанда хатын-кызлар хәрәкәте дә җәелеп китә, аның бурычы – хатын-кызларны социалистик төзелешкә тарту. Булдыклы кыз Җиһан да мондый хәрәкәттән читтә кала алмаган билгеле. Аны Тәтеш кантонында хатын-кызлар бүлегенең башта инструкторы, соңрак җитәкчесе итеп билгелиләр. Ачлык вакытында

ачларга ярдәм оештыру, ач балаларны икмәкле өлкәләргә озату, Кызыл армия өчен ярдәм йөзеннән кием-салым җыю, ачлар өчен ашханә пунктлары оештыру – барысы да ул елларда хатын-кызлар оешмалары эшләгән эшләр.

1922 елның гыйнварында Х.Байдамшинаны Казанга эшкә чакыралар. Ул Берләштерелгән Бистә (Объединенный городской) районында эшче хатын-кызлар бүлеген җитәкли башлый. Нәкъ менә шунда эшләгән эшләрен, кешеләрне эшкә тарта белүен Зөһрә апа күреп, иң югары бәяне бирә дә инде. 20 нче еллардагы ачлык газабын да, хатын-кызлар оешмаларындагы чиксез авыр хезмәт хакында да кабат язып тормыйм, "Казан утлары" журналының 2013 елгы №1 санында укырга мөмкин.

Ул еллардагы ачлык, авыр хезмәт Җиһанның сәламәтлеген какшата. Ул хезмәтеннән китәргә, җиңелрәк эшкә күчәргә мәҗбүр була. 1927 елда, бераз сәламәтләнгәч, 14 яшеннән шахтада эшләп, революциядән соң дәүләт, партия эшендә үзен таныткан, Казан шәһәренең ВКП(б) Түбән шәһәр район комитетын җитәкләгән Кыям Алимбәк (Галимбәк) улына (1897–1938) кияүгә чыга. Өйләнешкәч, Кыямны партия Өлкә комитеты Мәскәүгә марксизм-ленинизм югары курсларына укырга җибәрергә карар кыла. Ире белән бергә башкалага киткән Җиһан тиз генә эшче яшьләр факультетына укырга кереп белемен күтәрә.

1929 елда аларны шул ук Өлкә комитеты карары белән Казанга кайтаралар. Кыям – Халык Комиссарлары Советын җитәкли, ә Җиһан сәнәгать страховой кассасында башта инструктор, соңрак җитәкчесе булып эшли. 1930–37 елларда республика сәнәгать советы Президиумы, Пленумы әгъзасы булып сайлана. Аның тырышлыгы белән шифаханә, сырхауханәләр, "Крутушка" ял йорты, олылар һәм балалар өчен санаторийлар, балалар ясләләре, бакчалары, ятимнәр өчен интернатлар ачыла.

Бу тигез, матур, ялкынланып эшкә бирелгән тормыш 1937 елда чәлпәрәмә килә. Бөтен күңеле белән тырышып эшләгән ире дә, Җиһан ханым үзе дә кулга алыналар. "Өстемдә бары бер кат күлмәкчән килеш илтеп яптылар", – дип яза үз истәлекләрендә Җиһан апа. Бер гаепсез көе төрмәгә китереп тыккач, "до нутра потрясенной" булмый хәлең булмас, Ходай күрсәтмәсен, төрмә белән танышырга

язмасын. Кулга алынганчы бер ятим баланы алып тәрбияли башлаган булалар әле. Ул бала да урамда кала. Истәлекләрендә ул хакта үзәге өзелеп язган Җиһан ханым.

Аны милләтчелектә, солтангалиевчелектә гаеплиләр. Кыямыннан баш тартырга, аны Совет власте дошманы итеп күрсәтергә таләп итәләр. Ул баш тарта, нык тора. Әйтергә кирәк, ирләрен халык дошманы итеп таныган, органнар белән эшләргә риза булган хатыннарны кулга алмаганнар ул чакта. Ирләренә хыянәт итмәгәннәр барысы да үзләре төрмәгә озатылганнар. Раббым, дустыңа-дошманынга күрергә язмасын кабат.

Кыям Абрамовның, шахтада эшләгән вакытта авария булып, бер кулы сынган була. Төрмәгә эләккәч, җәзалап аның бердәнбер сәламәт кулын да сындырганнар. Шулай, 1938 елда революциягә, Совет властена чын күңелдән бирелеп, халык файдасына эшләгән эшләре өчен ике тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнгән татар баласы атып үтерелгән. Җаннары җәннәттә булсын.

Җиһан Абрамованы 5 елга дип утырталар, әмма ул биш ел тугыз елга сузылган.

Казахстан лагеренда вакытта ул терлекчелектә эшләгән. Көтү дә көткән, башка төрле эшләрдә дә эшләгән. 1946 елдан 1956 елга кадәр хокуклары чикләнгән “вольнонаемная” (янәсе, үзе теләп ялланган) кеше буларак эшкә калдырылган. Ветеринария фельдшеры, аптека эшчесе булып эшләгән.

1956 елда Җ.Абрамова Казанга кайта алган. Идел буе райсобесына учетка куелган. Сәламәтлеге какшаган, элек бергә эшләгән хезмәттәшләре, дуслары кайсы кулга алынган, кайберәүләр мәңгегә югалган вакыт бит инде. Өр-яңадан яши башларга кирәк булган Җиһан апага. Югалтуларны, йөрәктәге сызлануларны нәрсә белән булса да бераз онытырга, кешеләр арасында булырга кирәк бит инде. Ул җәмәгать тәртибендә, хәзерге Идел буе районындагы №22 йортлар идарәсе каршында китапханә оештыра, квартираларга йөреп китаплар җыя башлый. Бер меңгә кадәр укучылары, 9000 артык китабы була бу китапханәнең. Бәхетенә, 20 гасырның 60–70 елларында халык китап укый иде әле, шунысы файдалы булган. Күпме макулатура җыеп, никадәр чиратларны үтеп китап сатып ала идек бит.

Тагын бер файдалы шөгыльләре бар иде ул вакытта Җиһан апа кебек пенсионерларның. Йорт идарәләре каршында оешкан балалар мәйданчыкларына килеп, балаларга әкиятләр укыйлар, төрле-төрле уеннар оештыралар иде алар. Менә Җиһан апа да шундый эшлекле, актив пенсионер булып гомер иткән, үзенә шундый юаныч тапкан. Ул чактагы Мәдәният министрлыгы аның бу активлыгын югары бәяләп, Мактау грамотасы белән бүләкләгән, рәхмәт.

Җиһан апаның дуслары белән сөйләшкәнем булды. Аны бары яхшы яктан гына искә алалар иде. Шулай матур булып кала алды ул замандашлары күңелендә. Урыны җәннәттә, рухы шат булсын.

Ә Евгения Соломоновнага, исән булса, бары бер генә сүз – “ялгышасыз” дип кенә әйтер идем.

# ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ БАТЫРЫ
# ЗӨҺРӘ АЛТЫНБАЕВА

*Әле җирдә бик күп изге җаннар*
*Рухи салкынлыктан өшиләр.*
*Шаһинур Мостафин*

Россия тарихы – сугышлар тарихы. Ил тарихында узган канкойгыч, җаннарны тетрәндергән гражданнар сугышыннан соң инде йөз еллап вакыт үтте. Әмма анда катнашучы милләттәш хатын-кызларыбызның батырлыклары бүген дә сокландыра, акылы сау кешеләребезне уйландырмый да калмас әле. Чынлап та, халкыбызның азатлык өчен көрәш тарихы шулай рухландырган микән аларны, ник үзләре теләп сугыш мәхшәренә, ут эченә барып керделәр икән?

Сугыш газапларын башыннан ахырынача кичеп, тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән татар кызы Зөһрә Алтынбаеваны искә алыйк әле, рухы шатлансын.


*Зөһрә Алтынбаева*

Ул 1888 елда Казан губернасының Самара губернасы белән чиктәш (Татарстанның хәзерге Нурлат районына керә) Ерыклы авылында туа. Әти-әнисе хакында сүз архив материалларында сакланмаган, ә менә бертуган абыйлары Миңнәхмәт, Хөснулла, Сөләйман, Ибраһим, Әхмәткәримнәрнең сеңелләренә ярдәмче булулары турында әйтелә. Алар Зөһрәгә Уфа шәһәрендәге рус-татар мәктәбендә белем алырга да булышканнар икән. Гаиләдә матур тәрбия алып үскәннәрдер дип уйлыйк егетләрне, шулай булмаганда Зөһрәгә туганлык мөнәсәбәтләре дә җылы булмас иде.

“1916 елда Уфада укуны тәмамлагач, мин Красноводск тирәсендәге төрекмән авылында мөгаллимә булып урнаштым. Әллә бөтенләй ят җир булганга микән, Казанга кайтасым бик килде”, – дип яза Зөһрә апа.

1917 ел башыннан ул Казанда яши башлый. Мәгълүм булганча, Февраль революциясеннән соң Казан гөрли, һәртөрле партияләр үзләренең эшчәнлекләрен җанландыралар. 1917 елның апрелендә “Новый клуб” бинасында татар хатын-кызларының, “Мөхәммәдия” мәчетендә татар мөгаллимнәренең съездлары үткәрелә һәм, ниһаять, Мулланур Вахитов җитәкчелегендә Мөселман социалистлар комитеты оештырыла. Комитетның төп максаты – хакимиятне ярлы халык Советларына бирү, барлык җирләрне җир комитетларына тапшыру, завод-фабрикаларны, табыш бирә торган йортларны дәүләт милкенә әверелдерү һ.б. Тиздән, Үзәк МСК органы буларак, “Кызыл байрак” гәзите нәшер ителә башлый.

Комитет төрле оешмалар, сәнәгать предприятиеләре белән элемтә урнаштыра башлый, эшчеләр арасында агитация-масса эшләрен җәелдереп җибәрә, һәрбер эшкә җаваплы кешеләр билгеләнә. Эшче хатын-кызлар арасында аңлату эшләре Әминә Мөхетдинова белән Зөһрә Алтынбаевага йөкләнә. “Мин “Кызыл байрак” гәзитен әзерләп почтага салу һәм халык арасына тарату эшләрен дә үз кулыма алдым – дип яза истәлекләрендә З.Алтынбаева. – Минем эшемне Мулланур иптәш Вахитов югары бәяләде”.

Болар өстәвенә, Зөһрә Комитетның Елга аръягында урнашкан Алафузов фабрикасы эшчеләрен укытуны да үз өстенә ала. Алафузов театрының беренче катындагы бүлмәгә яше һәм карты, укый белгәне һәм хәреф тә танымаганы, татары һәм чувашы, алар сөйләгәнне аңлаучы руслары да җыела. Аларның барысына да ачкыч таба алган Зөһрә. Эшчеләрнең матбугат белән кызыксынулары арта барган. Шуларны искә алып, Комитет Ленинның популяр әсәрләрен тиз арада тәрҗемә итеп чыгарырга карар бирә. Бу хәл Зөһрәгә дә, аның кебек башка пропагандистларга да эшлекле ярдәм була. Октябрь вакыйгаларын алар зур хәзерлек белән каршы алалар.

Тарихтан укып белгәнебезчә, 1918 елның апрелендә Мәскәүдә татар-башкорт батальоны оеша. М.Вахитов аның комиссары итеп

билгеләнә. Милли составы шактый чуар булган бу батальон акгвардиячеләргә каршы көрәштә зур батырлык күрсәтә.

Совет властена куркыныч янаган көннәрдә батальон сугышчыларын Көнчыгыш фронтка озатырга карар кылына. Совет хөкүмәте аларны Октябрь казанышларын сакларга чакыра. Сугышчыларны тантаналы рәвештә Кызыл мәйданга тезәләр. М.Вахитов үз чыгышыннан соң батальонга сугышчан Кызыл байрак тапшыра. Аңа: “Революция дошманнарына үлем!” дип язылган була. Митингтан соң Беренче татар-башкорт батальонын тынлы оркестр белән Казан вокзалына озаталар. Шунысы кызык, батальон сугышчылары арасында Мәскәүдәге туганнары янына күрешергә генә дип килгән Зөһрә Алтынбаева да була.

Зөһрәнең батальон сугышчылары сафына басуын очраклы хәл дип уйлап булмый, әлбәттә. Ул бу хакта үзе дә “Вәли Шәфигуллин, Каюм Саттаров, Якуб Сәйфи, Шәһит Әхмәдиевләр көн саен җыелышлар үткәрәләр иде. Мин алардан күп нәрсәгә өйрәндем, күп нәрсәне аңладым”, – дип яза.

Батальон төялгән поезд Түбән Новгород шәһәренә җиткәндә, ак гвардиячеләрнең Самараны алулары билгеле була. Димәк, яңа оешкан кызыл гвардиячеләр турыдан-туры ут эченә барып керә.

Батальон сугышчыларының сәяси яктан тотнаклы, Совет властена чын ихластан бирелгән булуларын архив материалларыннан һәм шул чордагы матбугат битләреннән ачык күрергә мөмкин. “Знамя революции” гәзите, мисал өчен, үзенең 1918 ел 19 июнь санында батальонда җыелыш үткәрелү хакында болай дип яза: “Җыелышта түбәндәге резолюция кабул ителде:

1. Эшче, крестьян һәм кызылармияче депутатлары Казан Советын, шулай ук Мөселман эшләре буенча комиссариатны соңгы тамчы кангача сакларга;
2. Әгәр Казанда Совет властен бәреп төшерергә хәзерләнүче көчләр бар икән, аларга бердәм төстә каршы чыгарга!”

Батальон моннан соң Көнчыгыш фронтның Сызрань участогына җибәрелә. Сызраньга килеп җитәргә егерме чакырымнар кала, Троицк авылы янында, батальон акгвардиячеләр белән беренче тапкыр йөзгә-йөз очраша. “Беренче татар-башкорт батальоны сугышчылары “арсланнар кебек сугыштылар”, – дип яза “Кызыл Бай-

рак” гәзите үзенең 1918 елгы 19 июль санында. Ни кызганыч, каты бәрелештән соң, батальондагы 250 сугышчыдан нибары 47 се генә исән кала.

Төрле сугышларда катнашырга туры килә каһарман кыз Зөһрәгә. Ул үзенең агитатор булып кына түгел, кулга корал тотып сугышуы хакында бик җиңел төсле генә искә алып китә. “Минем көчем күп керде, – ди ул. – Норлат янында Кызыл армия зур һөҗүмгә күчте. Ә мин станциядә җиләк-җимеш, папирос саткан булып, бөтен хәлне аңлатып фронтка язып торам. Кызыллар килгәч, кулга төшкән хәзинәләрне алып барып тапшырдым”.

Бөгелмә шәһәрен азат иткәндә ул бөтенләй разведкага күчә. Һаман-һаман уңай гына булмаган икән хәлләре, Дәүләкән станциясендә задание үтәгәндә ул аклар кулына әсирлеккә төшә. Аны элек Казанда күреп белгән бер колчакчы танып, тиешле җиргә хәбәр итә. Кыз баланы җәзалыйлар, атарга хөкем итәләр. Исән калырга, гомере бетмәскә булгандыр, Җаек елгасын үткәндә вагон тамбурыннан сикереп төшеп котылган да, мең бәла белән Курган шәһәренә килеп җитеп, большевикларга кушыла алган.

Бу авыр кичерешләр сәламәтлегенә зыян салмый калмаган, күрәсен. Ул, Омск шәһәрендә, кемнәр ярдәм иткәндер, хастаханәгә кереп дәваланырга мәҗбүр була. Тик озак ятарга мөмкин булмаган, күрәсең. Себер якларында да хәлләр гел үзгәреп торган. Әле бу вакытта кызыллар сугыша-сугыша Петропавловскига гына якынлашып киләләр. Зөһрә шулай Семипалатинскида яшәгән туганы Гарифулла янына сыенырга мәҗбүр була.

Әмма үзен кызыл сугышчы итеп санаган Зөһрә биредә дә тыныч кына яшәмәгән шул. “Мин Күкпикти (Семипалаттан ерак түгел Кокпекты шәһәре хакында сүз бара) шәһәрендә Колчак армиясеннән качкан егетләрне кулга ала башлаганнарын ишеттем. Аларның исем-фамилияләрен язып мәгълүмат җыя башладым. Акларның көне беткәнен сизә идем. Чөнки Омскидагы байларның да шәһәрдән кача башлаулары хакында хәбәрләр тулы иде”, – ди ул.

Семипалатинск ягындагы таулар арасында партизан отрядлары оеша башлый. Зөһрә шунда китәргә карар кыла. Отрядка З.Алтынбаева килеп кушылганда, анда алтмышлап кеше була инде. Аларның күбесе Колчак, Семенов гаскәрләреннән, әсирлектән качкан

солдатлар, авылларыннан ирек эзләп чыгып киткән яшьләрдән тора. Күпне күргән тәҗрибәле сугышчы, белемле кеше буларак, отряд җитәкчеләренең берсе – комиссары итеп Зөһрә Алтынбаева сайлана. Отряд бер елга якын хәрәкәт итә һәм Кызыл Армия өчен файдалы эш башкара. Колчак һәм Семенов гаскәрләре тылындагы авылларда Совет власте урнаштыручылар да шушы партизаннар, якынлашып килүче Кызыл Армиягә азык-төлек белән ярдәм итүчеләр дә, качып китәргә теләүче байларның алтын-көмешләрен конфискацияләүчеләр дә алар, ягъни шул партизаннар була инде. Әйтеп үтик, бер потка якын алтын-көмешне нәкъ менә Зөһрә айлар буе үзе саклый һәм Омск, Колчак гаскәрләреннән азат ителгәч, Совет хакимиятенә дә үзе илтеп тапшыра. Шунысы кызык: хәзерге көндә үз тормышын куркыныч астына куеп саклап, хөкүмәт органнарына илтеп потлап алтын тапшыручылар бар микән? Мин полиция хезмәткәрләрен күз алдында тотып әйтмим. Төгәл генә бу сорауга җавап бирүе кыен төсле, әмма нәкъ менә революция солдатлары арасында чиста куллы, намуслылары күп булганына иманым камил. Чөнки алар азатлык өчен көрәшчеләр. Азатлык өчен көрәшү үзе чиста куллыларны таләп итәдер.

1920 елда Казанга кайта Зөһрә. “Без Бристоль номерларында Г.Ибраһимов, В.Шәфигуллин, Әминә Мөхетдинова (иске дуслары) һ.б. яши идек. 1921 елның мартында ГПУдан килеп мине кулга алдылар. Имеш, Сәхибгәрәй Сәетгалиевкә атучыга мин наган биргәнмен икән. Мин тиешле җавабымны бирдем. Чөнки ул көнне мин юлда идем, наганымны да Чистай милициясендә калдырган идем. Партизанлык документларымның барысында күрсәттем”, – дип, тормышындагы күңелсез вакыйганы да язып калдырган Зөһрә апа.

Сәетгалиевчеләр Зөһрәгә барыбер кырын карыйлар. Намусына ышанмый караучылар арасында эшли алмый ул, Омскига китә. Бер ел эшләп, яңадан Семипалатинскига күчә. Бу шәһәрләрдә аның бергә партизанлык иткән көрәштәшләре, дуслары исән була әле. 1927 елга кадәр ул Семипалат өлкәсендә хатын-кызлар хәрәкәтенә җитәкчелек итә, аларны яңа тормышка әзерли. Балалар ясляләре оештыруда да тырышлык күрсәтә, чукрак-телсезләр мәктәпләрендә укыта, Өлкә район судында сәркатип та булып эшли. Хезмәт кенәгәсеннән күренгәнчә, аның 1932 елдан алып Татарстанның

Мамадыш партия өлкә комитетында инструктор булып эшләгәне билгеле.

Казанга яңадан кайчан әйләнеп кайтканын төгәл итеп белә алмадым. Ул Горький һәм Комлев урамнары чатында урнашкан сукыр-чукраклар мәктәбендә директор вазыйфасын башкара. 1943 елда (ае, көне күрсәтелмәгән) аңа мәктәп янындагы коега слесарь карт төшкәнен, ләкин газга тончыгып аңын югалтканын килеп әйтәләр. Зөһрә коега ташланып, картны күтәреп югарыдагыларга бирә алган, әмма үзе хәлсезләнеп кире коега егылып җан биргән.

Кеше бәхете өчен бу кыз бала нинди авырлыклар күрмәгән дә, нинди рәхимсез рәнҗетелүләр кичермәгән. Архивтагы материаллар аның тормыш юлын тулысынча яктырта дип әйтеп булмый.

Ул кылган эшләрне эшләргә күбебезнең хәленнән килмәс иде. Искә алуыбыз аның рухына шатлык өстәсен. И, халкымның бөек кызы, бөек шәхесе! Сугышларда җиңеп халкым бәхетле булыр дип өметләнденме? Рухыңга сүзебез дога булсын. Сугышлар әле дә туктамый бит.

Сүземне үзем хөрмәт иткән шагыйрь, прозаик, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Шаһинур Мостафин сүзләре белән тәмамлыйм. Эпиграф итеп тә аның сүзләрен алган идем.

*Бу дөньяда һаман сугыш бара*
*Кайчан булыр икән азагы?*

## ТАТАР КЫЗЫНЫҢ ҮКЕНЕЧЛЕ ЯЗМЫШЫ

*Россия тарихы – сугышлар тарихы.*

Бу сугышларның бар афәтен, халык җилкәсенә төшкән авырлыгын калын-калын томнарга гына кертеп бетереп булмас, мөгаен. Юк, булмас. Тарихка гражданнар (ватандашлар) сугышы дип кереп калган сугышның да татар халкына кагылышлы өйрәнелеп җитмәгән вакыйгалары, ачылмаган сәхифәләре бүгенге көнгә кадәр бар әле. Бу сүзне бигрәк тә армиядә медицина-санитария хезмәте күрсәтүчеләрне күздә тотып әйтәм. Чөнки армиядә табиблар, шәфкать туташлары, санитарлар булмаса, алар тырышлыгы белән йөз меңнәрчә яралылар яңадан армиягә кайта алмаслар иде. Ни булганын күз алдына китерү дә кыен. Мисал өчен, I Бөтендөнья сугышында яраланган офицерлар саны барысы 27704, ә солдатлар 2424494 исәпләнгән (контузия алучылардан башка). Шулардан офицерларның 14861е, солдатларның 1815606 сы яралары төзәлеп кире сафка баса алган. Моннан тыш, фронтларда төрле-төрле йогышлы авырулар, эпидемияләр килеп чыгуын да әйтсәк, медицина хезмәте күрсәтүчеләрнең фидакярлекләрен бәһаләп бетерүе тагын да кыенлаша. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армиядә генә 1 миллион 300 мең кеше тиф белән авырган.

Бу сугышларга, бигрәк тә мондый җан өшеткеч хәлләргә хәзерге тарихчыларның бәяләре төрлечә. Аларга тукталып тормастан, берничә сүз белән генә татар хатын-кызларының илгә афәт килгәндә ирләр белән бер сафка басулары хакында гына искә төшереп китәм.

Беренче империалистик сугыш башлану белән, Петербургтагы Хәйрия җәмгыте тиз арада “яралылар өчен лазарет ачарга… һәм шәфкать туташлары итеп мөселман кызларны да чакырырга карар кылды”, – дип язган “Каспий” газетасы 1914 елның 9 август санында.

Мондый хәл Казанда да күзәтелә. “Новый клуб” залында 1914 елның 31 сентябрендә, шәһәрнең 200 дән артык иң абруйлы кешеләре җыелып, яралылар өчен хастаханә ачу хакында сөйләшәләр.

Мәҗлесне Галимҗан хәзрәт Галиев (Баруди) ача һәм рәислеккә Габдулла хәзрәт Апанаевны тәкъдим итә. Коръән уку белән башланып киткән мәҗлеснең ахыры да бик уңышлы була. Тиз арада хастаханә ачар өчен җитәрлек акча да җыела, оештыру комитеты да төзелә. Безнең өчен тагын да мөһимрәге шул: оештыру комитетына татар хатын-кызларыннан ике табибә тәкъдим ителә. Болар – Маһипәрвәз Дәүләткилдеева һәм Суфия Коләхмәтовалар. Алар икесе дә яралыларны дәвалауда да искиткеч тырышлык күрсәтәләр.

Гражданнар сугышы башлангач, Казан хәрби медицина үзәгенә әверелә. Шәһәрдә сугышка кадәр үк төрле дәвалау учреждениеләре, шул исәптән Россиядә иң абруйлылардан саналган хәрби госпиталь, атаклы галимнәре белән танылган университетның медицина факультеты һ.б. булуы да сәбәп булгандыр. Тиз арада яңа хастаханәләр, дезинфекция отрядлары оештырыла. Шәһәрне чистарту өчен мәҗбүри хезмәт кертелә, санитарлар өчен махсус курслар оештырыла, армиягә, яралanучыларга ярдәм итә алган һәрбер кеше исәпкә алына.

Әмма гражданнар сугышының сыйныфлар сугышы икәнен дә истән чыгарып булмый. Врачлар, шәфкать туташлары һәм хәтта санитарлар да кызыл сугышчыларны тәрбияләүдән баш тартканнар. Коммунистлар партиясе шәфкать туташлары һәм санитарлар курсларына язылуны сорап халыкка мөрәҗәгать белән чыгарга мәҗбүр була. Еш кына бу курсларга укый-яза белгән кызларны, бигрәк тә мөгаллимәләрне мобилизация белән дә алып китәләр. Шулай итеп, 1920 елның беренче ноябренә Кызыл Армиядә хезмәт итүче шәфкать туташларының саны 10830 га җитә.

Мәкаләмдә мәҗбүри түгел, йөрәге кушканга һәр ике сугышта да (I Бөтендөнья, Гражданнар сугышы) шәфкать туташы булып яралыларга ярдәм күрсәткән Тальковская Зинаида Александр кызы (Зөләйха Искәндәр кызы) хакында язарга теләгән идем.

Ул 1890 елның 4 маенда Вилен губернасы Ошмянск өязе Кырык Татар авылында туган литва татары, патша армиясе генералы Искәндәр Осман улы гаиләсендә дөньяга килә. Әнисе – Елизавета Степановна Сулькевич – татар ротмистры кызы, укытучы.

Искәндәр Осман улының гаиләсендә ике кыз – Дейли (Елена) белән Зөләйха (Зинаида) һәм ике ир бала туа. Уллары Михаль (Ми-

хаил) чик саклаучы берләшмәнең ротмистры, соңрак Азәрбайҗан армиясе офицеры була һәм 1924 елда Баку шәһәрендә үлә. Икенче уллары Искәндәр Тальковский – киләчәктә Кызыл Армия генералы дәрәҗәсендә репрессиягә эләгә һәм 1942 елның февралендә атып үтерелә.

Әйтеп үтик, татар халкының талантлы баласы Искәндәр улы Тальковский хакында тарихчы галим Дамир Шәрәфетдиновның “Карурман аша ла башлар адаша…” исемендә тарихи-документаль очеркы чыкты. Рәхмәтебез рухына шатлык өстәсен.



*Зөләйха Тальковская, Якуб Апанаев*

Зинаида (сүземне Зөләйха исеме белән дәвам итәм) Ригада гимназия тәмамлагач, Петербургтагы Югары медицина курсларына (соңрак Медицина институты итеп үзгәртелә) укырга керә. I Бөтендөнья сугышы башлангач, курста укучы студенткаларның күбесе (алар арасында Зөләйха да) шәһәрдәге госпитальләрдә шәфкать туташлары булып хезмәт итә башлыйлар. Зөләйханың искиткеч таланты аңа эшләргә дә, укырга да мөмкинлек биргән икән. Шушы чорда әле ул Казанның атаклы бае Мөхәммәтшакир Апанаевның

улы Якубны очрата. Якуб бу вакытта Петроградтагы укчы дивизиядә (Зөләйханың әтисе янында) хезмәт итә. Ни кызганыч, Якуб Апанаевның соңгы еллары хакында КГБ (ФСБ) архивындагы шәхси эшен карый алмадым. Ул репрессия корбаны. Акылым белән нахакка гаепләнеп үтерелгәннәрнең эшләре ни өчен хәзергә хәтле серле сандыкта ятканнарын аңлый алмыйм. Россия тарихы – сугышлар тарихы, гаепсезгә каннары коелган шәхесләр тарихы икәнен кем генә белми икән инде (акылы сау кешеләрне истә тотам). Әнә бит шагыйрь Фәтхи Бурнаш та шигырендә мең кат хаклы бит:

*Әйләнә тормыш һаман тукталмыйча,*
*Тормый тарих бер сәгать тик язмыйча;*
*Шул сәхифәләр аңарда, кайсы ки*
*Калды бер тамчы кара кан таммыйча…*

Язучы һәм әдәбиятче галим М.Мәһдиев Фәтхи Бурнашның бу шигырен поэзиясендәге энҗе-таш дип атый[1].

Октябрь революциясе Тальковскийларның язмышын кискен үзгәртеп җибәрә. Алар бернинди икеләнүсез Совет власте ягына чыгалар. Гаилә башлыгы Искәндәр Осман улы Тальковский Петртоградтагы 1 нче укчы дивизиянең бригада командиры итеп билгеләнә, ә аның улы Петроград мөселман батальоны командиры, ә 1918 елның гыйнварыннан шушы полкның командиры булып китә[2].

1919 елда Зөләйха белән Якуб – икесе дә әлегә бик бәхетлеләр, яратышып Казанга кайтып өйләнешәләр. Зөләйха – атаклы Апанаевлар килене, документларын Петроградтан алып Казан университетының медицина факультетына кабул итүләрен сорап гариза бирә. Моңарчы тиешле булган барлык имтиханнарын үз вакытында уңышлы биреп барган кызны берсүзсез бишенче курска кабул итәләр.

Тик, студентка булып университет аудиторияләрендә рәхәт чигеп йөрергә туры килде микән Зөләйхага. Ник дигәндә, 1920 елда

---

[1] Мәһдиев М. Сызып ак нур белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 521 б.

[2] Шәрәфетдинов Д.Р. Карурман аша ла башлар адаша… (Комдив Искәндәр Тальковский турында тарихи-документаль очерк) = Бездны мрачной на краю (Историко-документальный очерк о комдиве Искандере Тальковском). Казань, 2000. 19 б.

Татарстан республикасы төзелгәч, ил өстенә төшкән бәла казаларны санап бетерерлек түгел. Иң коточкычы – ачлык, янгыннар, тиф эпидемиясе… Татарстанның ил тоткасы булырдай барлык ирләре Төркестанда Совет власте урнаштырып йөри. Зөләйханың энесе Искәндәр дә, ире Якуб та шулар арасында.

Университет аудиторияләре бушап калгандай була. Студентларны әле “Фронт атналыгы”, әле “Кызыл сугышчыларның гаиләләренә ярдәм”, әле “Кызыл Хач җәмгыятенә ярдәм атналыгы” дип җәмәгать эшләренә тартып торалар. Ач балаларны коткару эшенә дә студентлар чакырыла. Ач балаларны урамнардан, тыкрыклардан, вокзал тирәләреннән җыеп аласы, беттән арындырасы, мунча кертәсе, киемнәр табып киендерәсе, ашханәләр ачылса, алар өчен савыт-саба җыясы һәм тагын бик күп төрле эшләргә катнашасы була.



*Сулдан уңга: Зөләйха Тальковская, Якуб Апанаев, Мөхәммәтшакир Апанаев, Хәдичә Исхак кызы Апанаева, Өммегөлсем улы Мәхмүт белән. Басканнар – сулдан уңга: Маһиәнвәр ире Ибраһим Апанаев белән, Нурмөхәммәт Усманов – Апанаев заводында бухгалтер*

Зөләйха кебек уңган-булган студенткаларга госпитальләрдә дә ихтыяҗ зур. Кулыннан эш килгәннәр хәтта врачларны алмаштырган вакытлары да була. Зөләйха апа нәкъ менә шул вакытларда операцияләр ясый башламады микән?! Хирург булып тәмамлый бит ул 1925 елда Казан университетын. Бәхетенә Якуб та фронттан кайта.

Кеше бәхете озакка барамыни ул. 30 нчы еллар җитә. Совет власте башта динчеләргә, соңрак үзе өчен көрәшчеләргә, зыялыларга каршы ут ача. Якуб та 1937 елда кулга алынып, 1938 елның икенче гыйнварында атып үтерелә. Апанаевларның барысының да мөлкәтләре тартып алына, күбесе кулга алынып, төрмәләргә ябыла, җидесе атып үтерелә.

Зөләйха апага яшәр өчен дөньяда нинди юаныч кына калды икән? Ул 5 нче шәһәр хастаханәсендә гинеколог булып эшли. Хирург буларак операцияләр ясый. Студентларның практикасына җитәкчелек итә. 1941 елда шулай гадәттәгечә операция ясарга керешә, тик операция бик катлаулы булып чыга. Өстәл янында 6 сәгать буе берүзе операция ясый ул. Опрациясен уңышлы тәмамлап чыкканда аягындагы тромблар шартлый. Утырып ял итәргә дә өлгерә алмыйча, татарның тагын бер талантлы кызы үлеп китә.

Операцияләре уңышлы булып бетмәсә, “халык дошманы” хатынына гаеп тагарга да күп сорамаслар иде. Бәхетенә эше уңышлы булган, төрмәдә үләргә язмаган. Күмәргә килгән халык белән Мәскәү урамындагы (элекке Киров урамы) бакча халык белән шыгрым тулган булган. Казан халкы яраткан табибәсе Зөләйхасы белән елап саубуллашкан.

# МӨГАЛЛИМӘ ФАТЫЙМА ӘДҺӘМОВА ХАКЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Татар хатын-кызларының белем алу өчен көрәшләре – рухи мирасыбызның бик аз диярлек өйрәнелгән, әмма бик гыйбрәтле, фаҗигале һәм бик кызыклы сәхифәсе дияргә була. Бу сәхифә үз эченә татар халык мәгарифе тарихында мәңге сүнмәс беренче йолдызлар белән беррәттән, язгы аҗагандай ялтырап алган меңләгән билгесез зыялы хатын-кызларыбыз язмышын үз эченә ала. Бу язмышлар барысы да татар халкы тәрәккыятенә, мәгърифәт өчен көрәш тарихына бәйле.

Мәгълүм булганча, XIX гасырның икенче яртысында башланып киткән милли уяну дәвере XX гасырга кергәндә татар хатын-кызларына да бик зур этәргеч була. Мәгърифәтчеләр хәрәкәтеннән уянып киткән хатын-кызларга яңа сүз, яңа фикерләр өстәлә. Мондый яңалык аларны милләт язмышы белән бергә үз язмышларын да үзгәртү турында кыюрак уйлануларга китерә. Милләтнең киләчәге, аның тәрәккыяте өчен борчылган татар зыялылары хатын-кызларга да заманга яраклы белем бирүне максат итеп куялар. Әмма бу тарихны өйрәнгәндә бер нәрсәне ассызыклап китү зарур: патша хөкүмәте татар халкының мәгарифенә һәрвакыт аяк чалып, аның белем учакларын матди ярдәмнән тулысынча диярлек мәхрүм итеп килә.

Шушы җәһәттән мәгърифәт учакларын, ягъни мәктәп-мәдрәсәләр ачуга өлеш чыгарып ярдәм иткән татарның күренекле шәхесләрен тагын да рәхмәт белән искә алабыз. Алар арасында, XX гасыр башында алтмышлап мәктәп-мәдрәсәләр ачкан, аның өстәвенә аларның ике йөздән артыграгын уку-укыту әсбаплары белән тәэмин итеп торган, кырыктан артык мөгаллимгә хезмәт хакы түләгән һәм дистәләрчә татар яшьләренә чит илләрнең югары уку йортларында белем алырга ярдәм иткән, Хөсәеновлар аеруча олы хөрмәткә ия.

Матбугатта язылганча, “Оренбург каласы сәүдә җәһәтеннән башка шәһәрләргә караганда алданрак булганга, халыкта акчага ихтыяҗ аз, аларның тормышлары да иркен күренә”[1]. Матди тормыш-

[1] Сөембикә. 1915. №11. 19 б.

ның шулай иркенрәк булуы бирелә мәктәп-мәдрәсәләр ачып, укыту-тәрбия эшләрен җайга салырга мөмкинлек биргән күрәсең. Оренбургның үзендә атаклы “Хөсәения” мәдрәсәсеннән тыш, 1901 елда Гани Хөсәенов акчасына, олуг шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Дәрдемәнднең хатыны Мәхүбә ханым ярдәме белән, кыз балалар өчен ике мәктәп ачыла. Берсе – шәһәрнең үзендә, икенчесе Каргалы авылында. Каргалы мәктәбенә авыл мөгаллимәләре хәзерләү бурычы йөкләнә, аның директоры Мәхүбә ханым үзе була. Шәһәрдәгесенә зуррак максатлар куела, ягъни сигез сыйныфлы үрнәк кызлар мәктәбе итеп оештыру күздә тотыла.

Менә шушы кызлар мәктәбенең җитәкчесе итеп икенче гильдия сәүдәгәр, Оренбург шәһәр думасы депутаты Әдһәмов (Адамов) Мостафа Мөхтәр улының хатыны Фатыйма Миркамил кызы билгеләнә. Шәһәр җәмәгатьчелеге алдында Фатыйма ханымның гыйлем дәрәҗәсе белән аерылып торган хөрмәтле затлардан булганын әйтеп китү артык булмас төсле. Мәктәп җәдид мәктәбе буларак ачыла. Башта укытыла торган фәннәр азрак була, ягъни Ислам дине нигезләре, татар теле һәм кул эшләре укытыла. Соңрак арифметика, рус теле, география, әхлак, гигиена кебек фәннәр өстәлә. Ниһаять, мәктәпнең программасы рус кызлары гимназиясенә якын итеп төзелә. Мәктәпне тәмамлаган кызларның күбесенә мөгаллимәлеккә шәһадәтнамә бирелә. Шуларның берсе – Багъбөстан Мөэминова 1905 елгы революция көннәрендә хатын-кызларны укыту һәм тегүчигү түгәрәкләре оештыра. Түгәрәкләр зураеп кызлар мәктәбенә әйләнә. Шул рәвешчә атаклы Багъбөстан мәктәбе барлыкка килә.

Фатыйма Адамова (Әдһәмова) мәктәбендә уку түләүле була. Укучылардан җыелган акча нигездә укытучыларга хезмәт хакы түләү өчен булса, калган барлык чыгымнар Хөсәеновлар ярдәменнән була.

1910 елда Әхмәт һәм Мәхмүт Хөсәеновлар васыять итеп калдырган 3000 сум акчага мәктәп өчен яңа бина булдырыла. Шунлыктан 1918 елда мәктәптә укучы кыз балаларның саны 120 гә кадәр җитә. География һәм рус теле фәннәрен Фатыйма ханымның үз кызлары Хәдичә һәм Зәйнәпләр, ә татар телен киләчәктә күренекле язучы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе булып

танылачак Байгилдиев Шәриф Камалетдин улы (Шәриф Камал) укыта. 1925 елда Совет хакимияте ни сәбәп беләндер мәктәпне яба.

Фатыйма ханымны зур абруйлы ханым булган дип күрсәтеп үткән идек. Мәктәп ачып, аның эшен иң алдынгылардан саналырлык итеп оештыру мәшәкатьләре өстенә актив җәмәгать эше алып баруы да мактауга лаек әле.

Хатын-кызларның Октябрьгә кадәрге елларда җәмәгать эшчәнлегенә кереп китүләренең бер юлы – хатын-кыз җәмгыятьләре, ягъни "Мөслимәләр җәмгыяте" оештыру булган. Мондый җәмгыятьләрнең беренчесе 1907 елда Уфада оешкан һәм "Уфимское мусульманское дамское общество" ("Уфа мөселман хатын-кызлар җәмгыяте") дип аталган. Җәмгыять, максат-бурычлары, керемнәре, әгъзалык тәртибен эченә алган, устав нигезендә эшләгән. Устав рәсмиләштерелгән. Җәмгыятьнең безнең өчен бүген дә кыйммәтен югалтмаган бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт булган: мөслимәләр арасында гыйлем-мәгърифәт тарату, укучы һәм мөгаллимәләргә ярдәм итү, мәктәптә укый алмаган мөслимәләрне һөнәрле итү, шифаханә, ятимханә, китапханә, уку йортлары ачу, хәйрия кичәләре, спектакльләр, концертлар уздыру һ.б. Мондый җәмгыятьләр татар милли тормышының үзәкләре булган күп кенә шәһәрләрдә һәм хәтта авылларда төзелгән.

1912 елда Оренбургта төзелгән җәмгыятьне төзүдә башлап йөрүче һәм җитәкчесе нәкъ менә Фатыйма Әдһәмова була. Мөхәррире Гаяз Исхакый булган "Ил" газетасы (С.-Петербургта чыга) "Вакыт" газетасыннан алып урнаштырган материалында Оренбург мөслимәләр җәмгыятенең уку мәҗлесе программасын биргән. Мәҗлес 1913 елның 10 декабрендә Габделхәмит Хөсәенов йортында үткәрелгән. Программада: 1. Коръән уку, вәгазь, нәсыйхәт – мөгаллимәләр Фатыйма Әдһәмова, Багбөстан Мөэминова, Мөслимә Шәфыйкова.

2. Мөселман хатын-кызлары арасында мәгърифәт һәм укуның таралуы – мөгаллимә Зәйнәп Камалетдинова.

3. Балалар тәрбиясе хакында – мөгаллимә Гайшә Госманова.

4. Шәригать насыйрында (ярдәмендә) сәламәтлек саклау – мөгаллимә Салихова (исеме күрсәтелмәгән).

5. Табиблар карамагында сәламәтлек – табибә Разия ханым Сөләйманова.

6. Декламацияләр: Г.Тукаев, М.Гафури һәм С.Сүнчәләй шигырьләре – шәкерт кызлар бергә кушылып укыйлар.

7. Пушкин һәм Лермонтов шигырьләре – Рабига Шәрәфетдинова.

8. Салават Шәриф һәм мөнәҗәтләр – кыз шәкертләр бергә кушылып укыйлар[2].

Мәҗлеснең программасы, нәкъ алда күрсәтелгәнчә, җәмгыятьнең үз максат-бурычларына тугры калып, хатын-кызлар арасында мәдәни-агарту эшләрен алга куйганына дәлил. Ни кызганыч, мәҗлестә күпме кеше катнашканы газетада күрсәтелмәгән, әмма мондый мәҗлесләрнең еш үткәрелүе хакында "Вакыт" газетасында мәкаләләр басылып торган.

Патша хакимиятен юкка чыгарган Февраль революциясе Россиядә яшәүчеләргә җиңелрәк сулыш алырга мөмкинлек биргән. Бөтен илдә, шул исәптән татарлар тормышында да, бу чорда зур үзгәрешләр булганын күрәбез. Татар хатын-кызлары тарих бүләк иткән форсаттан файдаланып, ирекле илдә иркенләп, алда торган бурычлар, чишеләсе мәсьәләләр хакында сөйләшер өчен мөслимәләр корылтаен үткәрергә җыеналар. Татарлар яшәгән барлык шәһәрләрдә корылтайның кирәклеген яклап җыелышлар үткәрелә һәм әгәр була калса дип, вәкиләләр дә сайланган.

Ниһаять, 1917 елның 24 апрелендә Бөтенроссия мөслимәләренең тарихта беренче корылтае тантаналы шартларда Казанның "Новый клуб" бинасында ачыла. Фатыйма апа корылтайга кызы Зәйнәп белән килә (бу вакытта аңа 61 яшь, ул 1856 елда туган).

Корылтайның барышы хакында язу мәкаләмнең бурычына керми. Әмма Фатыйма Әдһәмованың кызы Зәйнәпнең 1917 елның 1 маенда Мәскәүдә Ш.Әсәдуллаев йортында ачылган Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда катнашуын әйтеп үтәсе килә. Корылтай (съезд) эшендә 900 гә якын вәкил һәм вәкилә катнашкан. Съезд тарихта беренче тапкыр үз эшендә хатын-кызлар катнашуы белән дә аерылып тора. (Элек үткәрелгән дүрт съездның берсендә дә хатын-кызлар катнаштырылмаган). Съезда барлыгы 112 вәкилә булуы

[2] Ил. 1913. 13 декабрь.

билгеле. Алар барысы да шулкадәр актив булганнар диясем килә, алай булмаса, милләт өчен иң мөһим булган 13 җитди мәсьәләнең алтынчысы итеп хатын-кыз мәсьәләсе куелмас иде.

Фатыйма апаның да, кызлары Зәйнәп белән Хәдичәнең дә ахыргы гомерләре хакында белә алмадым. Татарның мәгънәле милли үзәге булган Оренбург каласында иң беренчеләрдән булып кызлар мәктәбе ачкан зыялы ханым хакында шәһәр архивында да мәгълүмат бик аз иде. 1917 елдагы мөслимәләр съездында катнашучыларның фаҗигале язмышларын искә төшерәм дә, куркуга төшәм. Репрессия җилләре кагылмаган булсын иде дим. Ни генә булса да, Октябрьдән соңгы вакыйгалар эчендә ил белән бергә булганнардыр дип уйлыйм. Рәнҗетелеп киткән булсалар, кичерә күрсеннәр. Сүзләребез рухларына дога булып барсын.

## АЛАР ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘР БИТ…

Татар халкының тугандаш халыклар, аерым алганда Төркестан (Урта Азия) халыклары белән бәйләнешләре хакында матбугатта язылып килә. Ә менә татар мәгърифәтчеләренең, шул исәптән татар кызларының тугандаш Азәрбайҗан халкының мәгарифен үстерүгә керткән өлешләре хакында фәнни хезмәтләр дә, язма материаллар да юк диярлек, күренми әлегә.

Тарихи мәгълүматларга караганда, Азәрбайҗанның нефть чыгару һәм балык тоту эшләрендә хезмәт иткән татарларның саны дистә меңләп санала. Ә бит элек татар кайда яшәсә дә үзенчә яшәргә тырышкан, мәчет-мәдрәсәсен салдырган, яшьләргә белем бирүгә зур игътибар биргән. Бакуда 1906 елда татар кызлары өчен татарча (җәдитчә) мәктәп ачылу да шуның ачык дәлиле бит.

Татарларның мәгърифәт өлкәсендә тырыш эшчәнлекләре Октябрьгә кадәр Бакуда чыгып килгән “Каспий”, Октябрьдән соң “Баку эшчесе” газеталарында чагылыш тапкан. Мисал өчен, “Баку эшчесе”нең 1931 елгы 2 октябрь санында мондый белдерү урнаштырылган: “Төрек мәдәнияте сараенда (Баку) Азәрбайҗан Дәүләт институтының тел-әдәбият бүлеге янында татар секциясен оештыру җыелышы чакырыла. Җыелышка түбәндәге иптәшләрнең килүләре мәҗбүри… Г.Сәгыйдев, Хәйретдинов, проф. Гобәйдуллин, М.Хәлфина, Абдрахман Шәрипов, Вәисов, Садыйков, Мөслимов, Идрисов, Алиев Яхъя, Исмәгыйль Биккиниев, Дәүләткилдеев, Шәмсетдинов, Юртый, Дубинин, Исаев, Абязов (рабфак)”.

Ни кызганыч, югарыда санап кителгәннәрдән безгә күренекле тарихчы галимебез, профессор Газиз Гобәйдуллин һәм аның бертуган сеңлесе Мәрьямнең генә исемнәре һәм эшчәнлекләре билгеле.

Газетаның шул ук санында “Октябрьнең берендә татар китапханәсе ачыла” дигән белдерү дә басылган. Гаҗәеп матур хәл бит бу. Ә тагын да гаҗәбрәге “Бакуда татар театры оештырыла” дигән хәбәр. “Бу эштә юлбашчылык, исем казанган артистыбыз Хәнәфи Терегуловка тапшырылды”, – ди газета. (Х.Терегулов (1877–1942) 1899 елда Гори шәһәрендә укытучылар семинариясен тәмамлап, Эриван (Ереван) губернасы мәктәпләрендә укытучы булып эшли,

соңрак Бакуга күчеп, 1905–1907 елгы революция вакыйгаларында катнаша. Азәрбайҗанда музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертә. Опера һәм балет театрында озак еллар иң төп рольләрне башкара). Тик ятмаган бит татарның талантлы шәхесләре.

Ни кызганыч, миңа бу газетаның бары бер генә саны белән танышырга насыйп булды. Безнең архивларда бүтән саннары сакланмаган. Әмма безнең өчен тагын да мөһимрәге – газета "хатын-кызлар сәхифәсе"н биреп барачагын да әйткән. Димәк, Азәрбайҗанда татар мәгарифе белән янәшә татар хатын-кызлар хәрәкәте дә сизелерлек булган. Бу фикер Кыргызстанда яшәп иҗат иткән галим һәм мөхәррир Вилор Акчурин язмасында да ачыклана төшә: "Татар хатын-кызларының үзенчәлекле батырлыклары хакында белми яшь милләттәшем, – ди ул. – Гасыр башында ук инде күп кенә татар гаиләләрендә ислам хорафатлары тәэсире кими башлап, татар хатын-кызлары үзләренең фикер хөрлеге, яңа тормышка омтылышлары белән башкаларга үрнәк булдылар… Әнә шуңа күрә дә бит инде 30–40–50 нче еллардагы югары катлам үзбәк, казакъ, кыргыз ирләре хатынлыкка татар кызларын алуны кулайрак күрделәр…". Галимнең бу фикере Азәрбайҗанда яшәп, хезмәт иткән татар кызларына да тулаем туры килә. Мисал өчен Тифлиста татар гаиләсендә туган Сәлимә Хәйрелислам кызы Якупованы гына алыйк. Әтисе шәһәр мөселманнарының хәйрия җәмгыяте каршында ачылган мәдрәсәдә мөдәррис-мулла, әнисе Зөләйха ханым шул ук мәдрәсәнең кызлар сыйныфында мөгаллимә. Хәйрелислам хәзрәт кызының бик яшьли ачылган сәләтен күреп, кызлар гимназиясенә укырга бирә. 1910 елда егерме яшьлек Сәлимә Азәрбайҗанның атаклы миллионеры Зәйнәлабдин Тагиев ярдәме белән Петербургның хатын-кызлар югары педагогик курсларында укый. Укыганда аның белем алырга сәләте тагын да ачыла төшә. Мөхәррире Гаяз Исхакый булган "Ил" газетасына мәкаләләр яза, Петербургта укучы татар яшьләре түгәрәге әгъзасы була.

Татар кызы булганын һичбер вакыт онытмый Сәлимә. Мәкаләләрен дә татар халкының киләчәге өчен, аның мәгарифе өчен борчылып яза. 1917 елның апрелендә Казанда үткәрелгән Бөтенроссия мөслимәләре съездында бертавыштан Мәркәз бюро рәисәсе итеп сайлана әле. Тик З.Тагиев аңа Бакуга кайтырга, Азәрбайҗан

хатын-кызлары арасында эшләргә куша. Калган гомере хакында “Хәтерләрне яңартыйк” дигән китабымда язган идем.

Шулай, үз бәхетен чит җирләрдә тапкан татар кызларының тормыш юллары бик гыйбрәтле. Пензада туып-үсеп, югары белем алып, Бакуда эшләгән бертуган Баишевалар – Гөләндәм, Өммегөлсем, Мәрьям, Шәмсекамәр, Зәйнәпләрнең тырышлыклары безгә үрнәк түгелме? Алар хакында “Халкым минем” газетасында язып чыккан идем.

Азәрбайҗанның Халык артисткасы Марзия Даутова, хатын-кызлардан беренче рәссамнары Наимә Кашаева һ.б.ларның тормыш юллары безнең өчен кызык түгелме?



*Наимә Кашаева*

Әйе, безнең горурлыгыбыз, милләтебезнең байлыгы бу кызлар дияр идем. Тик, ни кызганыч, алар хакында башкалар яза, тормыш юлларын өйрәнә, “безнекеләр” ди. Шунысы үкенеч: без белмәгән, тормыш юлларын өйрәнмәгән талантлы кызларыбызны киләчәк буын эзләмәс инде. Безнең буын да аларны барлап, табып бетерә алмады.

Тагын Азәрбайҗанда эшләгән кызларыбызга тукталыйк әле. Петербургта 1872 елда хатын-кызлар өчен ачылган Югары медицина курсларын татар кызларыннан беренче булып Разия Котлыярова тәмамлый. Кулына диплом алгач, башта үзе туган Касыйм шәһәренең өяз хастаханәсендә эшли, соңрак Бакуга күчә. Бакуда ул табибә, актив җәмәгать эшлеклесе булып танылa. Халык арасында медицина буенча лекцияләр укый. Кыз балаларны гимназияләргә кереп укырга өндәп чыгышлар ясый. 1904 елдан ул Оренбургка күчеп эшли башлый. Монда да халык арасында үзенең тырыш хезмәте белән хөрмәт казана.

Шул ук курсларны 1898 елда тәмамлаган Әминә Батыршинаны да Бакуга эшкә чакыралар. Табибә буларак ул да үзен бик тиз танытып өлгерә. Шәһәрдә рус телендә чыга торган “Каспий”

газетасында төрле темаларга мәкаләләре басыла. Үз мәкаләләреннән тыш, ул Казан ориенталисты Гөлнар (Лебедева Ольга Сергеевна) ханымның Римда француз телендә чыккан “Мөслимәләр хәрәкәте” әсәрен русчага тәрҗемә итеп бастыра. Болар өстәвенә “Мөселман затлы ханымнар җәмгыяте”нең иң актив әгъзасы буларак, җәмәгать эшләрендә катнаша. Идел буенда яшәүчеләр арасында ачлык башлангач, аларга ярдәм оештыруны башлап йөрүчеләрнең дә берсе ул була[1].

“Мөселман затлы ханымнар җәмгыяте”, нинди милләттән һәм нинди дин тотучылар булуга карамастан, ярлы гаиләләргә һәрдаим ярдәм итеп тора, хокук мәсьәләләре буенча да, дәүләт органнарына үтенеч белән мөрәҗәгать итүдә дә ярдәм күрсәтә. Озакламый җәмгыять Баку шәһәрендә “Мөселман хәйрия җәмгыяте” итеп үзгәртелә. Җәмгыятьнең әгъзалары арасында татар хатын-кызларыннан Хәнифә Меликова, Әминә Терегулова, Хөсниҗамал һәм Бәдигыльҗамал Мамедовалар, Фатыйма Тәнбиеваларның исемнәрен күрәбез. Җәмгыятьнең төп максаты итеп хатыннарның сәяси һәм мәдәни белем дәрәҗәләрен күтәрү, алар арасында мәгариф, мәгърифәт эшләрен тарату кебек зур бурычлар куела. Аларның эшләре нәтиҗәсе булып, хатын-кызлар өчен мәктәпләр ачыла башлый. “Али Бәйрәм” исемендә махсус клуб та ачылып, мәгърифәт эшләрен киң җәелдерүгә ярдәм итә.

Шундый мактаулы эшләрдә үзен күрсәтеп өлгергән тагын бер татар кызының, ягъни Латыйфа Бирюкованың (1896–1980) хезмәтләренә тукталыйк әле. Ул, югарыда әйтеп үтелгәнчә, 1906 елда татар кызлары өчен ачылган мәктәптә, аннан соң педагогик курсларда белем ала. 1918 елда Бакуда ачылган ярдәмчесез балалар (беспризорниклар) белән эшли башлый. Яшь кенә кызга урам тәрбиясе алган балалар белән эшләү җиңел булгандыр дип уйлап та булмый. Әмма Латыйфа алар белән уртак тел таба алган, барысына да түзгән һәм матур нәтиҗәләргә ирешкән.

1920 еллар Азәрбайҗанда хатын-кызлар хәрәкәте җанлана башлаган вакыт. Биредә эшне оештыручылар хатын-кызлар өчен махсус клублар ачудан башлыйлар. Клублар, кагыйдә буларак, мөселман динендәге хатын-кызлар өчен оештырыла. Клубларда укый-яза

[1] Каспий. 1907. 14 декабрь; 17 декабрь.

белмәүчеләр өчен наданлыкны бетерү курслары эшли башлый. Йорт эшләре, аш-су пешерү, тегү-чигү һөнәрләренә өйрәтү түгәрәкләре барлыкка килә. Пәрәнҗә, чадра киеп йөрүчеләр арасында әкренләп аңлату эшләре башлана, хатын-кызларның ирләр белән бертигез хокукта яшәргә тиешлекләре хакында лекцияләр укыла һ.б.

Баку читендәрәк ачылган Бинәгади дигән шундый клубны җитәкләргә кушалар тырыш кыз Латыйфага. Клубта эш башлау җиңел булмый, билгеле. Эшкә иске тормыш тарафдарлары булган һәм һәр яңалыкны күрә алмаган дин әһелләре дә, алар янында йөрүче кушташнар да аяк чала. Татарның тырыш кызы бу эштә дә сынатмый. Йөзләрчә хатын-кызлар укырга-язарга өйрәнә, чадраларын салып, җәмәгать эшләренә катнаша башлый.

1923 елдан Латыйфага Бакуның эшчеләр районнарында эшләү тапшырыла. Биредә дә ул эшне хатын-кызларны оештырудан башлый. Элегрәк урамга чыгарга да куркып йөргән хатыннар үзләрен кыюрак тота, кайберләре эшкә урнаша, матди якларын яхшырту хакында уйлана башлыйлар.



*Латыйфа Бирюкова*

Эшендә ирешелгән уңышлар хакында башкалар белән уртаклашасы килә Латыйфаның һәм ул "Шәрг гадыны" ("Шәрык хатыны") журналына мәкаләләр яза башлый. Озакламый журнал редакциясе аны эшкә чакыра һәм җаваплы секретарь вазыйфасын йөкли. Журнал хатын-кызлар арасында яратып укыла торган матбугат чарасына әйләнә. "Хатын-кызлар тормышының һәр почмагына күз сала, һәр сорауга җавап бирергә, авыр чакларда ярдәмгә килергә тырыша", – дип язылган журнал хакында[2].

[2] Сабир Ганҗәли. Һәр сәтирдә бир тарих. Бакы: "Шур", 1994. 261 б.

Латыйфа журналда сәламәтлеге буенча пенсиягә киткәнче эшли.

Үкенечләр белән дөнья тулы. Шулай да, болытлы көндә ялтырап кояш чыккан кебек, “мин татар” дигән әледән-әле үзебезнекеләр килеп чыга. Күңелләрен төшермәскә, милләтебезнең горурлыгы итеп санарга иде аларны. Үзебезнекеләр бит алар!

# ҮТКӘН ЕЛЛАРНЫҢ КҮРКӘМ ХАТИРӘСЕ

1992 елның 19 июне. Бу көн тарихыбызда иң мөһим вакыйга – беренче чакырылыш Бөтендөнья Татар Конгрессының беренче утырышы ачылган көн. Татар томышында бу тарихи факт. Әмма иң башта ул – миллионлаган татарның бәйрәм көне. Килер бер көн (Аллаһы Тәгалә насыйп итсен), киләчәк буыннарыбыз бу көнне “Бәйрәм көне” дип искә алырлар әле.

Бу көндә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Указы буенча башкалабыз Казанда дөньяга сибелеп яшәгән милләттәшләребезнең вәкилләре җыелды һәм сәгать 10 да герой шагыйребез Муса Җәлил исемен йөрткән театр бинасында Конгрессның пленар утырышы башланды. Ул Татарстан премьер-министры Мөхәммәт Сабиров рәислегендә ачылды. Залда утыручылар арасында Америка, Төркия, Финляндия, Германия, Польша, Япония, Австралия, Кытай, Швеция, Румыния, Кыргызстан, Казахстан, Башкортстан һәм Россиянең барлык өлкәләреннән диярлек килгән абруйлы кардәшләребез утырды. Аларның барысы да Татар Конгрессының киләчәктә газиз милләтебез өчен файдалы һәм уңышлы эшләр башкарачагына якты өметләр баглап килгәннәр иде.

Конгресс барышында залга кермәгән, сыймаган халык урамда бәйрәм итте. Исәнләшүләр, танышулар, күрешүләр, кочаклашу, елашулар…

Искиткеч, мәңге онытылмаслык күренеш иде бу. Нәкъ бәеттәгечә:

*Өйгә керсәк, тышка чыксак,*
*Шатлыклы тавыш иде.*

Шатланырга хаклары бар иде мөхтәрәм милләттәшләремнең. Бу көнне гасырлар буе көтте бит халкым. Араларында гайрәтле көрәшчеләре ул көн килер өчен гомерен бирде, зинданнарда интекте. Ниһаять, СССР дигән империя җимерелүе өметләргә юл ачкан кебек булды. 1989 елның февралендә үк Бөтентатар иҗтимагый үзәге оештырылды. Үзәк тарафыннан “Милләт”, “Известия ТОЦ” газеталары чыга башлады. Шушы 1989 елда Ислам дине кабул итүнең мең дә бер йөз еллыгы бәйрәм ителде. Республика

фәнни җәмәгатьчелегә үтенече буенча Президентыбыз М.Шәймиевнең 1991 елгы 30 сентябрь Указы нигезендә Татарстан Фәннәр Академиясе төзелде. Казаныбызда татар мәктәпләре, гимназияләр ачылды, югары уку йортларында ана телебез дә кертелә башлады (мактану булса булыр – Казан авиация институтында татар теле дәресләрен мин үзем алып бара башлаган идем).

Казанда дистәгә якын яңа газета-журналлар чыга башлау башкалабыз тормышына яңа сулыш өрде дияр идем. “Шәһри Казан”, “Мирас”, “Мәгърифәт”, “Татар иле”, “Идел”, “Салават күпере” һ.б. кебек газета һәм журналларыбыз халык арасында зур популярлык казандылар, үсеп килүче буынны тарихи һәм рухи мирасыбызга якынайттыдар. (Ни кызганыч, бүген бу милли басмаларыбызның кайберләре бөтенләй чыкмый, ә кайберләре күп кенә тиражларын югалттылар. Әйтергә оят, интернетка кереп баткан зыялыларыбыз да газет-журналлар укымый. Телевидениегә чакырылганнарның чыгышларын тыңлаганда, алар өчен оялудан аркалар куырылып китә).

Республикабызда 1992 елның 21 мартында булган референдумны онытып буламы? Референдум күпмилләтле республиканың бердәм булып демократик юл белән мөстәкыйль дәүләт булып яшәргә омтылышын ачык күрсәткән иде. Хәер аның нәтиҗәсе теләгәнчә булмавы бер яктан үкенечле булса, икенчедән Россиядә булып узган вакыйгалар мөстәкыйльлек өчен көрәшнең ни белән бетәчәген ачык күрсәтте ич.

Ә менә 1992 елның 9–13 июнендә үткәрелгән “Төркиләрнең, рухи мәдәнияте вә тарихы: үткәне һәм бүгенгесе” дигән темага Казаныбызда үткәрелгән халыкара конференция эзсез югалмады, шөкер. Хәзер дә тугандаш халыклар белән аралашулар дәвам итә, күңелне сөендерә. Кыскача әйткәндә, әйтеп үткән һәм әйтми калдырган күп кенә чаралар азатлык өчен күтәрелгән көрәш нәтиҗәләре иде.

Конгресста чыгыш ясаучылар, аларның теләкләре, алда куйган бурычлар хакында стенографик хисап 1992 елда ук басылып чыкты. Матбугатта да Конгрессның эшләре хакында даими язылып, дөньяга чыгып тора. Шуңа күрә Конгрессның 25 кешедән торган Башкарма Комитеты һәм аның рәисе итеп олуг тарихчы галим, Казан

дәүләт университетының кафедра мөдире, профессор Индус Ризак улы Таһиров сайлануын гына әйтеп үтәм.

20 июньдә Конгресснең эше секцияләрдә дәвам итте. Барысы 15 секция (түгәрәк өстәл) иде. Минем өлешемә “Милләт, хатын-кыз һәм гаилә” секциясенә катнашу бәхете тиде. Секциянең җитәкчесе “Сөембикә” журналының баш мөхәррире Р.Туфитуллова иде. Без зур дулкынлану белән Актерлар йортына җыелдык. Залда иң зур хөрмәткә ия кунаклар – өлкән язучыбыз Гомәр ага Бәширов, сөекле җырчыбыз Фәридә апа Кудашева, хөрмәтле абыстайларыбыз Рәшидә Исхакый һәм Сәйдә Аппакова, күренекле галимәләр Мәдинә апа Рәхимкулова һәм Флора Әхмәтовалар, ерак араларны якын итеп килгән кадерле ханымнарыбыз Шәмсия Апакай, Нәркиз Агишлар… Бүген кайберләре мәрхүм инде, рухларына дога кылып искә алыйк.

Алар сөйләгән сүзләр бүген дә хәтердә әле. “Әйдәгез, татар хатынының бөтен матур сыйфатларын бөтен дөньяга танытыйк, – диде Мәдинә апа. – Элек күрсәтә алган бит татар хатыны үзенең матурлыгын, чиста-пөхтәлеген, гыйлем-мәгърифәтле булуын, гаиләсенең тоткасы һәм балаларына оста тәрбияче булуын. Дөнья безгә карап соклансын, үрнәк итеп куйсын Татар хатынын”. Йә, Аллаһы Тәгаләм, кайсыларыбыз ирешә алды икән мондый бөеклеккә!

Шәмсия Апакай һәм Нәркиз Агишларның чыгышлары да залны тетрәндерде. Алар туган телебезне үзләре дә онытмасын һәм балаларына да өйрәтү өчен сабак укуларын һәм укытуларын, балалары белән фәкать татар телендә генә сөйләшүләрен, татар җырлары язылган магнитофон тасмаларын тыңлауларын, дога укыган кебек Тукайның “Туган тел”ен җырлауларын, газиз туфракны сагынуларын шундый ихласлык белән сөйләделәр ки, залда утыручыларның күзләре яшьләнде. Мин тетрәнеп “Газиз Аллам, аерма туган җиремнән” дип теләк теләдем. Бәлки мин генә дә булмаганмындыр.

Мине тетрәндергән шундый очраклар аз булмады әле. Тагын берсе хакында язмый кала алмыйм икән. 1997 елның августында Конгресснең икенче корылтае булды. Кунакларны Изге Болгар җиренә экскурсиягә алып бардык. Теплоходта барганда кунакларның күбесе киң җәелгән Чулман өстенә карап сокландылар. Теплоходтан төшкәч, ялгышмасам Хабаровскидан килгән бер ханым су өстенә яулык җәйде дә су эчте. Мин сәбәбен сорагач: “Әбиемнең

васыяте шулай: Туган җиргә аяк баса алсагыз Идел суын минем өчен авыз итегез, үтенәм, – диде әбием, шуның теләген үтәдем, шөкер", – дип дога кылды. Бу ханымның исемен оныттым, ә кыяфәте, йөзендә чагылган канәгатьләнү хисе, сөенече күз алдымда.

Секция утырышында татар хатын-кызларының иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген җанландыру, татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү, милли гореф-гадәтләрне, йолаларны саклау, татар гаиләсенең яшәеш сферасын киңәйтү һәм аны милли рухта коруга булышлык итүгә юнәлдерелгән бер адым ясалды – Бөтентатар хатын-кызлар берләшмәсе (ассоциясе) оештырылды. Берләшмәнең советы, идарәсе булдырылды. Идарә рәисе итеп Р.Туфитуллова, аның урынбасарлары итеп мин, ягъни Т.Биктимирова һәм Л.Шакирҗанова (Л.Шагыйрьҗан) сайланды. Урыннарда берләшмәнең бүлекчәләрен оештыру максаты куелды. Күренекле галимәбез Флора Әхмәтова-Урманче тәкъдиме белән берләшмәгә "Ак калфак" исеме бирелде.

"Ак калфакның" үз заманында халкыбыз күңеленә кереп калырдай эшләре аз булмады. Асылыбызга кайтыр өчен, меңъеллык тарихыбызны каныбызга сендерер өчен, гаиләдә, мохитыбызда хатын-кызның дәрәҗәсен күтәрү өчен оештырылган "Гыйффәт туташ", "Киленбикә" кебек чараларның әһәмиятен аерым күрсәтеп үтәсем килә.

Мин Конгресс башкарма комитеты аппаратында 1992–1997 елларда эшләдем. Ул чагында аппарат Татарстан Министрлар комитеты бинасының 5 катында 15 кв. метрлы бер бүлмәгә урнашкан иде. Без анда фонд директоры Лилия Нарбекова, секретарь Рәйхана Сибгатуллина, бүлек җитәкчеләре Рәшит Ягъфәров, Илдар Миңгәрәев, компьютерчы Люция Гыймадиева, бухгалтер Венера Кабировналар белән эшләдек. Венераны соңрак Нажия Салаватовна алыштырды.

Ничектер бер фикердә, дус булып эшләдек дип әйтә алам. Рәхмәт хезмәттәшләремә. Безнең эш күбрәк Конгресска йомышы төшеп килүчеләрне кабул итү, мөмкин кадәр аларга ярдәм итү һәм Конгрессның төрле төбәкләрдә бүлекләрен булдыруга булышу белән бәйле иде.

Безнең бәхеткә төбәкләрдә татар иҗтимагый үзәкләре оешкан һәм милләтпәрвәрләребез аларда тупланган иде. Эшне алар белән тыгыз элемтә урнаштырып башладык. Бу эштә иң зур ярдәмче Рәшит Ягъфәров булды. Чөнки ул Татар иҗтимагый үзәгенең дә җитәкче вазыйфаларын башкарган, эшкә яраклы кешеләрне дә яхшы белә иде.

Төбәкләрдән килүчеләр төрле булган кебек, йомышлары да төрле булып, бик еш кына уңайсыз хәлләрдә дә кала идек. Мисалга Украинадан килүчеләрне искә алып китәм. Мин эшләгәндә ике ел рәттән Конгрессның андагы бүлеге җитәкчеләре 20 дән артык баланы ял итәргә дип лагерьларга урнаштыру өчен алып килделәр. Күпме йөгерергә, күпме ишекләр кагарга туры килде аларны урнаштырырга. Бөтендөнья Татар Конгрессы булсак да, акчабыз юк иде бит әле.

Командировкалардан кайтып кермәдек дия алам. Мин үзем Минскидан Иркутскига кадәр Россия төбәкләрен иңләдем. Мин генә түгел, башкалар да шулай йөрде, кулдан килгәнен дә килмәгәнен дә үтәргә тырышты.

Барып кергән җиргә татар гадәте буенча ниндидер күчтәнәч алып барасы килә иде. Әмма, әйткәнемчә, акча юк. Иваново губернаторы (исемен онытканмын, гафу) янына 14 сумлык курай тотып кереп, бүләк итеп чыктым. Әле дә уйлыйм, ничек кире бирмәде икән губернатор ул курайны. Рәхмәт инде.

Хәзер Конгресста эшләүчеләргә сокланып та, көнләшеп тә карыйм. Акчалары да бар, эшләре дә масштаблы. Ходаем, тагын да шулай матур эшләре белән сөендерсеннәр иде. Ел саен нинди зур, төрле-төрле форумнар оештыралар – яшьләрнеке дисеңме, дин әһелләренеке, хатын-кызларныкы, галимнәрнеке дисеңме… Дөрес бәһали беләбез микән дип уйлыйм кайчакта.

Тик нигәдер кайберәүләр тискәре бәя бирәләр бу эшләргә. Хәтта Сабан туе бәйрәмен үткәрү дә телгә начар яктан керә хәзер. Әмма шуны әйтәсем килә: җыр-бию кебек матур күренешкә төрле спорт ярышлары да кушылган олы бәйрәм тагын кайсы халыкта бар соң? Бөтен дөньяда югары бәяләнеп, татарларны танытты бит бу бәйрәмебез. Интернетта аноним рәвештә теләсә нинди пычрак атып

утырганчы, Конгресс Башкарма комитетына килеп эшлекле тәкъдимнәре белән уртаклашырга ярамый микән бу “белгечләргә”?

Сүземне Алтын Урдада XIV йөз ахыры һәм XVI йөз башларында Сарай шәһәрендә яшәгән халык җырчысы һәм сынчы Субра сүзләре белән тәмамлыйм.

*Бары да үлә дусларым,*
*Үлмәгәндә ни үлми?*
*Батыр кеше үзе үлми.*
*Батыр үзе үлгәндә дә*
*Эше белән сүзе үлми,*
*Аңа чыккан җыр үлми.*

Менә шулай. Бөтендөнья Татар конгресына да, аның матур эшләренә дә җырларда җырланырдай озын гомер телик, уңышлар телик.

## НИК ҮЗӘКНЕ ӨЗӘ ҮТКӘННӘР…

Менә, исәннәргә тагын яз җите. Киләчәк язларыбыз да илләребезгә, көннәребезгә тынычлык белән һәм борчу-хәсрәтсез килергә язсын. Быел Җиңү көненең 73 еллыгы. Хаклы рәвештә матур итеп искә алыныр бу көн дип өметләник. Тагын “Үлемсезләр маршы”на (“Марш бессмертных”) чыгып, җиңүчеләрнең портретларын тотып урамнардан узарлар. Насыйп булсын. Минем бу “Маршка” үз әниемнең рәсемен күтәреп чыгасым килә, тик, ни кызганыч, аякларыма ышанмыйм. Бу хәл, бу теләк сугыш чоры әниләренең газапларын оныта алмаган минем кордашларымда да туа торгандыр. Чөнки әниләребезнең Җиңүгә керткән изге өлешләре, изге хезмәтләре безнең күз алдында иде. Без кичергән сугыш елларының, көннәренең күбесе хәтердә, чөнки ул еллардагы рәхимсез сугышның яралары, безнең йөрәктә мәңге төзәлмәслек җәрәхәт булып урнашып калды. Без – балалар әле, ә менә фронтка иң якыннарын озатып, кара урман кебек ишелеп төшкән кайгы-хәсрәт эчендә калган әниләребез, әбиләребез, ниләр кичерде икән? Ничек чыдадылар икән? Исән чакларында барысы да хакимияттән олы хөрмәт күреп, җанга рәхәт бер сүз ишетә алдылар микән? Юктыр, барысы да түгелдер. Шулай да, бәлки, исәннәре күреп, ишетеп калгандыр. Аларга бу олы сүзне, олы бәяне русның күренекле язучысы Федор Абрамов Россия язучылар съездында әйтеп калдырды: “Сугыш вакытында икенче фронтны хатын-кызлар ачты”, – диде. Бу искиткеч ачык хакыйкать иде. Шуңа да бу сүзләр яңгырагач, зал бер мәлгә тын калды, соңыннан көчле алкышларга күмелде. Ни кызганыч, съезд үткәрелгән ел хәтеремдә калмаган. Съезд барышын Үзәк телевидение күрсәткән иде.

Ә минем әнием – Сәфәрова Шәрифә Хәйретдин кызы, сугыш вакытында ишеткән бер рәхмәт сүзен, гомере буе яхшылык белән искә алып елый иде. Ничәнче ел булды икән, язгы чәчүгә дигән орлыкны Коркачык станциясеннән күтәреп ташыйбыз. Шулай, капчыкларыбызны аллы-артлы күтәреп кайтырга чыктык. Аякта юеш чабата, арып-талып язгы суга басмаска тырышып атлыйбыз. Шулчак станциягә солдатлар төялгән бер эшелон килеп туктады да,

вагоннан берәм-берәм солдатлар сикереп төшә башлады. Без дә туктадык. Күзебез белән якыннарыбызны эзлибез, кайберәүләр “татарлар бармы, кайсы районнар?” – дип сораша ук башлады.

Менә бер өлкәнрәк кеше төште, командирлары булды ахры. Ул бик тиз генә солдатларга тезелергә кушты. Алар тезелгәч, безгә таба борылып җиргә тезләнде дә: “Спасибо”, – диде. Бер сүз дә әйтә алмый калдык, солдатлар тиз генә сикерешеп менүгә, поезд кузгалып та китте”.



*Фотода әни бертуган апам Гөлсәгыйдә белән*

Әнинең бу истәлекне сөйләгәндә ни өчен елаганын аңлыйм. Ирләрдән ишетеп ияләнмәгән бу кадерле сүз, олы хөрмәтнең мондый чагылышы аны чиксез дулкынландырган булган, күрәсен.

Коркачык белән бәйле тагын бер вакыйга хәтеремдә. 1944 елның үзәккә үткән салкын буранлы көне. Өчкә-дүрткә бөгелеп чана тарткан хатын-кызлар авылыбыздан 60 чакрым ераклыкта урнашкан шул Коркачык станциясенә ашлык илтәләр. Өсләрендә ямаулы күлмәк, иске бишмәт, кайсылары шәл урынына ашъяулык бөркән-

гән, аякларында чабата. Репин картинасындагы бурлаклар кебек җан ачысы белән чана тарталар. Үсә төшкәч белдем: колхоз амбарларында ашлык калдырырга рөхсәт булмаган икән (ач балалардан, тол калган хатыннардан курыкканнадыр инде). “Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!” – иде бит. Шулай, орлыкны кыш башында илтәләр, язын алып кайтып азап чигәләр иде әниләр.

Тагын бер хәл һич исемнән чыкмый. Әни белән телевизор карап утырабыз. Сугыштан азат ителгән җирләрдә хатын-кызларның, сукага җигелеп, җир сөргәннәрен күрсәтәләр. Әни бәгърем елый башлады…

– Шулай онытылмас микәнни бу газаплар, – диде ул. Үземнең дә Шәмсениса апай белән сука сукалавым һаман исемә төшә. (Сәфәрова Шәмсениса апа әниемнең якын дусты, гел бергә эшләделәр). Бригадир сукага чыгарга кушкач, башта ышанасы да килмәде. “Чи калган җирләрне сукаларсыз, анда ат та, сыер да бата (колхозда атларның юньлесе фронтка алынган, үгезләр дә бер-ике генә баш, сыер җиккән очраклар еш була иде). Җәмил абый (сүз яше 70 тән артып киткән өлкән кеше хакында) сукагызны тотып йөрер әнә”, – дип каршы сүз әйтерлекне калдырмады. Басуга бардык, җигелеп тартабыз суканы. Аяк бата, чабатаны өстерәп чыгарып булмый. Суык балчыкка ялан аяк басып карыйбыз. Суканы тартырга юк кына бит, җитми генә бит көч. Өчәүләп утырып еладык шул чакта.

И, газиз Аллам… Тормышта үзем күргән газапларны искә алмаска мин риза. Әмма әнинекен оныта алмыйм. Аңа шул газаплары өчен кадер-хөрмәтем аз булгандыр төсле тоела, җаным әрни.

Әти сугышка киткәндә бурасы гына күтәрелгән өй, ярты капчык борчак оны калган йортта. Ул өйне эшләтеп бетерергә кайдан җай табуын сорадым әнидән бервакыт. “Атагызга килгәндә килен әйберсе итеп килгән күпме урын-җир, ашъяулыклар, өстәл япмалары, тәрәзә өлengeләре барысы да сатылды. Хәтта ки яхшырак күлмәкләрем, сөлге тастымалар дә бетте шул йортка кереп”, – дип аңлатты әни.

Әниемнең әнисе Майшәрәф Ризван кызы (Татарстанның элек Кызыл Юл, хәзер Арча районына керә торган Шекә авылы кешесе) кул эшләренә – тегү, чигү, палас, эскәтерләр, сөлгеләр сугу, намазлыклар чигеп ясау, бәйләү, эшләренә оста булган. Әниемнең саты-

лудан калган әйберләрен күреп сокланмаган кеше булмый иде. Хәзер дә әбиемнең төсе итеп кызыл башлы сөлге һәм бер ашъяулыкны истәлеккә саклыйм. Алардан җаныма җылылык килә төсле, битләремә куеп юанам. Әниемә йортны да эшләтеп, торыр хәлгә китерергә нәкъ менә Шекәдәге әби-бабайларым булышканына иманым камил. Бүтән таяныч юк иде бит безнең.

Әмма сугыш башында аларның үз башларына төшкән хәсрәтләр тагын да куркынычрак булган икән. Шаһимәрдән бабам белән Майшәрәф әбиемнең олы уллары (әниемнең энесе) Гыйниятулла абыебыз сугыш башында күрсәткән батырлыклары өчен II һәм III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Ә менә Сталинград сугышы вакытында каты яраланып, сугыш кырында ятып кала. Җиңү шатлыгыннан әллә яралыларны җыярга онытканнар, белмим. Әмма абыебызның карлы басуда яралы аягы өшегән. Бераздан, сугыш кырында ятып калганнарның кесәләрен актарырга чыккан бер авыл кешесе тапкан аны. Абыйның гомере бетмәгәнгәдер, чанага тартып авылга алып кайткан аны ул кеше, рәхмәт.

Абыйны өстәлгә яткырып, дилбегәләр белән ныклап бәйләп куялар да, бернинди дару-фәләнсез (бу котычкыч вакытта авылда нәрсә булсын), утын кискән кебек пила белән кисәләр аягын. Авыртуга чыдый алмаган яралы абыем дилбегәләрне өзеп берничә мәртәбә сикереп тора. Шулай ике тапкыр кискәннәр аның аягын. Мин белгәндә абыйның аягы бот төбеннән үк юк иде.

– Әни Гыйниятуллага багышлап роза гөле утырткан иде. Башта гөле шулкадәр матур булып үскән, шау чәчәккә күмелгән. Әмма кинәт саргаеп, кибеп корган. Әни шуннан аңлаган баласының авыр хәлдә калганын, – дип сөйләде әни.

Бәла үзе генә йөрми диләр бит. Икенче Габделмалик исемле абыебыз колхозда эшли башлаган. 12 яше генә тулган малайны Заготконторага ашлык тапшыруда җаваплы бригадир итеп куйганнар. Шулай бер баруларында ул, икмәкне тапшыргач, иптәшенә капчыкларны ышандырып калдырыган да, конторага тиешле кәгазьләрен алырга кергән. Чыккач санаса, ике капчык юк икән. Әллә иптәше үзе алган, әллә урлаткан. Кем белә? Абыйга суд ясап, сугыш законнары буенча төрмәгә утыртканнар. Татарстанда гына да калдырмаганнар бит әле, Себергә үк озатканнар.

Ходай рәхмәте, бу төрмәнең (кайсы икәнен хәтерләмим) ашханәсендә бер татар хатыны эшләгән булган икән. Ул, игелекле җан, җай туры килгәндә, абыебызга 2 чи бәрәңге бирә торган булган. Җаны җәннәттә булсын бу изге җанның. Абыйны бәлки шул бәрәңгеләр ач үлемнән коткаргандыр, Аллага шөкер, исән-сау кайта алган. Әмма әбиебезнең йөрәге бу хәсрәтләрне күтәрә алмаган шул инде. Өстәвенә Шаһимәрдән бабаебыз да Сослонгир урманына җибәрелгән вакыт булган. Кайтып, әбине җирләргә өлгергән ул, әмма Сослонгирда алган газапларыннан озак яшәмәгән, үлгән.

Аларны озатып кайткач, әни бездән яшереп кенә ишек тупсасына сөялеп бер җыр җырлады:

*Өй түрендәге миләшне*
*Берәү дә әйтми балан дип.*
*Әткәм дә юк, әнкәм дә юк,*
*Беркем әйтмәс балам дип.*

Әнинең тавышы үтә дә моңлы, матур яңгырашлы иде. Ник һаман җырламады икән дип, хәзер дә сәбәбен эзлим.

Сослонгир урманы тарихын, шөкер, язып чыктылар инде. Хәзер коррупционерлар дип аталган кабәхәтләр сугыш вакытында да булганнар икән. Күпме эшчеләрне ачтан үтереп, азык-төлекне үзләштереп, сатып ятканнар бит. Күпме кеше, бу газаплардан котылыр өчен, тилмерә-тилмерә “фронтка җибәрегез” дип гариза язган. Йә Аллам, бармы икән бәндә балаларының комсызлыгына чик?

Колхозга килгән наряд буенча әнине дә Сослонгирга җибәрергә булганнар. Ә өйдә берсенең алты, икенчесенең өченче яше тулар-тулмас ике бала: апам белән мин. Без икебез дә, өстәвенә җитмешне тутырып килгән әбиебез (әтинең әнисе) дә тамак шеше белән авырыйбыз. Өйдә районнан килгән вәкил әнине алып чыгарга көтеп тора икән. Сәкедә сузылып яткан авырулары янына хушлашырга килгән әни, түзмәгән, кычкырып елап җибәргән: “Нишлим, кая барыйм, кемнәргә калдырыйм сезне? Тагын күрешә алырмын микән?”

Үз-үземне белә башлаганда үзәкләремне өзгән беренче хатирәм бу. “Кая барыйм, нишлим? – дигән ачыргаланып өзгәләнгән әни тавышы. Үсә төшкәч, әнигә сөйләгәндә ышанмыйчарак тора иде.

“Шуны хәтерләдеңме?” – дип сорый иде мәрхүмә. Окоп казырга баруы хакында никтер ул да сөйләмәде, үзем дә сорамадым. Гомер юлларында кичергән хәсрәте, газаплары сугыш беткәч тә җитеп ашты бит бәгырькәемнең. Тол хатыннар, бигрәк тә безнең Әтнә районында, җиңел, уңай тормышның нәрсә икәнен белмәде. Ризык кытлыгы өстенә бездә урман юк, өй җылыту, утын әзерләү аларның үзәгенә үткән нәрсәләр иде. Үзләрен түгел, суык өйдә күшегеп, күгәреп утырган балаларын кызганудан җаннары бәргәләнә иде аналарның.

Әйе, әни белән бергә дусты Шәмсениса апайны да “колхозның тракторлары” дип йөртәләр иде. Иң авыр эштә алар булды. Колхоз фермасында, сушилкада алар, ындыр табагында алар, гектарлап урак урган, печән чапкан алар. Менә шул “тракторист” печән чабып кайткач, каенанасы – әбиемә тилмереп: “Әнкәй, нишләп шул кузгалакның боткасын пешереп карамыйсың, бәлки тамак туяр иде”, – дип ачыргаланганын ничек онытыйм соң?

Каенанасы – Вәрига әбием белән әнинең үзара мөнәсәбәтләре соклангыч матур иде. Сугыштан исән-сау кайткан әти безнең гаиләдән китте, тормады. Ә әби әнием янында калды, улы белән китмәде.

Тормыш җиңелрәк булмасмы дип өметләнеп, бертуган сеңлесе чакыруы буенча, әни Мари республикасының Ново-Павловское дигән совхозына барып эшкә урнашты. Әби үзе генә өйдә калган иде. Ике-өч ай үтте микән, инде сигезенче дистәгә якынлашкан әби, таякка таянып 45 чакрым җирне җәяү үтеп, без торган шул совхозга килде. “Зинһар дип әйтәм, килен, кайтыгыз кире авылга. Өебезне ятим итмә, ничек тә яшәрбез, Алла ярдәменнән ташламас. Сугыш вакытында да кешеләр кебек ямьсезләнмәдек, матур яшәдек ич, мин исән чагында бергә торыйк”, – дип үтенде ул. Без бер-ике айдан авылга әйләнеп кайттык шулай. Өебез әле дә бар. Башта әби белән әни, алар артыннан энем, апам мәңгелек йортка күчтеләр. Урыннары җәннәттә булсын. Җәй көне өебезгә кайтып торырмын әле дип өметләнәм. Насыйп булсын. “Нигеземә кура үсмәсен” дигән васыяте бар әбиемнең. Әни дә шул үтенечен олылады әбинең.

Аларның тормышы хакында бик кыска гына истәлекләр яздым. Ә язылмаганнары күпме. Рухларына догам булып барсын.

## СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАЛАРЫ

*Сугыш елларында без ни күрдек?*
*Кара таңнан башак җыеп йөрдек,*
*Китап битен кәгазь итеп гелән*
*Фронтка хат яздык корым белән.*

Әтнә районы Күлле-Киме авылында яшәүче Сәфәрова Хәтимәнең бу шигъри юлларында Бөек Ватан сугышы елларында балалар кичергән ачы хакыйкать язылган. Искә төшерик, сугыш башлану белән, Татарстан халкы гаять авыр, зур сынау алдына баса. Фронтка бертуктаусыз корал, армиягә кием, азык кирәк… Татарстан – иң якын тыл, фронт ихтыяҗларының күбесе монда үтәлә. Болар өстәвенә, Казан, Зеленодольск (Яшел Үзән), Чистай һәм башка шәһәрләребезгә Ленинград, Мәскәү, Одесса, Киев, Херсон, Бежецк һәм башка шәһәрләрдән 30дан артык предприятие күчеп килә. Аларны урнаштырасы, эшче көчләр белән тулыландырып, фронт өчен хәрби продукция чыгаруны җайга саласы бар. Татарстан, соңгы көчен җыеп, бу кыенлыкларны җиңәргә алынган беренче республика була.

Илгә төшкән афәтнең беренче көннәреннән үк фронтка киткән ирләр урынына балаларын үстереп өй тирәсендә йөргән хатын-кызлар һәм яшүсмерләр (балалар!) килә.

“Миңа ун яшь тә тулмаган иде, – дип яза Казан шәһәреннән Сабиха Җәлилова. – Әтине фронтка алу белән, “Ясалма күн” (“Искож”) заводына эшкә килдем. Мине махсус цехка алдылар. Анда зениткалар, пушкалар өчен катыргыдан заглушкалар (капкачлар, томалагычлар) эшләнә иде. Без, балалар, аларны ящикларга тутырып бардык. Шул ук ящикларга басып эшли дә идек, ник дисәң, өлкәннәр белән бертигез эшләргә туры килә, ә буй кечкенә. Стаханов талоннары һәм тулы карточка алып эшләдем. Мин ишле гаиләгә зур терәк идем: көнгә 600 грамм ипи алып кайтам бит инде. Сугыш вакытында бик зур бәхет иде бу! Ялсыз-нисез көнгә 12шәр сәгать эшләдек”.

Тагын бер истәлек. Аны Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында яшәүче Кәримова Суфия Сәлах кызы сөйли. “Без 1933 елны гына Казанга күчеп килгән идек. Гаиләдә 5 бала. Әтине 1941 елны сугышка алдылар. Ачлык-ялангачлык өй саен. Без яшәгән Сабин бистәсе кырында торф чыгара башладылар. Мин, 11 яшем тулыр-тулмас, җәйге каникул вакытында торф чыгаруда эшли башладым (май аеннан – октябрьгә кадәр). Директорыбыз Гайсин фамилияле кеше иде. Ул да, торф чыгаручы олырак кызлар да мине кызганалар, чөнки бик ябык идем. Торф чыгаручылар өчен ашханә эшли, көнгә бер мәртәбә мине шунда бушка ашаталар, ә эштән туктап, мәктәпкә киткән вакытта, ел саен 3 метр ситсы бирәләр иде. Өч ел эшләдем шулай, ә аннан соң заводка эшкә кердем. Мине кызганган олы апаларның алар үлгәнче яннарына барып йөрдем. Барысы да аяклары шешеп газапланып үлделәр”.

Бу истәлекләр – диңгездәге бер тамчы. Әмма алар – әле сабыйлыктан да чыгып бетмәгән меңнәрчә балаларның ил язмышын олылар белән бергә күтәргән уртак язмышларын сөйләүче дәлилләр бит.

1941 елның җәй һәм көз айларында ук Татарстанның бик күп мәктәпләрендә укучы балалардан хезмәт бригадалары төзелә башлый. Шундый беренче бригадалар Чистай һәм Зәй районнарында оештырыла. Чистай районының Актау мәктәбе пионерлары республика мәктәпләре укучыларына түбәндәге хат белән мөрәҗәгать итәләр:

“Малайлар һәм кызлар!.. Әтиләребез һәм абыйларыбыз сөекле Ватаныбызны, безне, балаларны сакларга фронтка киттеләр. Алар Советлар җирен батырларча, тормышларын да кызганмыйча, явыз дошманнардан саклыйлар.

Мондый җаваплы моментта без дә кул кушырып утыра алмыйбыз. Ватанны саклауга олылардан алып иң кечкенәләргә чаклы баскан икән, явыз фашистлар белсеннәр: социалистик колхоз кырларында безгә дә эш табылыр.

Фашист палачлар онытмасыннар: без совет балалары, яхшы һәм отличнога уку белән бергә, социалистик Ватан хакына тырышып эшли дә беләбез. Колхоз кырларында һәм җәмәгать терлекчелегендә тырышып эшләячәгебез турында пионерларча сүз бирәбез”.

Чистай пионерларының чакыруы Татарстанның барлык мәктәпләрендә тирән теләктәшлек таба. Мәсәлән, 1941 елның көзендә Чепья районында 1894, Әтнә районында 1914 укучы һәм 104 укытучы кыр эшләрендә катнаша. 1942 елның 19 апрелендә Казан шәһәре укучыларының һәм укытучыларының гомуми җыелышы уздырыла. Анда укучыларны язгы кыр эшләренә катнашырга чакырып мөрәҗәгать кабул ителә. Укучыларны язгы авыл хуҗалыгы эшләрендә катнаштыру максаты белән уку елы 20 майда ук тәгәлләнә. 5–10 сыйныфлар өчен язгы каникуллар бетерелә. Укучылар 21 майдан 31 майга кадәр тикшерү сынауларына тартылалар. Имтиханнар кыскартыла.

Уку елы тәгәлләнү белән 1942 елда авыл һәм шәһәр мәктәпләреннән 123 мең укучы, 180 отрядка берләшеп, укытучылар җитәкчелегендә 4 миллионга якын хезмәт көне эшли. 1941–1945 елларда авыл хуҗалыгы хезмәтенә 650 меңнән артык укучы һәм укытучы катнаша. Ни кызганыч, бу саннар 9–10 яшьлек авыл балаларының үгез яки сыер җигеп сукага, тырмага йөргәннәрен, кышкы салкыннарда ферма терлекләренә салам-печән, су ташыганнарын сөйләмиләр. Камыт киертергә буйлары җитмәгәч елап җибәргән авылдаш “малайларым” минем күз алдымда әле дә тора…

6–7 яшьлек балалар кырда башак җыярга чыга иделәр. “Бер башак та җирдә калмасын!”, “Син калдырган башак Гитлерга ярдәм!” дигән лозунгларны күтәреп, басуга алып барып, таякларга элеп куялар иде. Ялан тәпиләрне камыл ертып бетерсә дә, “Барысы да фронт өчен” булгач, чыдарга тырышылган күрәсең, елаучылар булмый иде. Бу хәлләр сугыш беткәч тә озак еллар дәвам итте әле. Чөнки сугыш беткәнгә карап кына халык өстенә җиңеллек килмәде шул.

Кырда үскән һәр башакны югалтмыйча җыярга тырышуның да сәбәпләре бик җитди иде. Фашистлар басып алган җирләрдә сөрү җирләренең кырык җиде (!) проценты калган, йөз меңнәрчә совхоз, МТСлар җимерелгән. Өстәвенә, 1943 елда булган корылык үстерелгән игеннәрнең яртысын диярлек көйдереп бетерә. Шуңа күрә халыкның төп азыгы булган икмәккә ихтыяҗы аеруча зур булган диясе килә.

Сүзебез мәктәпләр хакында иде бит әле. Әйтергә кирәк, сугыш мәктәпләрнең эшен үзгәртеп коруны да таләп итә. ВКП(б) Казан шәһәр комитетының 1941 ел 5 сентябрьдәге карары нигезендә, мәктәп биналарын госпитальләр итеп файдалану сәбәпле, укулар өч сменада алып барыла башлый. Зеленодольск, Чистай, Алабуга, Бөгелмә мәктәпләре дә өч сменалы укуга күчәләр.

Укыту-тәрбия эшләре дә үзгәртелә. Дәресләрдә укучыларны совет патриотизмы рухында тәрбияләүне көчәйтү таләп ителә. Гражданнар сугышы тарихын өйрәнү өчен сәгатьләр арттырыла. География дәресләрендә топография өйрәнүгә, физикадан элемтә һәм сигналлар, химиядән – агулаучы матдәләр һәм аларга каршы көрәш чараларына күбрәк урын бирелә. Укучылар һәртөрле хәрби оборона, ПВО (һава һөҗүменә каршы), санитария занятиеләренә тартылалар. Кыз балалар санитария дружиналары әгъзалары, радист, телефонист, телеграфист булырга әзерләнәләр.

Шунысы да мәгълүм, 1941/42 уку елында ук Татарстан укучыларының шактый өлеше (20 процентка якыны) укуга йөрми. Моның сәбәпләре төрле: материаль мохтаҗлык, өс-башка һәм аякка кияргә булмау, авыручылар күбәю һ.б. Әмма төп сәбәпләрнең берсе, инде әйтеп үткәнчә, балаларның завод-фабрика, авыл хуҗалыгы эшләренә тартылуы. 1942 елның беренче яртысында ук Казан шәһәрендә завод-фабрикалар өчен 18 мең яшүсмер (бала) эшкә тартыла. Бер үк вакытта хәрби заводларга кадрлар хәзерләү өчен һөнәр мәктәпләре ачыла.

Республика буенча алынган мәгълүматларга караганда, Татарстанда 1942 елда 14 тимер юлчылар мәктәбе, 27 ФЗӨ мәктәпләре ачыла һәм аларда 167 мең эшче хәзерләнә. Укуны тәмамлау белән, аларны Татарстанга гына түгел, СССРның башка өлкәләренә дә тараталар. Архив материалларыннан күренгәнчә, 1943 елның 5 сентябрендә генә дә 525 яшүсмер – Сталинградка, 79ы – Свердловск өлкәсенә җибәрелгән.

Бу саннар сугыш чоры балаларының авыр язмышын аңлата, чөнки аларның күбесе ФЗӨ мәктәпләренә мәҗбүри тартылган сабыйлар була.

Сугыш чорының олыларга да ифрат дәрәҗәдә каты булган законнары, тәртипләре балалар өчен икеләтә-өчләтә авыррак бул-

гандыр диясе килә. Васильево урманчылыгында урнашкан 30 нчы һөнәр мәктәбенең сугыш еллары өчен бик тә гадәти булган көн тәртибе белән танышкач, бу фикер тагын да ныгыды. Мәктәптә укучылар иртән сәгать 6 дан торып кичке 6га кадәр эшләгән нәни затлар булган бит. Моның өстәвенә, ул бәхетсез җаннарга хәрби күнегүләргә өйрәнү газаплары да өстәлгән була. Документларның берсендә балаларның, авылдан бәрәңге алып килеп, яшерен генә тулай торак мичендә пешереп ашаганда “фаш ителүләре” хакында сөйләнә. Әмма мәктәп директорының “бәрәңге яисә башка ризыклар пешерергә категорически тыела” дигән карары булып, балалардан ул бәрәңге дә тартып алынган.

Олылар кебек эшләп хәрби заказлар үтәгән, аның өстәвенә көн саен хәрби дәресләр белән интеккән ач балаларның өметләрен кисү нигә кирәк булды икән? Җитмәсә, аларның күбесе, өйләренә кайткач, вакытында килеп өлгерә алмау сәбәпле, төрмәләргә утыртылган. Бу хакта архивларда мәгълүматлар саклана әле. Әмма күңелле бала чакларын сугыш тартып алган һәм кинәт олыгаеп киткән балалар түзде. Аларны “әти кайткач!” дигән өмет җылытып, юатып торды. Фронттан якыннарының үлеме хакында хәбәр килсә дә, бала күңеле һаман ышанмады, көтте, бер-берсен юата белде. Сугыш чоры балаларының күңеле “шәфкать”, “мәрхәмәтлелек” дигән матур хисләр белән тулы иде әле.

Менә шуңа да балалар арасында тимурчылык хәрәкәте дә киң колач ала алды. Тимурчылар өлкәннәргә, фронтовикларның гаиләләренә өй җыештыру, утын кисү һәм яру, су китерү һәм башка күп төрле эшләрдә булыштылар. Архивтагы документларда һәм аларга нигезләнеп язылган китапларда башкарылган эшләрнең кайбер исәпләре, саннары сакланган.

Мисал өчен, “Татарстандагы 1481 тимурчы пионерлар командасы 169 мең фронтовик гаиләсенә шефлык итә, аларга 16 мең кубометр утын кисеп-ярып бирделәр”, – диелә бер документта. Моның өстәвенә, Татарстан укучыларының 74 мең тонна металл ватыклары җыеп тапшырулары, 18 меңнән артык тәмәке янчыгы, 22 мең кулъяулык, 150 мең конверт һ.б. әйберләр әзерләп фронтка җибәрүләре хакында да күрсәтелә. Арча районы Сеҗе урта мәктәбе укучылары колхоз кырларына 97 ц. көл, 121 ц. кош тизәге, 227 йөк

тирес чыгардылар, 93 килограмм бәрәңге күзәнәге җыйдылар”, – дип яза “Кызыл Татарстан” газетасы. – Бу эшләр һәр авылда, һәр колхозда башкарыла”. Чыннан да, 1943 елда гына да республикабыз мәктәпләре укучылары 1000 центнер бәрәңге күзәнәкләре, 12240 тонна көл һәм меңнәрчә тонна башка төрле ашламалар туплый алганнар икән.

1943 елны Казан мәктәпләре укучылары, өй шартларында үстереп госпитальләргә 500 килограмм яшел суган тапшыралар, дип сөйли икенче документ. Болар – тарихка кереп кала алган саннар. Ә күпме бала дару үләннәре җыйган (авылыбызда зуррак яшьтәгеләрнең кычыткан җыеп, киптереп йөрүләре хәтеремдә), күпме бала Казанда урнашкан 56 хәрби госпитальдәге яралы сугышчыларга шефлык итәргә йөргән бит әле. Бәлки һәр яхшылыкны санап торырга да кирәксенмәгәннәрдер. Яхшылык бит күңел кушуы буенча эшләнә. “Без Казанның Ленин урамында яшәдек, – дип искә алды Бурнашева Дилбәр Вафа кызы. – Ишек алдыбыздагы йортка Мелитополь шәһәреннән килгән госпитальне урнаштырдылар. Йортыбыздагы барлык балалар да госпитальгә йөрдек. Яралыларның хәлләрен җиңеләйтеп, кәефләрен күтәрер өченниләр генә эшләми идек. Миңа 10–11 яшьләр чамасы, зур кыз санала идем. Шуңа күрә миңа яралыларга кино күрсәтү эшен дә йөкләделәр. Мин шулай көн саен кино күрсәтеп йөрдем. Моның өстенә бинтлар юарга, хәтта яраларын бәйләргә булышу дисеңме, хатлар уку, язу, китаплар уку дисеңме, концертлар кую дисеңме – берсе дә калмады. Яралылар бик күп килә иде. Бигрәк тә Сталинград сугышы вакытында яралылар чиксез иде. Салкын кыш бит инде. Ишек алдында яткан яралыларга өйдән чәйнек белән алып чыгып кайнар су эчерәбез, өсләренә ябарга тырышабыз… Яралылар – безне, без – аларны кызгана идек. Безне кызганып бирәр шакмак шикәр, я конфет бирсәләр, алмый идек. Чөнки өйдәге олылар: “Зинһар, кызыгып бер әйберләрен дә ала күрмәгез, ул шикәр, конфет аларга сәламәтләнү өчен кирәк”, – дип бик нык кисәтәләр иде. Ә өйдә карточкага алган ипидән (аны да көн саен сатмыйлар иде) башка берни дә юк. Кайвакыт Америкадан килгән дуңгыз мае (“лярд” дип атала иде), кайвакыт шикәр тәмен хәтерләткән “Мальтоза” дигән нәрсә эләгә иде. Өйдәге кием-салым, йорт әйберләрен Казаннан бик еракта

урнашкан авылларга барып аз-маз он, бәрәңге кебек ашамлыкларга алмаштырып бетергән идек инде”.

1418 көн дәвам иткән бу сугышта мәктәпләр, укучы балалар тормышыннан меңнәрчә мисаллар китерергә булыр иде. Әмма бер нәрсәне – укытучыларның да, укучыларның да ил язмышы хәл ителгәндә халык белән бергә булып, бар авырлыкларны бертигез дәрәҗәдә күтәргәнен ассызыклап әйтмичә булмый. Балалар үсә торды, укытучылары артыннан фронтка китә торды… Тик укытучылар сугыш уты эчендә дә укытучы, укучылар – укучы булып калганнар икән диясем килә.

Укытучы Саттаров Нурмөхәммәтнең фронттан язган бер хатын тирән кичерешләр белән укыган идем. “Зөһрәм, сөеклем! – диелгән иде хатта. – Сугыш бетә инде, ә күңел ышанмый. Кайтып сине, балаларымны күрәсем килә. Нишләптер бер хыялым башымнан чыкмый… Мәктәпкә барырмын кебек. Укучыларымны утыртып, бер сүз дә әйтмичә, йөзләренә карап утырырмын кебек. Алар минем йөрәктәге җәрәхәтне тоярлар, башның ниләр күргәнен аңларлар кебек. Тик, Зөһрәм, ул укучыларымның да күбесен сугыш йотты бит инде. Бу җәрәхәт гомергә калыр микәнни?.. (1945 ел, 24 апрель)”. (Нурмөхәммәт 2 майда һәлак булган).

Бу сугыш тәҗрибәсе адәм баласы өчен чиктән тыш фаҗигале, күпме кыенлыклар, бәхетсезлекләр китерә торган гамәл икәне тулысы белән аңлашылды. Советлар Союзын саклар өчен күпме корбан, эзсез югалучылар, әсирлеккә эләгүчеләр, гарипләр барлыкка килде. Сугышның аяусызлыгы, аның фаҗигасе моның белән генә дә бетми бит әле. Ул сугыш кырында вафат булучының гаиләсенә искиткеч зур хәсрәт, авырлыклар, бәхетсезлекләр алып килә. Кем баласы ачлы-туклы булды? Тол солдатканыкы. Кем баласы ямауга каткан киемнән озаграк йөрде? Тол солдатканыкы. Толлык газапларын да, ятим үсү авырлыгын да, аның кимсенүләрен дә берничек тә аңлатып бетереп булмый. Үзгәртеп тә булмый.

Бүгенге иркә, назлы буын, югарыда күрсәтелгәнчә “фронт өчен” эшләгән, балалыгын күрмәгән балалар, алар күргән авырлыклар хакында сөйләгәнне тыңламый икән инде. Ни кызганыч, Казандагы уку йортларында Бөек җиңү хакында чыгыш ясаганнан соң, мин моның шулай икәнлегенә ышанып кайттым.

Йөрәкне әрнеткән тагын бер нәрсә бар. Сугыш ветераннарына күрсәтелгән игътибар, өстенлекләрне күпсенеп әйтүем түгел. Тик шул өстенлекләрнең чиреге кадәрен генә булса да сугыш чоры балаларына, әтиләрен яки якын туганнарын сугышта югалтканнарга да биреп булмады микән? Җиңүгә күпме еллар узды, ә сораулар һаман үзгәрми.

*Бөек Җиңүнең 80 еллыгына*
*багышлап*

## СЕЗ ТАРТКАННЫ…

*Хатын-кызлар тавышлана анда:*
*Кайсы көлә, кайсы елыйдыр…*
*Төнге күктә Киек каз юлымы –*
*Хатын-кызның үткән юлыдыр.*
*Роберт Әхмәтҗан*

Кеше күңеле, хәтере чиксез тирән икән. Үткән сугыш афәтен үз иңнәрендә күтәргән аналар гына түгел, аларның толлык әчесе эчендә үстергән балалары да сугыш һәм сугыштан соңгы елларның газабын оныта алмый. Сугыш беткәч тә бик тиз генә рәтләнә алмады бит әле тормыш. Еллар буе тилмереп көткән җан тынычлыгы да, яшәр өчен җиңеллек тә бик озак килмәде шул. Авыз тутырып ипи ашау өметләре дә юкка чыкты, өстән сәләмәләр дә төшмәде…

Шушы арыган-алҗыган кешеләрнең йөрәкләренә сугыштан соң кан саудырып төшкән тагын бер җәрәхәт – фронтка китеп һәлак булганнар белән күрешүдән өметләре өзелү иде. Күпме аналар балаларын “менә, әтиегез кайтыр, Алла боерса” дип юатып, һаман матур тормышка өметләндереп яшәделәр, һаман көттеләр. Әмма акланмады өметләр, тол хатыннарның, балаларның күз яшьләре тагын да тозлырак, тагын да ачырак, кайгы катулары тагын да катырак булып мәңгегә йөрәкләрендә урнашып калды.

Шунысы сокландыра, өлкән буынны бу газаплар рухи яктан чыныктырды кебек, алар гомер буе алдан буразна ярып, үз көчләре белән тормышны алып барырга күнектеләр. Менә шундый көчле рухлылар арасында Әтнә районы Яңа Шимбер авылы кызы дустым, авылдашым Әлфия дә булуы белән горурланам.

Әтисе – Сәлах абый Яңа Шимбернеке, әнисе Шәмсениса апа күрше Бәрәзә авылыннан булганнар. Матур гаилә корып яши башлаганнар алар. Сәлах абый авылыбызда йорт җиткергән, тик Мәскәү заводларына эшчеләр кирәк булгач, чакыру буенча бертуган энесе

Низами белән завод эшчесе булып киткән. Мәскәү өлкәсендәге Климовск шәһәрендә квартира алгач, алар гаиләләрен дә үз яннарына алдырганнар. Тормыш көйләнгән.

Тик 1941 елның 22 июнендә Сәлах абыйның да, миллионланган башкаларның да тормышлары җимерелә. Фронтка киткәндә бары бер үтенечен әйтә Сәлах абый хатынына: “Зинһар, ничек тә булса авылга кайтырга тырыш, балаларны да, үзеңне дә сакла”. Бу соңгы күрешү булган.

1941 елның сентябрь-октябрь айларында фашистларның бик тиз генә Мәскәүгә килеп җитүләре тарихта билгеле инде. Менә шул вакытта кешеләр тормышына бөтенләй яңа, куркыныч сүз килеп керә. Эвакуация… Бу сүз күңелләргә күпме югалтулар, күпме газап, хәсрәтләр вәгъдә иткән кебек куркыта, алданиләр күрәсен белә алмаган халык хафага төшә.

1932 елда туган Шәүкәте, 1935 елгы Әлфиясе һәм яңа туган Ринатын алып Шәмсениса апа да эвакуацияләнергә тиеш була. Юлга чыкканда бөртекләп, тырыш хезмәт белән әзерләгән күпме кирәк-ярагын, күпме балалар әйберсен ала алды икән бу апа. Җилкәсендә рюкзак, кулында күкрәк баласы. Бәхетләренә, Сәлах абыйның югарыда искә алынган энесе Низами сугышка китмәгән була әле. Ул үз гаиләсен дә, абыйсыныкын да авылга хәтле озатып куя алган һәм шунда ук фронтка киткән.

Әлфия хәтерли: “Станциядә кеше күп, аяк басар урын юк. Мин әнинең бер кулынаябышкан көйгә вагонга якынлаштык. Халык ыргылып вагонга керә башлауга, Шәүкәт абый да, әни дә халык дулкынына ияреп вагонга керә алдылар. Ә минем кулым ычкынды да, керә алмадым, калдым. Хәзер нишләргә белмәгән әни вагон эчендә ачыргалана, мин – тышта елыйм. Аерылу ачысы перрондагыларга да тәэсир итте ахыры, рәхмәт, бер солдат килде дә, паровоз кузгалып китә башлагач, мине тәрәзәдән эчкә ыргытты. Шулай мең бәлаләр белән Шимбергә кайтып җиттек”. Сәлах абый да, энеләре Низами белән Төхфәт тә сугыш кырында ятып калалар. Шулай Шимбердә яшәп кала аларның ятимнәре.

Шәмсениса апа әниемнең дусты иде. Гомер буе бергә эшләделәр. Аларны “колхозның тракторлары” дип атап йөрттеләр. Иң авыр эшне аларга кушалар иде.



*Әлфия Сәлах кызы (унда), дусты Рәйсә белән*

Әнисе эштә вакытта бөтен йорт эше Әлфия җилкәсендә. Шәүкәт абый, мәктәптән бушаганда, шулай ук колхоз эшендә. 9 яшендә беренче мәртәбә ипи салганын, ул ипи бик әйбәт булып чыгып, күрше карчыгы ипине өй саен күрсәтеп, мактап та йөргәнен көлеп искә алган иде Әлфия. Җиденче сыйныфны тәмамлауга Шәмсениса апаның Шәүкәтен ФЗУга, Әлфиясен колхоз эшенә йолкып диярлек ала колхоз җитәкчесе. Хәзер искә алып сөйләшкәндә исем китә. Калды микән якын тирәдә Әлфия эшләмәгән урман хуҗалыгы? Әле дә хәтеремдә, Әлфияне мактаганда авылдашлар: “Шәмсенисаның бу кызы ирләр эшләмәгәнне эшли, ирләр күтәрмәгәнне күтәрә”, – диярләр иде. Әмма буыннары да ныгымаган кыз бала икәнен искә алырга гына оныта торган булалар күрәсең. Соңрак Әлфия ел саен Владимир, Тверь (элекке Калинин) өлкәләренә торф чыгарырга йөрде.

Татар кызларының йөрәгенә төшкән торф чыгару эшенең искиткеч авыр эш икәнен авылдашым болай дип сөйләде: “Башта торф чыгарасы җирне агачлардан чистартырга кирәк була иде. Балта белән җирдән агачның тамырларына кадәр чистартып чыгара идек. Ул – сулы җир, балта белән чапкан саен биткә, өскә су чәчри. Балталар, пычкылар үтмәсләнә. Аларны да үзебез кайрый идек.

Ярый агачлар нечкәрәк, сирәгрәк булса. Бик куе булып, гел агачлык була иде күп вакыт. Урман-урман инде ул, бәхетен андый эшкә кермәсен.

Чистартылган җирне трактор кисеп чыга. Без шул кисәкләрне куптарып алып, киптерер өчен әрдәләнәп өябез. Сулы җир бик авыр, күтәргәндә эч авыртып, бөгелеп төшә идек. Җитмәсә, кигәвен, черки үзәккә үтә. Күчләре белән сарылалар. Башны, күзне бәйләп эшли идек. Яшь булганбыз, чыдаганбыз инде”.

Менә шулай, җәйләрен Мәскәү өлкәсе өчен торф чыгаруда, кышларын колхоз өчен урман кисүдә үтә Әлфиянең үсмер еллары.

“Үзәккә үткән тагын бер нәрсә, – дип сөйли Әлфия, – ул якларда мунча булмавы. Сасы сазлык эчендә эшлибез бит, рәхәтләнеп юынасы килә. Без яшәгән йортның хуҗасы мичкә яга да, мич кызгач, күмерен тартып, төбенә салам җәя. Чишенеп шунда кереп ята, тирләгәч, мүкәләп чыгып, бер чуен су белән тышка чыгып коена. Гел урамда гына юынып, чистарынып булмый, әбинең миченә без дә кергәләдек. Үзебез белән эшләгән яшүсмер егетләр “мичкә кергәнегезне күрдек” дип үртиләр иде.

Соңгы баруыбызда бер вагоннан мунча ясадык. Арабызда бер егет мич чыгара белә икән. Ул мунчаны карарга бөтен авыл җыелды. Соңыннан вагонны бирәсе килмәгән начальниклар да, авыл халкы да кереп юынырга өйрәнделәр. Чабынырга да, себеркегә хуш исле үләннәр кыстырырга да өйрәттек, исләре китте.

Бәдрәф юклыгы да шаккатарлык иде. Урманга бару белән, юкарак агачларны, киртәләрне алып кайтып бәдрәф ясыйбыз. Менә хикмәт, икенче елны тагын шул авылга туры килсәк, исебез китә иде. Өсләренә урман ишелеп тора, шул бәдрәф агачларын ватып яккан булалар иде.

Идән юу гадәте дә юк иде. Хуҗа хатын берәр җиргә китсә, идәндәге пычракны су белән җебетеп, көрәк белән кырып чыгабыз да, кайнар су белән шатырдатып юабыз. Идән сап-сары була. Хуҗа хатын хәйран кала иде. “Татарлар шулай, идәнне һаман юып торалармыни? – дип сораша, ышана алмый иде, бахыр. Югары культурага дәгъва иткән халык вәкиле бит, бичара.

Бервакыт токмач җәйгән вакытымда авылдашларын җыеп кайтты ул. “Әлфия әнә нәрсә ясый белә”, – дип күрсәтә аларга токмач-

ны. Гаҗәеп көлке тоела иде мондый хәлләр безгә. Яшьлек бит әле, үз халкыбызның күркәм гадәтләренә бәя бирергә өйрәнә генә башлаган чаклар иде шул”.

Элекке елларда Татарстан кешеләрен, бигрәк тә татарларны төрле-төрле төзелешләргә, ерак өлкәләргә чакырып торалар, чакырып килүчеләрне халык “вербовщиклар” дип йөртә иде. Төзелешкә чакырып авылга вербовщик килгәч, Әлфия дә Казанга китәргә була. Башта төзелештә йөк ташучы (грузчик), соңрак “Казан киез итек, киез комбинатын”да, “Кинопленка” кебек предприятиеләрдә эшли тырыш кыз. Кайда гына эшләмәсен, үзен гел яхшы яктан, өлгер, булдыклы итеп күрсәтә ул. Эшләгәнен һәр җирдә яраталар, предприятие җитәкчеләре, гел хөрмәт белән искә алып, башкаларга үрнәк итеп күрсәтеп торалар. “Социалистик ярыш җиңүчесе” дип алган мактау кәгазьләре әллә ничә. “Хезмәт ветераны”, “Казанның 1000 еллыгы” истәлегенә бирелгән медальләре бар. Шәһәр Советы депутаты булып та берничә чакырылышта сайланганын беләм.

Менә шулай кайда гына эшләсә дә хезмәтеннән тәм табып эшләгән кызның шәхси тормышы да, Аллага шөкер, матур булды. Чувашстанның Шыгырдан авылында туып үскән, армиядә хезмәт итеп, офицер дәрәҗәсендә отставкага чыккан Рәхимулла Камалов белән 20 ел бергә гомер иттеләр алар. Савиново бистәсендә үз йортлары, матур гына бакчалары, мунчалары бар иде. Аш-суга оста, өе гел чиста итеп җыештырылган, кунакчыл хуҗаларда кунаклар еш була иде. Иренең туганнары да гел ярдәм, сыену табып тордылар аларда.

Әмма кайгы-хәсрәт тә урап узмады шул Әлфияне. Флотта хезмәт иткәннән соң, Климовскида эшли башлап гаилә корган, институтның кичке бүлегендә укыган Шәүкәт абыйсы бары 28 яшендә фаҗигале төстә һәлак була. Озак та үтми, бу хәсрәттән авырый башлаган әнисе бөтенләй урын өстендә кала. Болар өстәвенә 33 яшендәге энесе Ринат та яшьләй үлеп китә. Үз хәлен үзе белгәндер инде Әлфия. Өйләренә барган саен авыру әнисенең урын җирләренә карап соклана идем. 10 ел буе кетердәп торган җәймәләр, япмалар булды Шәмсениса апаның яткан җирендә. Әле кашык белән ашатырга да, мунчага күтәреп алып барып юындыруларга да өлгерергә,

ике кечкенә баланы тәрбияләргә кирәк иде авылдашыма. Рәхимулла абый да бик иртә гүр иясе булды шул.

Чыдамлылыкның да бер чиге була. Адәм баласының кайгы-хәсрәтләре эзсез үтми, китереп суга бит. Өч мәртәбә инсульт кичерде Әлфия. Аллага шөкер, җиңде, аякка басты, улы Марат белән кызы Гүзәлне дә юньле кешеләр итеп тәрбияләде, югары белем алырга да мөмкинлекләр тудырды. Марат хәзер полковник, Гүзәл – бухгалтер булып тырышып хезмәт итәләр. Алар өчен күңеле тыныч ананың. Әлфия оныкларын үстерергә, аларга тәрбия күрсәтергә дә үзендә көч тапты. Мәктәпкә ашатып-эчертеп озатты, кайтуларын көтеп алды. Шуңа да балаларының да, оныкларының да хөрмәтен тоеп яши, Аллага шөкер.

Рәхмәт сиңа, авылдашым, дустым Әлфия. Әтиеңнең якты истәлеген хөрмәт итеп, аңа, әниеңә, туганнарыңа догада булып яшәвең өчен. Ходаебыз мәрхәмәтеннән аермасын иде әле безне.

## УТ ЭЧЕНДӘ ТАТАР КЫЗЛАРЫ…

*Түземлекләр җиткәч чигенә,*
*Сынау килгәч туган иленә,*
*Килеп басты Татар хатыны*
*Көрәш сызыгының чигенә,*
*Шәл яулыгын салып иңенә.*
*…Халык диңгезенең төбеннән,*
*Берәмтекләп, сөеп җыелган*
*Сөембикәләре милләтнең*
*Кан-көрәштә күпме җуелган…*
*Исемнәре җырга уелган.*

*Лена Шагыйрьҗан*

Без – сугыш чоры балалары. Ил өстенә ишелеп төшкән олы кайгы, миллионнарның гомерен кискән, аналарны һәм балаларны ятим иткән сугыш, гомер буе безнең белән янәшә бара. Аннан котыла да алмадык, алмабыз да төсле. Гомер үтеп бара инде.

Бала чактан караган кинофильмнар, укыган китапларның күбесе руслар күрсәткән батырлык, тиңдәшсез каһарманнар да рус батырлары, рус кызлары иде. Мәктәптә укыганда "Мин кемгә охшарга телим" дигән темага сочинение язарга булса, без билгеле инде – Зоя Космодемьянская, Лиза Чайкина, Любовь Щевцова, Ульяна Громовалар хакында яздык. Ул кызларны һич тә гаепләргә җыенмыйм. Аларның батырлыгы күңелгә кергән, матур булып урнашкан. Ә менә хатын-кызның сугыш кырында хәле ничек, нинди җайсыз, авыр хәлләрдән алар ничек чыга? Ничек ияләнә, ниләр кичерә, ничек чыдый ул? Боларын уйлый белмәгәнбез икән әле. Кулыма чорыбызның күренекле язучысы, Нобель премиясе лауреаты Светлана Алексиевичның "У войны не женское лицо" (китап исеме шулай хәтеремдә калган) дигән әсәре төште. Бу китап миңа сугышта катнашкан кызларның бөтен фаҗигасен аңлатып бирде дә инде. Ирләргә сугышта бер читен булса, хатын-кызга мең тапкыр читенрәк икәнен белү, аңлау – бөтен дөньямны әйләндереп ташлады.

Мин үзебезнең татар кызларының хәлләре тагын да аянычрак булганын, аларның фаҗигаларын, кичерешләрен аңлап тетрәндем.

Күңел әрни: безнең буын Совет хакимияте чорында үзенең газиз халкы, туган-үскән җиренең тарихы, милләтнең чишмә башы, асылы, тамырлары турында белми үсте. Үз ата-бабаларыбыз, чын Ватаныбыз, үз милләтпәрвәрләребез хакында да белмәдек без. Безнең башлар борынгы, урта гасырлар, яңа һәм иң яңа тарихлар белән тутырылды. Тарихыбызны белсәк, бүгенге наданлык та, үз халкыңа, аның үткәне һәм бүгенгесенә битарафлык та булмас иде.

Сүзем ут эчендәге татар кызлары хакында иде бит әле. Сугыш утын кичкәннәрне искә алу иде максатым.

Үз Ватаннарында үги булып яшәсәләр дә, шул илгә афәт килгәндә хаклык, язмышлар белән исәпләшмәгән кызларыбыз. Тормышның кайсы гына өлкәсенә карама – анда каһарманлыклары белән балкып торган кызларыбыз күп. Рус әдипләре, тарихчылары татар кызларының сугыш вакытында күрсәткән батырлыкларын, хезмәткә намус эше итеп карауларын, һәр эшне көчләрен, хәтта тормышларын кызганмый башкаруларын күрмәмешкә салыштылар. Йөрәгемне әрнеткән нәрсәләр күп…

Сугышның иң хәтәр көннәрендә Мәскәү белән Ленинград шәһәрләре күкләрен саклаучы зенитчы кызларның күбесе татар кызлары булуы хакында ник онытылды? Белергә теләүчеләргә “Сөембикә” журналының 2020 елгы 5 нче санын укырга киңәш итәм. “Татарочкалардан үрнәк алыгыз” исемле мәкаләдә зенитчы кыз хакында Раилә Хәялиева язган иде.

Дөрес, мәкаләдә язылганнар гына түгел, зенитчы кызларыбыз күп булган, кайберләренең исемнәрен тагын искә алыйк. Мәрхүм булсалар, рухлары шатлансын, могҗиза белән исән калсалар, үзләре шатлыктан еласын. Кайгырсак та, шатлансак та елыйбыз бит. Болар: Наилә Әхмәтҗанова, Мәрьям Кадыйрова, Фәнихә Юсыпова, Заһидә Вафина, Мөнәвәрә Насыйбуллина, Зәйтүнә Хәлиуллина, Сәйдә Мостафина, Лена Шәмсетдинова, Зөлфия Нурлыгаянова, Бикә Хәйруллина, Суфия Исхакова һәм тагын бик күпләр. Исемнәрен тәсбих тарткан кебек кабат-кабат әйтеп рәхмәт белдерик.

Ничек шулай үзләрен башка милләт кызларына үрнәк итеп куя алдылар икән. Бер зенитчы кызларга гына да әйтелгән сүз, бирелгән

бәһа түгел әле бу кыйммәтле бәя. Сугыш елларында күпме кызларыбыз торф чыгаруда эшләделәр. Торф чыгару ул вакытта, чын мәгънәсендә, икенче фронтка әйләнә, чөнки торф сугыш кораллары ясый торган заводларны, электр станцияләрен эшләтүгә, торак йортларны җылытуга китә. Эш шартларының ничек авыр булганын хәзер аңлатуы да кыен.

Безнең кызларның торфны Мәскәү, Вологда, Иваново өлкәләреннән алып ерак Себер җирләрендә дә чыгарганы мәгълүм. Бер генә мисал китереп үтим, чөнки язмам бик озынга китә. Арча районының Иске Иябаш авылыннан Хәкимова Рәйсә белән Фазыйлова Кәримәләр өч ел буе Түбән Тагил урманнарында торф чыгаруда эшләгәннәр. “Сездән башка татар кызлары тагын бер идеме? – дип сорагач, “И, сеңлем, нишләп булмасын, элегрәк хатлар да алышкан идек, хәзер исемнәре онытылган инде, гаепләмә”, – диделәр. Гаепләмәдем, әмма бер нәрсәгә әле дә җавап таба алмыйм. Тагил өлкәсендә торф чыгарырлык бүтән милләт кызлары булмады микәнни?

Владимир, Калинин өлкәләрендә озак еллар торф чыгарган авылдашым Хәҗирә апа Төхфәтуллина болай дип сөйләде:

– Бервакыт без торган бистәгә күрше колхоз рәисе килде. Колхозның исеме хәтеремдә калмаган, Калинин өлкәсе иде. Шул рәис (үзе чулак, фронттан кайткан булса кирәк): “Кызлар, сезнең тырышлыкны белеп, зинһарлап килдем. Быел уңыш яхшы, безгә ял көннәрендә урак урырга килмәссез микән, игеннәр әрәм була бит”, – дип чакыра безне.

Киттек шул авылга. Безнең Әтнә районы кызлары инде: Бәрәскә, Бәрәзә, ике Шимбердән. Торф нормасын тутырабыз да, шимбә, якшәмбе көн урак урабыз. Рәис куанычыннан еламый гына. Әле эшләгән өчен ит, май, он бирделәр. Рәхәтләндек туйганчы ашап, ике-өч ел булыштык үзләренә.

– Ул авылның үз кешеләре, үз колхозчылары кайда иде? – дип сорыйм Хәҗирә ападан.

– Үз кешеләре дә бар инде. Тик безнең хәтле эшли алмыйлар ич алар, – ди ул, бер дә исе китмичә генә. – Үзләренең яшелчә бакчаларында казыналар. Безне генә көне-төне колхоз эшенә йөртәләр иде, сеңлем.

Искитәрлек хәл. Халкымның иң гүзәл, иң матур сыйфаты – эш сөючәнлеге үзенә үк дошман булып кайта икән ләбаса. Ул, татар халкының фаҗигасе дисәм дә ялгышмам төсле. Кайда авыр хезмәт – шунда татар, шунда татар кызлары. Торф чыгарганда кызларның гарипләнүе, хәтта үлеп калулары да мәгълүм бит. Бу хакта безгә “Торфчы Мөнәвәрә”, “Мәгъдәнә” бәетләре сөйли.

Әйе, авырлыклар килсә, татар кызларының зур намус ияләре икәнлекләрен дә, нинди гүзәл сыйфатларга ия булуларын да белүчеләр була. Сугышның иң хәтәр көннәрендә шушы торф чыгаруда эшләгән хатын-кызлар өчен татар телендә “Правда” исемле махсус газета чыгып килүе очраклы хәл түгел. Бу газетаны татар журналисткасы Мәрьям Дибаева берүзе чыгара. Мәскәү өлкәсендәге торфчы кызлар янына ул, 1944 елда ире Самат Дибаевның фронтта һәлак булган хәбәрен алып, кечкенә кызын әнисе тәрбиясендә калдырып китә.

Берүзе материал җыеп мәкаләләр язган, Мәскәүгә килеп типографиягә тапшырган, берүзе бөтен тиражны күтәреп кайтып торфчы кызларга өләшеп тә йөргән бит ул. Аның истәлекләрен “Ил язмышын салып иңнәренә” дигән китабыма керткән идем[1].

Тагын бераз читкә киттем. Әмма, укучылар мине аңларлар, чөнки фронт белән тылдагы батырлыкны аерып куя алмыйм мин. Кайда җиңелрәк булды дигән сорауга дөрес җавап табып булмый.

Җавап таба алмаган сораулар бар әле ул. Күңелемдә халкымның шушы мактаулы, эш сөюче, намуслы кызлары алдында оялу микән, кызгану микән – бер хис саклана. Ни өчен аларны бөтен СССР буйлап авыр хезмәттә тилмерттеләр икән? Милли сәясәтнең ачык чагылышы бит бу. Татарстанның бөтен шәһәрләрен, авылларын эвакуация белән килгәннәр тутырган. Ә Татарстан кызларын, товар вагоннарына төяп читкә, эшкә озатканнар. Авыр эштән, ачлыктан үлеп калганнар күп, әмма хисабын бүген кем белә? Совет власте елларында Дәүләт Оборона комитеты фронт өчен дип эшләткәч, нигә аларга льготалар, пособиеләр бирелмәде икән. Кем белә дөрес җавабын? Кем курыкмыйча әйтә ала?

[1] Биктимирова Т.Ә. Ил язмышын салып иңнәренә. Казан: Алма-Лит, 2006. 190–191 б.

Тагын фронтка әйләник әле. Безнең горурлыгыбыз, курку белмәс очучы Мәгубә апа Сыртланова телевизорда тапшыру вакытларында искә алынды. Рәхмәт. Ул гади очучыдан эскадрилья полкының командир ярдәмчесе дәрәҗәсенә ирешкән татар кызы. Бу полк хакында беләләрдер дип уйлыйм. Яшьлегебездә без соклана, батырлыклары белән чиксез горурлана идек. Мәгубә апа, ялгышмасам, 1971 елда бакыйлыкка күчте дип беләм. Саубуллашырга бардым, җәсәде Казанның Офицерлар йорты залына куелган иде. Педагогия институтында эшләгән укытучыбыз Зөһрә апа Вәлиуллина миңа: “Мөселманча куябыз җир куенына, Аллага шөкер рөхсәт бирделәр”, – дип әйтеп, сөенече белән уртаклашты. Урыны җәннәттә булсын.



*Мәгубә Сыртланова*

Әмма никтер икенче очучы героебыз Ольга Санфирова искә алынмады кебек. Бергә булалар бит алар. Күренекле язучыбыз Шамил Рәкыйповның “Кызлар – йолдызлар” дигән китабында алар хакында язылган.

Бар һәм бик күп горурланырлык татар кызлары. Фронтка үз теләге белән киткән атаклы снайпер кызлар – Зәйтүнә Габделвәлиева, Әлфия Рәхмәтуллиналарны онытып буламы? Шәфкать туташларыннан снайперлар командасы төзегән Бөгелмә кызы Гөлсем Шакирҗанованы рәхмәт хисләре белән искә алыйк. 60 тан артык дошманның башына җиткән кыз бу.

Шәфкать туташларыбыз хакында әйткәндә меңнәрчә яраланган сугышчыларны сугыш кырыннан алып чыгып үлемнән коткарган Мөнирә Әхтәмәва, Сафура Подвигина, Суфия Хәйретдинова, Зәйтүнә Бариеваларны; медицина пунктларында һәм госпитальләрдә яралыларга күпме каннарын биреп, тормышларын саклап калган Мәрьям Гимаева, Рая Ибраһимова, Роза Зарипова, Зәйнәп Гый-

лаҗетдинова һәм иң беренчеләрдән булып “Батырлык өчен” медале алган шәфкать туташы Асия Ильматованы хөрмәт белән искә алыйк.

Аеруча горурлык белəм үземнең якташым Әтнә районы Түбән Көек авылы кызы – шәфкать туташы Нажия Шакированың исемен атап үтәм. Һәм аның янына авылдашым Фәрзәнә апа Хисамиеваны, Түбән Көек кызлары Хәлиуллина Майшәрәп белән Шәмсеруй Фазылҗановаларны куям. Авыл кызлары, ә нинди батырлыклар күрсәткәннәр!

Нинди авыр шартларда операцияләр ясап, терелтеп, сугышчыларны яңадан армиягә яраклы итеп сәламәтләндергән хәрби табибәләрдән Вәсимә Сәйфуллина, Фатыйма Хәбибуллина, Мөнәвәрә Шәрифҗанова, Әминә Хәмзина, Рәисә Булатова, Оркыя Насыйрова һәм башкаларга олы рәхмәтебез булсын.

Халыкара Кызыл Хач җәмгыятенең иң югары бүләге – Флоренс Найтингел алтын медаленә лаек булганнар арасында татар кызы Фаина Чанышева бар. Белеп торсыннар.

Татар кызлары елга фронтларында да тырышып хезмәт иттеләр. Яралыларны, гаскәрләргә кирәкле азык-төлек, сугыш коралларын ташыйлар алар. Араларында пароход штурманнары Фәйрүзә Галиева һәм Оркыя Курмаева да бар. Оркыяның әнисе һәм өч сеңлесе Харьков шәһәрендә дошманнар кулында калгач, ул үч алу теләге белән, хәрби очучылар мәктәбенә китә һәм фронтта һәлак була.

Язганнарым күп төсле, әмма язасыларым тагын да күбрәк икән. Тик һәрнәрсәнең чиге була. Шулай да Көнбатыш фронтның махсус партизан оешмасы штабында хезмәт иткән Чистай кызы Чәчкә Заһированы (руслар исемен Рита дип йөртәләр), дошман басып алган Днепропетровск шәһәрендә подпольеда көрәшеп һәлак булган Фатыйма Гафурованы, һәм быел интернетта мактаулы исеме чыккан тиңдәшсез разведкачы Фәридә Салимҗановаларны искә алмый китеп булмый икән. Үзләренең курку белмәс батырлыклары, оста сугышчылар булып ирләрне дә сокландырган пулеметчы кызларыбыз – Суфия Гыймаева, Маһирә Мөхәммәтшина, Нина Ризатдинова, Әминә Хафизовалар да һәйкәлләр куярга лаек затлар.

Тылдагылар хакында сөйлиләр язалар да, Алла бирсә тагын язарлар дип өметләнәм. Бары кайбер саннарны гына искә төшерәм.

Авыл хуҗалыгында төп көчләр хатын-кызлар (1944 елда 76,8%) һәм яшүсмерләр булды. МТСта эшләүче механизаторлар арасында 55%ны хатын-кызлар тәшкил итте. Комбаенчыларның 62, тракторчыларның 81 проценты хатын-кызлар иде. Татар кызларыннан тракторчылар Х.Сираҗиева, Б.Гыйззәтуллиналар (кызганыч, исемнәре язылмаган) "Советлар Союзының иң яхшы тракторчысы" дигән исемгә лаек булдылар.

Исемнәре язылмаган, бер карашка әлләни батырлык дип тә саналмаган бер төркем хатын-кызларыбызны әйтеп китәм. Аларның намуслы хезмәтләрен искә алып, исемнәрен табарга югарыда искә алган якташым Нажия апа Шакирова сораган иде. Архивлардан эзләдем, таба алмадым. Бу исемсез каһарманнарыбыз – кер юучы хатын-кызлар. "Сталинград янында күпме хатын-кыз яралы сугышчыларның керләрен юа, үтүкли иде", – дип үтенде Нажия апа. Бик кызганыч, кайсы районнан җибәрелгәннәрен дә ачыклап булмады. Әмма бу изге эштә, 1942 елда гына да, Татарстаннан 84 мең (!) хатын-кыз катнашкан икән.

Бу саннар артында да кеше язмышлары. Берсе генә хакында да ник язылмады икән?

Сугыш еллары янәшә бара. Ил-көнебез тыныч булсын, бу газаплар бүтән кабатланмасын иде. Ә бу җәһәннәмне үткән кызларга багышланган фильмнар "Мөселман киносын"да гына булса да күрсәтелсен иде.

## ХӘТЕРЛӘҮЧЕЛӘР

## МАРИ УРМАННАРЫ ГЫНА ТҮГЕЛ…

Гаҗәп хәл. Еллар үткән саен хәтер савыты саега икән. Әмма балачакта һәм яшьлектә булып узган вакыйгалар кеше күңелендә мәңге онытылмый, “сүнми дә, сүрелми дә” икән.

2013 елда IX Казан халыкара мөселман киносы фестивале кысаларында “Родина” кинотеатрында күрсәтелгән “Хайтарма” фильмын карагач, күңелемдә Кырым татарларының олы фаҗигасенә кагылышлы истәлекләрем яңарды.

1944 елның көзе. Октябрь айлары булса кирәк, олылар бәрәңге алган вакыт (сугыш елларында бәрәңгене кырда ураклар беткәч кенә алалар иде). Миңа 4 яшь (1940 елның октябрендә туганмын), апама – 7. Өйдә көндезге чәйне эчеп утырабыз. Шул вакытта безгә ике яшүсмер һәм минем яшьләрдәге бер кыз бала килеп керде. Бу баланың өстендә юка гына күлмәк, башында да, аякларында да киеме юк иде кебек. Ул бик туңган, үзе нечкә, ябык, бик кызганыч хәлдә иде. Яшүсмерләр үзләренең татар икәнлеген әйтте. Әни аларның Кырым татарлары булуын аңлады, ахры, кабатлап соравы хәтеремдә калган. Ә мин теге кыз баладан күземне ала алмыйм, ул үзе әкрен генә дерелди, күзләре тәлинкәдә калган бәрәңгеләрдә иде мескенкәемнең.

Хәзер ышанып та булмас, әмма минем бәләкәй йөрәгем аны кызганудан әллә нишләде. Мин елый башладым. Әнидән минем өстемдәге кофтаны шул кызга бирүен үтендем. Бу хәлне мин хәзер дә аңлатып бетерә алмыйм: мин ничек ул баланың фаҗигасен аңлый алдым икән?! Бәлки, акыл керә башлавы булгандыр, дип тә уйлыйм. Әнигә рәхмәт, ул минем өстемдәге шул кофтаны салдырды да кызчыкка киертте. Калган бәрәңгеләрне дә аларга ашатты. Өйдә ипи юк та юк инде, бар ризыгыбыз шул бәрәңге дә, сөт. Әни аларның барысына да сөт эчерде.

Менә ничә еллар үтте, ә күз алдымда минем өстән төшкән, юка гына кара җептән бәйләгән кофтаны киеп, елмаерга тырышкан шул 4–5 яшьлек кыз бала басып тора.

Әйтеп үтим, сугыш вакытында да, сугыш туктагач та авыл бик ярлы яшәде. Өстебезгә кияргә кием булмады. Ивановода яшәүче туганыбыз, безне кызганып, кайчак үз балаларыннан калган киемнәрне җибәргәли иде. Кофта да шулай насыйп булган иде миңа. Өстемә кияргә бүтән җылы киемем булмаса да, ничектер яхшылык эшләгәнемне аңлапмы, мин бик канәгать идем. Тик исән кала алды микән ул бала?

Тагын бер вакыйга исемдә. Әниләр амбар алдында сушилкада эшли. Без, балалар, алар янына барабыз, каравылчы кумаса, нәрсә эләксә, шуны ашап, чемченеп йөрибез.

Шулай бер көнне амбар алдындагы чирәмгә бер кыз бала килеп егылды. Янына әниләр йөгереп барды. Ничә яшьләр булды икән аңа, бер 13–14 тирәсе микән? Бүгенгедәй хәтерлим, башыннан аягына кадәр соры, канатлы бетләр сарган иде аны. Сүзен әйтерлек хәле булмагандыр, ул бик кызганыч итеп ыңгыраша гына иде. Әни тиз генә өйгә кайтып, сөт, киярдәй бер күлмәк алып килде. Олылар безне “Бете иярә”, дип куып торды. Кызның авызын ачып сөт йоттыра башладылар. Сарык йоны ала торган кайчы белән озын чәчләрен кыркып алдылар. Өстендәге сәләмәсен кисеп ташлап, әни алып килгән күлмәкне кидерделәр.

Күзен ачкач, аның Кырым татар кызы икәнен белделәр. Исемен әллә үзе әйттеме, Мәллимә дип йөрделәр. Соңрак ул Галия апаларда яшәде, бергәләп чыпта сукты, авыл кешеләренә ияләште. Туганнарын эзләде микән, белмим. Әмма шулкадәр ачык йөзле, һәр сүзгә ышанучан, барысын да үз итә торган кыз иде ул. Әнә шул ышанучан булгангадыр, еллар үткәч, кияүгә чыкмыйча гына бер кыз бала да тапты. Бәлки, бәхетенә булгандыр.

Берничә елдан Мәллимә хәзерге Биектау (элекке Дөбъяз) районы, Өлә авылына күчеп тора башлаган. Шулай бер елны безгә 12–13 яшьләр чамасы булгандыр, Сабан туена барганда аның өен эзләп табып, хәл белергә кердек. Әйткәнемчә, бик якын итә, үз күрә иде ул безне.

Өенә кергәч, андагы чисталыкка, матурлыкка исебез китте. Өй эче бәйләгән челтәрләр, чиккән япмалар белән тулы. Киң күңелле Өлә кешеләре сәдака итеп китергәндер, дип уйлыйм ул әйберләрнең күбесен. Мәллимә үзе дә кул эшләренә – чигү, бәйләүләргә бик оста

иде. Ул безне ничек кунак итәргә, кайларга ничек итеп утыртырга белми. Үзе шундый шат, әйтерсең лә көтеп алган кунаклары килгән. Янында чиста, пөхтә, чәчләре матур итеп үрелгән кызы, безгә елмаеп тора.

Йә, Аллам, рәхмәт бу Өлә авылы кешеләренә. Алар ярдәм итмәсә, өйле, тормышлы булып яши алмас иде бу Кырым татары кызы.

Хәзер шуны уйлыйм: эзләмәде микән, тапмады микән үз туганнарын Мәллимә? Үзе исән түгелдер инде, баласының язмышы ничек булды икән? Өләдә гәзит укучылар булса, язып җибәрсеннәр иде белгәннәрен. Ничек кенә булмасын, халыкларыбызның уртак фаҗигасе дә, үзара ярдәмләшүе хакында да сөйли әлеге фактлар.

Еллар үткәч, педагогика институтында укыганда, бу хакта укытучыбыз Мәдинә апа Җәләлиевага сөйләгән идем. Аның да Кырым татарлары язмышы белән бәйле истәлекләре бар булып чыкты. Ул болай дип сөйләде: “Студент еллары сугыш вакытына туры килде. Без күргән җәфаларны сөйләсәң – тел, язсаң – кәгазь чыдамас. Югары уку йортларында укучы кызларны урман кисәргә җибәрәләр иде. Мари урманында мин дә урман кистем. Башта агачларны кисәбез дә, 2–2,5 метрлы итеп турыйбыз. Шуннан соң тачкаларга салып, елга буена чыгарабыз. Өс-баш начар, үзегез беләсез, ашарга җитми. Әле дә хәтеремдә: октябрь-ноябрь айлары, коточкыч салкын. Без чыгарган агачларны, бозлы суга яртылаш кереп, кырымтатар кызлары салга төйи, туңса да, чыгып йөгерә алмый ярда милиционерлар тора. Йә Алла, ул кызларның исән калганнары булды микән? Мари урманнарының теле булса, бу хәлләрне гомер буе буыннардан-буыннарга сөйләр иде”.

Хәзерге яшьләргә Русия сәясәтенең мондый якларын белгертмәскә тырышалар. Фильмны фестиваль конкурсына кертмәүләрен дә башлыча шуның белән аңлатырга кирәктер.

Ни кызганыч, Совет хакимияте елларында Кырым татарларына карата алып барылган мәкерле һәм аяусызсыз сәясәтне белдермәскә тырыштылар. Ил тарихында Кырым татарлары дигән милләт искә алынмый иде диярлек, аның кайда һәм ничек көн күрүе хакында бик иркенләп, ачыктан-ачык сөйләшү дә булмады. 1944 елда Кырым татар автономияле республикасы халкының – татарларның ике

сәгать эчендә эшелоннарга төялеп, Урта Азиянең комлы далалары-на, Ерак Себергә һәм Мари урманнарына илтеп ташлануын, юлда барганда меңнәрчә балаларның, хатын-кызларның, картларның (ко-рал тота алган ирләр фронтта, гитлерчыларга каршы сугышта) ач-лыктан, авырулардан кырылганын бик күпләр белмәде. Кайчандыр Кырым ярымутравында татарларның олы һәм бөек дәүләте булганы да искә алынмады. Аллага шөкер, тарихта кайчак дөреслек тә, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр дә калкып чыга. Кырым халкы белән дә шулай булды.

Хәтер, хәтер… Яхшылыкны да, яманлыкны да онытмый. Кыз балаларның тилмерүләре дә Мари урманнары хәтерендә генә кал-мас әле. Киләчәк буыннар да уйларга өйрәнерләр, онытмаслар, туганлык, дуслык мөнәсәбәтләрен саклауны да үз кулларына ала белерләр дип өметләнәсе килә.

# ОЛЫ ИХТИРАМ ИЯСЕ УКЫТУЧЫ ЗӘКИЯ АПА

Мин 1990 нчы еллар башыннан үзебезнең “Татарстан” радиосында чыгышлар ясый башладым. Аның башлангыч сәбәбе шунда: Бөтендөнья татар Конгрессында эшкә күчкән идем (чөнки КАИда КПСС тарихы укыту туктатылды). Шулкадәр күтәренке рухлы еллар иде бу үзгәреш еллары. Татар халкы яшәгән өлкәләрдә иҗтимагый үзәкләр эшли башлады һәм һәр өлкә диярлек татар телендә үз газеталарын да чыгара башлады. Бу барыбыз өчен дә күңелле хәл иде. Мин шул газеталарга радиодан күзәтүләр оештыра башладым. Конгресска бу эшне хуплап рәхмәт хатлары ява башлады. Әйе, чын мәгънәсендә ява иде бу хатлар.

Күбрәк үзем сокланган хатын-кызлар хакындагы чыгышларым бик нәтиҗәле булды. Минем белән очрашырга теләүче ханымнар да күбәйде. Мөмкин булган хәтле очрашырга тырыштым.



*Укытучы Зәкия Сабитова*

Үзем бик хөрмәт итеп, аралашып яшәгән Нәфыйга апа да шулай укытучы Зәкия апа Сабитова белән күрешүемне сорады: “Яз әле укытучы Зәкия хакында, тормышы бик гыйбрәтле бит”, – диде.

Ни кызганыч, Зәкия апа белән очрашуга өметләнеп барганда ул авырый иде инде. Күрештек, әмма сөйләшә алмадык. Күңелемдә бу үкенечне басарга уңай хәл чыкты – Зәкия ханымның хатлары матбугатта басылды. Үземне шулкадәр тәэсирләндергән хатларын укучыларга да тәкъдим итәм.

Бераз гына биографиясеннән өзекләр китереп китү дә артык булмас кебек.

Сабитова Зәкиябану Фәйзрахман кызы 1919 елның 3 мартында Әтнә районы Олы Бәрәзә авылында туа. 4 еллык мәктәпне авылда,

7 еллыкны Күлле Кимедә тәмамлый. 1936 елдан Олы Бәрәзә мәктәбендә укыта башлый. Читтән торып Казан педучилищесын тәмамлый. Шул елны укытучы Кадыйров Шәфикъка кияүгә чыга. Ирен 1940 елны хәрби хезмәткә алалар һәм ул 1941 елны ук хәбәрсез югала. Зәкия өч бала һәм кайнана белән тол кала.

Сугыш вакытында директор, соңыннан завуч була, югары классларда география фәнен укыта. Соңыннан башлангыч классларда белем бирә. 1974 елны 40 ел стаж белән пенсиягә чыга. 1953 елны партия сафына керә. Күпсанлы медальләре бар.

Сугышка кадәр спектакльләрдә катнаша. "Галиябану"да Галиябану ролен башкара. Мәкаль-әйтемнәрне күп белә. "Әнием әйтмешли" исеме белән алар И.Кадыйровның "Казан арты – Әтнә яклары. Олы Бәрәзәм" китабына да кертелгән.

2004 елны вафат.

## *Соңгы хат. Әтиегезгә*

*Татарстанның Әтнә районы Олы Бәрәзә авылында яшәгән, егерме ике яшендә өч бала һәм кайнана белән тол калып, кырык ел мәктәптә укыткан әнием – Сабитова Зәкия Фәйзрахман кызының (1919–2004) сугышта хәбәрсез югалган сөекле ире Кадыйров Шәфикъ Лотфулла улына (1911–1941) язган хатлары.*

Әтисе!

Син Армиядә хезмәт иткән чакта "Миңа хатны ешрак яз, аз язасың", – дия идең. Сугыш башланып, синнән хат килми башлагач, мин хатларны бик еш яза башладым. Ләкин алар кәгазьгә түгел, күңелдә генә язылдылар. Менә инде бу хатым соңгысы булыр, ахры. Хәзер миңа 70 яшь тула. Күп гомерем калмагандыр. Адәм баласына Ходай гомерне күп итеп бирмәгән, аның чиге булырга тиеш.

Мин хатларыңны бик сирәк укыйм. Болай итүемә рәнҗемә. Аларны укуы бик авыр, паралич-фәлән булмагае дип куркам. Укымасам да, алар гел күңелдә.

Син киткәч тормышыбыз бик авыр булды. (Хәер, бер безнеке генә түгел, бөтен кешенеке авыр булды.) Хезмәт хакы – 270 сум. Хәзерге акча белән 27 сум ул. Шуның белән 5 кешедән торган гаиләне алып барырга кирәк. Шуннан әз-мәз сиңа да җибәрә идек.

(Тәмәкегә дә кирәк бит.) Ашарга ипи биреп тордылар, карточкага булса да ярады. Әтиләр бик ярдәм иттеләр, алар булмаса, икеләтә авыр булыр иде. Әмма ягу үзәккә үтте. Саздан чыбык, камыш ташыдык. Дәрестән соң Мәймүнә апай белән чана тартып төшеп китәбез, әзерләп, төяп алып менеп ягабыз. Утын юк.

Аннары, җәй көне урманнан ботак ташыдык, кечкенә арба белән. Син аны беләсең инде, Өркәнне төшеп җиткәнче, уң якта "Двадцатый" дигән участок бар бит анда. Шуннан нарат ботагы ташыдык. Иң элек беребезнекен, аннары икенчебезнекен менгерәбез (гел Мәймүнә апай белән). Аныкына карыйм да, минеке әзрәк дип, тагы өстим. Шулай итеп, ул бик авыр була иде.

Өлә үрен төшкәндә арбаны тотып кына төшәбез. Әммә Өркән үре белән Майлыкара үре бик авыр була иде. Кайвакыт Өркән үрен төшкәндә – утырып төшүе кызык булгандыр инде, аннары, җиләк тә ашыйсылары килгәндер – Люция белән Роберт та баралар иде. Ашыт күпере сугыш вакытында бөтенләй ватылып бетте бит ул. Әнкәй Ашыт буена каршыга төшә. Аңа бауны ыргытабыз да, ул теге яктан арбаны бау белән тарта, без йөздереп чыгабыз (күпер турысы сай иде). Менә шулай итеп җәйләрен утын хәзерләдек.

Сугыш башлану белән отпусклар бетерелде.

Аны язмаганмын икән: син киткән кышны мин укый-яза белмәүчеләрне укыттым бит. 3 чыгарылыш ясадым. Алар промартельгә чыпта сугучылар иде. Моның өчен промартель 870 сум акча түләде (хәзерге белән 87 сум). Дәрестән чыгам да аларны укытырга китәм (хуҗалык өйләрендә укыттык). Шулай бик тырышып эшләгәнгәдер инде, җәйгә миңа ял йортына путевка бирделәр. Казаннан ерак түгел – "Шеланга"га.

Ул елны яз соң килде, бик начар булды. Бардым, әйбәт кенә ял иттем. Кайтканда – юл тулы атлылар. "Сугыш башланды!" – диләр. Кайтып керсәм, авылда гарасат. Шау-шу, җылашу. Кемнәрдер китә (тәгаен белмим).

Менә шулай итеп дәһшәтле көннәр башланды. Көн-төн дими эшлибез. Хатын-кыз, бала-чага гына калды.

"Без чыгып киттек", – дигән хатыңнан башка хатың килмәде. Шуннан соңгы язмышың билгесез.

1941 елның кышы мәңге онытыла торган булмады, һай, әрәм булды алмагачларыбыз.

Безнең бакча авылда беренче булыр иде. Бөтен агачлар өшеп бетте. Коймалар җимерелә башлады. Тормыш чыгырыннан чыкты. Ир-ат кулы тимәсә, рәт-баш бетә бит ул. Хәзер бөтен кайгы – ничек кенә булса да балаларны ачлыктан саклап, исән-сау калу.

Өйне урталай бүлеп, бер ягында гына тордык. Барыбер теге як юешләнде. Алай да булмады, мәктәпкә Мәймүнә апай янына кереп, бергә торып карадык. Без Мәймүнә апай белән килешәбез. Әбинең бер дә торасы килми. Балалар – балалар инде, сугышалар, алар хәзер килешә үзе. Әбинең чыгасы килеп үзәккә үтте. Чыдый алмагач, 8 мартка үз өебезгә кире чыктык. Бергә тору сәбәбе дә – ягу бит. Мәймүнә апай мәктәптән яга. Җәйгә көчкә генә ягу ягын рәтләп чыктык. Коймаларны да ягарга туры килде. Ләкин келәтне саклады. Аннары җәй көне абый белән Гайфулла абый кечкенә өй эшләп бирделәр. Аннары кышларын шул өйдә тордык.

Тормыш читен булса да, әкренләп балалар үсте. Люция 7 не бетергәннән соң Казанга китте. Анда тегүчелек һөнәренә өйрәнде. Роберт хәрби училищега укырга китте. Ул 3 ел укып, эшли башлады. Шуннан соң безнең тормышыбыз алга китте.

Бүлеп тә торгач, безнең өебез оеп кына төште. Роберт ай саен 550–800–1000 сум акча җибәреп торды (хәзерге 50–80–100 сум). Без ике ел эчендә өй салдык. Авыл советыннан агач материалларына делянка бирделәр (Шакир җизни авыл советы председателе булып эшләде. Ул да бик тырышты). Без шуны кисеп ташыдык. 1960 елны өй салдык.

Роберт өйләнеп, Германиягә хезмәт итәргә җибәрделәр. Аннан да бик күп әйбер җибәрде. Хатыны рус кызы, ярый, алай начар булмады. Килен кыз булмас, шикәр тоз булмас, диләр.

Икенче елны иске өй агачлары белән куша-куша мунча эшләдек. Аның җитмәгән агачларын Мәгъсүм абый бирде. Аннары капка, койма эшләттек.

Өй салган елны эш бихисап күп, авыр булды. Роберт кайтты үзе, калган эше дә күп бит. Ярый әле Әминә бик булышты. Бер агачны 10 җиргә күчерәсең бит андый чакта. Шул елны, тиф белән авырып, Казан больницасында яттым. Эш тә бик каты, класста 37 бала,

4 класс, яңа программа кергән ел. Үзәккә үткән ел ул. Җәй көне яңа программа өйрәнү курсында булдым. Кутыр өстенә чуан дигәндәй, мине шулар аяктан екты.

Өй салганда Илгиз армиядә иде. Бу малаеңа өй салу авырлыклары күп эләкмәде. Ләкин хәзер минем төп таянычым булып тора ул.

15 көн, 3 атнадан кайтып тора, нинди эш бар, барын да эшли. Узган җәй мунча юышты. Менә быел өйне бергә юарбыз ди. Гомумән, балалар әйбәт булды.

Роберт ел саен отпускага кайта. Бөтен ватык-китекне төзәтә. Йортны бик төзек тоталар.

Теге салган мунча тузды. Яңа мунча салдык. Аның агачларын Илдус кайтарды. Мунча зур, яңа, Аллага шөкер, игелеген син генә күрмәдең. Малайларың үзебез кук, чабынырга яраталар. Алар кайткач, мунчага еш ягам.

Хәзер өйләрдә паровой бит, күмер ягыла. Күмер мәктәптән бирәләр, утын сатып алабыз.

Менә 3 елны Рәбига апайның Клаpалары утын кайтарды безгә, дәү машина белән. Шундый яхшылык эшләрләр дип кем уйлаган аларны. Аның ире дә бик әйбәт, игелекле кеше булды.

Әнкәй 1955 елны вафат булды. Яңа өйне күрә алмады. Аңа меңмең рәхмәт, авыр чакта балаларны карады, пешереп ашатты. Картлык көнендә аңа авыр булды.

Әнкәй үлгәннән бирле Майсәвәр бездә, бергә торабыз. Ике туган бергә тору авыр икән. Ул көйсезрәк, ялгыз да күңелле түгел. Көйсезне көйләве дә читен. Син кайткан булсаң, алай булмас иде.

Сафи абый кайтмады. Мәймүнә апай гомер буе гарип бала бага. Мин үземне аның белән чагыштырганда бик бәхетле дип саныйм. Син кайткан булсаң, бәхетебез тулы булыр иде.

Хәзер Роберт пенсия ала – 186 сум. Аллага шокер, аның картлык таянычы бар. Люция киләсе елга пенсиягә чыга, Алла теләсә. Илгизгә 50 яшь тула быел. Шулай итеп, балаларыбыз да олыгаялар бит.

Хатларыңның берәзын ягам, беразын калдырдым. Рәнҗеп ятма!

Хуш хәзергә.

1989 ел, 7–8 февраль.

Әтисе!

Калган сүзләрем күп икән әле. Истә чакта языйм. Синең хатларыңны миннән соң укучы да булмас, бәлки. Шулай да, Илгиз укыр әле дип өметләнәм, чөнки ул нечкә күңелле. Ул малаең нәкъ үзең кебек. Төсе, бите, буе, сыны. Әзрәк кызу характерлы, әбигә охшаганрак. Әмма яхшы күңелле. Роберт бик басынкы, ашыгып сөйләшмәс, күп сөйләшмәс, синең кебек уйлап кына сөйләшә.

Әле хатларыңны укып чыккач уйлап утырам. Дөнья бәясе кеше булгансың икән син. Олы җанлы, олы мәхәббәт белән сугарылган кеше. Мин, яшь кеше булып, күп нәрсәләрне бөтен нечкәлекләре белән аңлап та бетермәгән икәнмен. Менә тора-тора тирәнрәк аңлыйм. Син кайткан булсаң, без бөтен кешегә үрнәк булырлык итеп яши алыр идек бит. Шундый авыр, юк елларда да сыкранмадык бит без. Өйне элекке урыныннан күчереп салган елны шулхәтле авыр булды, хәтта аягыбызга чүәк та алып кия алмадык бит. Җәйге отпусканы колхозда эшләп үткәрдек. Саман кирпече суктык (тирестән), колхоз шуның белән терлек абзарларын төзеде. Син ындыр бригадиры булып та эшләдең. Ул вакыттагы гаделлеккә исем китә. Орчыкбаштагы ындырда син бригадир, әнкәй шунда эшли. Борчак сугабыз. Әнкәй балаларга дип 5–6 кузак борчак алган. Син шуны ташлаткансың. Әнкәй кайткач әйтә: “Сезгә дигән борчакны атагыз ташлатты, син алгач башка кеше дә ала”, – дип. Син аерата гадел идең бит. Шулай кирәк иде. Гаделлек гомер буе кирәк нәрсә. Хәзер колхозны талыйлар, һәр кеше эшләгән җиреннән алып кайта.

Хәзер халык бик яхшы яши. Материаль байлык зур, әмма халыкның күңеле ярлы. Акчага, байлыкка табына халык. Рухи ярлылык хөкем сөрә. Аның җиле үз балаларыма да кагыла. Куркам, яхшы тормыш кешене боза бит ул.

Бервакыт синең хатларыңны Люция укыштырды, әзрәк кенә. “Әтинең хатларында бер дә төче теллелек юк икән”, – дип әйтә. Кайда ул безгә кәшәвәрләнеп, төче теллеләнү. Син анда безнең өчен, ничек тамак туйдыралар, нәрсә ягарлар, дип борчылып ятасың. Мин монда, гаиләне ничек әч-ялангач итмичә алып барыйм, дип борчылып ятам. Бишәү бит без. Ничек бара алганбыздыр, хәзер хәйран калам. Яшь булсам да, черкәм булганмын икән.

Аннары, эшебез дә бик читен булды. 40 ел балалар белән эшләү бик зур нәрсә ул. Элек балалар да күп иде. Беренче класслар 4 булганны хәтерлим, һәр класста 30–40 бала. Халык авылны ташлады, яшьләр шәһәргә китәләр, авылда кеше аз.

Сугыш беткәч, отпуск бирелә башлады. Исемен генә белеп яшәдек. Чынында ял итү булмады. Колхозда урып-җыюда, бәрәңге алуда эшкә булышу (физик эш белән), агитация-масса эше – бары да укытучылар өстендә булды. Балаларны күрергә дә вакыт булмый иде. Иртә китәбез, кич кайтабыз. Ул бичаралар үзләре үстеләр инде. Аларны авыр тормыш тәрбияләде.

Шәһәрдә атнага 2 ял көне булса да, авылда мәктәптә ул юк. Бер ял көне. Аны да партия укуына хәзерләнеп үткәрәбез. (Чөнки һәр атнаны дүшәмбе көн – партия укуы).

Хәзер үзгәртеп кору, хәбәрдарлык чоры башлангач кына, ялгышканнарыбызны аңладык. Партия байрагы астына әшәке җаннар кереп оялаган икән. Алар халыкның бөтен җанын, канын, байлыгын суырып ятканнар икән. Ә без – агитаторлар – халыкны алдаганбыз икән.

Мин үзем дә 1948 елдан бирле партия члены. Кеше арасында дәрәҗәм зур булды, Аллага шөкер, олысы-кечесе ихтирам итте, киңәшкә килде.

Шәфикъ!

Гыйльметдин турында язмадым бит әле. Ул бичара, исән булса да, иленә кайта алмады. Алар плен төшеп, бу якка чыкканнан соң судить ителгәннәр. Аны Әрмәнстанга җибәргәннәр. Ул шунда өйләнеп, монда кайтмады. Менә 10 ел чамасы бардыр инде, шунда вафат. Күрше Җәләй абый сугыштан исән-сау кайтты. 1956 елда үлде. Майҗиан апай да вафат.

Син белгән кешеләрдән Вафин Фәйзи абый да үлде. Насих Үзбәкстанда яши. Хәмзә Гарәфләре, Мөхәме дә сугыштан кайтмадылар.

1989 ел, 7–8 февраль

## ОСТАЗЛАРЫМ ХАКЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ…
## (1960 елларда Педагогия институты укытучылары)

Казан дәүләт педагогия институтының тарих, татар теле һәм әдәбияты бүлеген 1966 елда тәмамлап чыккан идек. Гомер юлларыбыз, язмышларыбыз төрле якларга таратса да, Аллага шөкер, исәннәребез бер-беребезне югалтмыйча хәбәрләшеп, очрашкалап яшибез. Алдагы көннәребезгә дә шулай яшәргә язсын. Очрашканда бездән чын педагоглар ясарга тырышкан остазларыбызны рәхмәт хисләре белән, сагынып искә алабыз.

Группабызның яртысы диярлек сугыш ятимнәре иде. Алар унынчы сыйныфтан соң төрле тармакларда эшләргә дә өлгергәннәр, әмма үзләрендә белем алырга теләк бик көчле булгандыр диясем килә, чөнки эшләп килүчеләрнең имтиханнар вакытында белем дәрәҗәләре югарырак бәяләнә иде.

Педагогия институтында ул елларда эшләгән укытучыларның (шул исәптә ректорыбыз Туишев Йосыф Әхмәтҗан улының да) нинди авыр сәяси шартларда эшләгәнен соңрак аңладык. Партиянең XX съезды (1956 ел) уздырылганга нибары биш ел үткән (институтка 1961 елда кердек). Бу уку йортында шәхес культы заманында нинди гарасат узганын хәтерләүчеләрдән курку хисе чыга алмагандыр әле ул чакта. Бер гаепсезгә күпме галимнәр юк ителгән, кулга алу план нигезендә алып барылган, аны тутырыр өчен хәтта студентлар да бу бәлагә дучар ителгәннәр икән. Мисал өчен, күренекле галим, сәясәтче, язучы Сәлах Атнагулов кулга алынганда, ул җитәкләгән группадан тагын 10 студентны да алып киткәннәр икән. Миндә фамилияләре саклана. Менә алар: Садыйков Абдрахман, Муратский Хикмәт, Сәетов Харис, Сөләйманов Әсхәт, Факизуллин Әсхәт, Гыйльми Әхмәт, Хәсәнов Хатыйп, Хәсәнов Ислам, Вәлиуллин (исеме күрсәтелмәгән), Кадыйров Хатыйп. Исәннәрдер дип уйламыйм, урыннары җәннәттә булсын.

1961/1962 нче уку елының беренче сентябрендә беренче лекцияне укып, безне студент тормышына кертеп җибәргән сөекле остазыбыз Лотфи ага (Исмәгыйль улы) Яфаров булды. Әлегә кадәр күркәм кыяфәте, олы җанлылыгы белән күңелебездә йөртәбез үзен.

Дүрт ел буе безгә татар теленең нечкәлекләрен, кагыйдәләрен өйрәтеп кенә калмады ул, тормышыбызның авырлыгын да белә, хәлебезне дә сорашып тора иде.

Уйлап куям, студент матди авырлыкларны яшьлек белән җиңәдер инде. Стипендия барлыгы 22 сум, шуның 1 сум 50 тиене – трамвайга билет алуга, 1 сум 50 тиене – тулай торак өчен түләргә китә. Группада 2–3 кеше стипендия алмый калган очракларда, аларга да өлеш чыгарабыз. Тәнәфестә буфетка чыгып йөгермәсәк, “Балакай, әллә акчаң юкмы, бар буфетка төшеп ашап мен, акча биреп торам”, – диеп яныбызга килә иде Лотфи ага. Алырга ояла идек, алмадык, әмма бөтен группабызны Г.Камал театрына чакыргач бардык. Ялгышмасам, “Бертуган Таһировлар” дигән спектакль иде кебек. Остазыбызның шулай аталарча карашы да ничектер бер җиңеллек бирә, аңа ышанычыбыз да, хөрмәтебез дә арта иде.

Әле дә онытмыйм… 5 нче курста да беренче лекция аныкы булырга тиеш иде. Аудиториягә кереп көтеп утырабыз. Лотфи ага юк. Кемдер кереп: “Лотфи аганы пенсиягә җибәргәннәр бит”, – дип әйтте. Барыбыз да урыннарыбыздан тордык та, хөрмәтле остазыбызның өенә киттек. “Сезнең белән башладык бит студент тормышын, безне озатып та калырсыз дип уйлаган идек”, – дип әйткәч, бик дулкынланды остазыбыз. Бик авыр хәсрәтле вакыты (бердәнбер улының вафатын кичергән көннәре булган). Кайгысы үтә торган кайгы түгел, әмма беразга гына безнең белән сөйләшкәндә җиңеләйгән төсле булгандыр. Безнең килүебезгә шат иде ул. Соңрак без аның өчен концерт хәзерләп, татар теле һәм әдәбияты кабинетына чакырдык, хәлебез җиткәнчә бүләк әзерләп (матур гына авторучка иде), бергәләп чәй эчтек. Мондый озату кичәсе факультетта беренче мәртәбә узган ахры, башка педагогларыбызның да күзләре яшьләнде. Безгә дә игътибарыбыз өчен рәхмәт сүзләре күп булды.

Минем Лотфи аганы соңгы тапкыр күрүем тагын бер сөекле остазыбыз Абдулла ага Сайгановның вафатына баргач булды. Гагарин урамы чатында Абдулла аганың җәсәден өйдән алып чыкканчы озак кына, күп нәрсәләр хакында сөйләшеп тордык. Нәкъ элеккечә, якын кешебез булып исемдә калды. Урыны җәннәттә булсын.

Абдулла Җамалетдин улы Сайганов (1913–1974) әдәбият белеме фәнен укытты. Аның татар, рус әдәбиятын тирән белүенә сок-

лана идек. Пушкинның “Евгений Онегин” поэмасын, Тукай, Такташ шигырьләрен күңелдән укып, әдәбиятның матурлыгын күрә белергә өйрәтә иде. Бөтен кыяфәте, буе-сыны, сөйләме искиткеч матур иде аның. “Чын зыялы кешеләр” дип сөйләшсәк, хәзер дә Абдулла ага күз алдына килә дә баса инде.

Булачак галим Әстерханда туып-үсеп, педагогия институтын тәмамлауга сугышка китә һәм кавалерия гаскәрләренә эләгә. Одесса өчен барган сугышларда каты яралана. Аты өстеннән егылып төшеп, ничә сәгать яткандыр, ис китәрлек хәл, караңгы төшкәч, аны аты сугыш кырына эзләп китә, табып янына килә, әмма яралы сугышчы үзе менеп атлана алмый. Шунда, ул хайванда юньле кеше акыллары булгандыр, ат тезләнеп, ничектер муенына атландыра алган аны һәм үзебезнекеләр ягына алып чыккан! Ни кызганыч, бу хәлне үзеннән ишетмәдек, укытучыларыбыз үзләре хакында бер истәлек тә сөйләмәделәр шул.

Гарәп теле өйрәтергә безгә Зәйнәп апа Максудова чакырылган иде. Ул инде өлкән яшьтә, еш кына авырый, занятиеләр үткәрергә дә сирәк килә. Казанда гарәп, фарсы телләре буенча аңа тиң белгечләр ул вакытта булмаган дип беләм. Хәзер дә үкенәбез, ник безгә шул үзе тәмамлаган Иж-Буби мәдрәсәсе хакында гына да сөйләмәде икән. Сөйләргә ярамады микән? Шулайдыр, курыккандыр дип уйлыйбыз.

Педагогикадан безне Муса Җәлилнең якын кардәше Таһир ага Корбанов укытты. Лекцияләрендә атаклы педагоглар хакында сөйләгәндә гел чит ил, урыс галимнәреннән мисаллар китерә иде. Бервакыт: “Таһир ага, безнең үзебездә шундый тирән фикерле, искә алырлык педагоглар, галимнәр булмаганмы, булса кемнәр алар?” – дип сорадык. “Бар, ник булмасын, бик бар, киләчәктә сезгә аларны белергә язсын”, – диде.

Еллар үтеп, олуг галимебез Ш.Мәрҗани исемен йөрткән Тарих институтында эшләгәндә “Татар педагогик фикер антологиясенең” 1–2 томнарын хәзерләдек. Шунда белдем үз галимнәребезне. Аллага шөкер, Таһир аганың сүзләре “Амин!” дигән сәгатькә туры килгән күрәсен. Биографияләрен, хезмәтләрен өйрәнгәндә шәхес культы елларында юк ителгән бөек затларыбызның фаҗигасен белеп елап җибәргән вакытларым аз булмады. Алар исән булып,

алар белгән гыйлемнәренең, аларның хезмәтләренең диңгездән бер тамчысы гына яшь буыннарга барып ирешкән булса (!), безнең милләт бу кадәр наданлыкка чумар идеме? Күбесе дөньяда тиңнәре булмаган шәхесләр булганнар бит.

КПСС тарихыннан безне Бондаренко Валентина Андреевна (милләте буенча яһүдә) укытты. Никтер безнең группаны бик яратты ул. Әйтеп үтим, бары ул гына барыбызның да исемнәрен белеп, якын итеп эндәшә иде. Экзаменнар беткәч һәрвакыт яныбызга килеп нәтиҗәләре белән кызыксына, үзенең дә кемне дә булса җәберләгәнен хәтерләмим.

Алай гына да түгел, безнең матди хәлебез кыенлыгын белә, җиңеләйтергә дә тырыша иде әле. Шулай, Хрущев заманында сатуда ипи бар кешегә дә җитми башлады. Иртән без киткәндә кибетләргә икмәк килеп җитми, ә занятиеләр беткәч кергәндә, инде елап сорасаң да, бер сынык ипи калмый. Ә Валентина Андреевналарга Украинадан туганнары посылка белән макарон җибәргәннәр. Шул посылка хакында әйтеп, барыбызны да кунакка чакырды ул, 7–8 кеше өйләренә барып ашап кайттык макаронны. Рәхмәтебез рухына дога булып барсын. Икенче курска күчкәндә Академик Губкин урамында тулай торак өлгерде, шунда урнаштык. Яңа өй белән котлап тагын килде укытучыбыз. Бөтен группага җитәрлек итеп пироглар пешереп алып килгән иде. Яхшылыгын онытмадык, барыбыз да сагынып искә алабыз. Хәзер математика буенча фән белгече, ТИСБИ да укыткан кызы Наталья белән каберенә баргач та яхшылыкларын искә төшереп сөйлим. Ул үзе дә, ире Леонтьев Григорий Алексеевич та еш кына төшләремә керәләр (Г.А.Леонтьев белән Казан авиация институтында бер чорда эшләдек, ул философия кафедрасын җитәкләде).

Безнең киләчәк өчен борчылган, яхшы киңәшләр бирергә тырышкан тагын бер остазыбыз хакында әйтми кала алмыйм икән. Ул да булса, Яңа тарих фәненнән лекцияләр укыган Иозеф Геннадьевич Трунский. Лекцияләре тирән эчтәлекле булуы белән кызык иде аның. Программадан тыш та кайбер нәрсәләр хакында әйткәләп куя иде әле. Ә без, татар балаларына әйткән сүзләре хәзер дә онытылмый. “Укыгыз, яхшы китапларны укыгыз, күп белергә тырышыгыз. Сез бары тик тирән белемле, чын һөнәр ияләре була алсагыз гына бу тормышта югалмассыз. Менә минем фәннән кайбер

китапларны киңәш итәм, укысагыз зачет та, экзамен да куям”, – дип кызыктыра иде. (Сез, татарлар, белемле булсагыз гына бирешмәссез, диюе булган икән). Аның киңәше белән укыган китапларымның эшли башлагач та зур файдаларын күрдем. Рәхмәт остазыбызга.

Ни кызганыч, бер мәкаләдә генә остазларыбызның барысын да искә алып бетерү мөмкин түгел. Әмма әдәби мирасыбызны тирәннән өйрәнеп, белеп, лекцияләрендә әдәбиятчы галимнәребез хакында эчке бер җылылык белән сөйләгән ике галимәбез – Җамал апа Вәзиева белән Мәдинә Җәләлиеваларны ничек искә алмаска мөмкин. Аларны онытканыбыз да юк бит. Алар икесе дә искиткеч чибәр булулары өстәвенә матур итеп, зәвык белән киенә дә беләләр иде. Җамал апа әдәбиятны тарихи чор белән бәйләп бик кызыклы сөйли, кайбер истәлекләре белән дә уртаклашып, әдәби геройларны җанлы итеп күз алдына бастыра ала. Татарстандагы котычкыч ачлык (1920–1921) хакында сөйләгәннәре хәтеребездә. Ул үзе Зөһрә апа Баимбетова оештырып Белоруссиягә озатылган ач балалар төркеменә эләгеп үлемнән исән калган булган.

Мәдинә апа группа җитәкчебез иде. Уку елларында үзебезгә игътибары җитте, еш аралаша иде дип әйтә алмыйм. Соңыннан белдек, диссертация язган, якларга әзерләгән еллары булган икән. Әмма үз фәнен, борынгы әдәбиятны белә, җиренә җиткереп, үтемләп сөйли иде. Безнең күпне беләсебез килеп бирелгән сорауларыбыз да, кылган гамәлләребез дә аның өчен борчусыз гына үтмәгәндер дип уйлыйм хәзер.

Шулай бервакыт группабыз белән өлкәннәрдән башка гына Болгарга экскурсия ясадык. Болгарда музей бер кечкенә генә, искерәк йортта урнашкан, экспонатлар бик бай булсалар да, хуҗа кулы, яраткан, кадерләгән оста кулы сизелми иде. (Ул чакта без күргән бай хәзинәләр кемнәр кулында югалгандыр, безгә караңгы. Әмма Болгарның хәзерге музеенда без сокланган экспонатларның берсен дә күрмәдем дип әйтә алам). Кайттык та, Мәдинә апаны тинтерәтәбез: ничек, ник шулай, ник тәртипле түгел? һ.б. Ул сорауларга институтта яңа эшли башлаган яшь укытучы ничек җавап тапсын? Тапкан, белгән очракта безгә дөреслекне ничек сөйләсен?

Свияжскига да бардык. Ялгышмасам, анда булган психик авыруларны да озатып бетермәгәннәр иде бугай. Экскурсовод хатын

(рус хатыны) собор подвалына алып төште. Андагы сөякләргә күрсәтеп: “Менә, чукынырга теләмәгән татарларның сөякләре”, – дип күрсәтте. Әллә ачулы вакытына туры килдекме, белмим, чукынмаган татарларны рәхәтләнеп сүккәне исемдә калган. Тик соборның исеме хәтеремдә юк. Тагын Мәдинә апаны сораулар белән алҗытабыз. Чын тарихыбызны белми идек бит әле ул чакта.

Институтны тәмамлап чыккач, еш очраштым укытучым белән. Авыр туфрагы җиңел булсын. Догаларым рухын шатландырсын иде. Бик үк бәхетле булмаган милләтемнең бик үк бәхетле булмаган, әмма талантлы, гүзәл бер баласы иде ул.

Өстәп шуны әйтәсем килә. Остазларыбызның безне чын педагоглар итеп күрәселәре килүе шиксез иде. Хәзер, еллар үткәч, аларга безнең өчен кызарырга туры килмәс иде дип ышанып әйтә алам. Аллага шөкер, күбебез сайлаган һөнәребезгә тугры булып, хәлебездән килгән кадәр намусыбызга тап төшерми эшләдек.

Рәхмәт остазларыбызга. Безнең хәтеребездә алар да иң матур кешеләр булып калды, без дә шуның өчен тырыштык.



*Казан Педагогия институтының татар теле һәм тарих бүлеге студентлары. 1963 ел*

## СЕЗДӘ ГАЛИМ БУЛСА, БЕЗДӘ ГАЛИМӘ БАР

*Һәр тугрыда ким түгелбез ирләрдән без,*
*Гыйлем алсак, иң галимнәренә тиң без.*
*М.Мозаффария*

Аллаһыма мең-мең рәхмәтләр әйтәм. Гомеремнең 30 елы буенча СССРның атаклы белем йортында – А.Н. Туполев исемендәге Казан авиация институтында укытучы булып эшләргә насыйп булды. Нинди бай тарихы, мактаулы галимнәре белән данлыклы уку йорты бу. Менә шул фән белгечләре арасында йөрәгемдә әлегә кадәр мәңге онытылмас урын алган татар кызы – Мәхфүзә Кәрим кызы Максудова бар. Ул – техник фәннәр докторы (1977), профессор (1978), ТАССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе (1981) һәм КДТУның атказанган профессоры (1997). Турбиналы машиналарның газодинамикасы өлкәсендә эшләүче галимә.

Мәхфүзә Максудова – хаклы рәвештә халкыбызның мактанычы, горурлыгы саналырга тиешле каһарман йөрәкле татар кызы. Авиация институтында эшләгән елларымда аңа карап сокланып туймый идем.



*Галимә Мәхфүзә Максудова*

Бу олы хөрмәтне, сокланулы карашны, зур дәрәҗәле институтның фән өлкәсендә танылган, олы галимнәре тарафыннан да, студентлары тарафыннан да булуын күреп куана идем. Милләттәшем бит, татар кызы бит! Аның хакында язасым, сөенечемне башкалар белән дә уртаклашасым килсә дә, озак вакыт яза алмадым, оялдым. Чөнки техник фәннәр өлкәсе миңа бөтенләй диярлек таныш түгел, ерак, язсам Мәхфүзә Кәримовна талантының кыйммәтен ача алмам кебек тоела иде.

Аның кандидатлык һәи докторлык диссертацияләре турбиналар характе-

ристикасы буенча якланган. Ул шул турбинаның эчендә төрле эш режимнарында барган процессларны өйрәнгән, аларны төзегәндә кирәк булачак төгәл хисаплау формулалары буенча эшләгән. Фәнни хезмәтләре моторларның куатен арттыру, ягулык расходын киметүгә багышланган. Танылган галимнәр Г.Жирицкий (Айдагы кратерларның берсе бу галим исеме белән аталган), В.И.Локай, М.К.Максудова, В.А.Стрункиннар язган "Очу аппаратлары двигательләренең газлы турбиналары" исемле дәреслек буенча бөтен СССР күләмендә ничә буын студентлар укып белем алды. Бу хезмәтләр әле диңгездән бер тамчы гына дияр идем. Башка хезмәтләре хакында Казандагы "СТАР" нәшриятында 2002 елда басылып чыккан "КАИ. Выпускники – гордость университета" исемендәге китаптан тулырак мәгълүмат алырга мөмкин. Мин бары Мәхфүзә ханым җитәкчелегендә 11 кеше кандидатлык диссертациясе яклаганын, ә үзенең моторлар төзү факультеты деканы, институтта чыгып килгән "Труды КАИ" дигән фәнни җыентыкның җаваплы редакторы, берничә тапкыр чакырылыш шәһәр Советы депутаты, институт партия комитеты әгъзасы вазыйфаларын башкаруын искәртеп китәм.

Максудованы якыннан белүчеләр аның фикерләү сәләте көчлелеген, кешеләргә карата да, фән кануннарына карата да җитди, төптән уйланган үз фикере барлыгын әйтми калмыйлар. Фән кешесе, галимә булуы белән бергә әдәбиятны, сәнгатьне теләсә кайсы белгечне сокландырырлык нечкә сиземләвен, театрга багышланган китапларының байлыгы, хәтта режиссерларны да көнләштерерлек икәнен әйтеп китү дә урынлы булыр төсле.

Зәвык белән матур итеп киенә белүен, бакча үстерүенә, квартирасын нәкъ безнең халыкча – татарча чиста пөхтә итеп тотуына да сокланмаган кеше юк иде.

– Син бит безнең кеше, килеп йөр әле миңа, – дия иде очрашкан чакларда. Тик, авыл кызы бит мин, андый минем өчен "буй җитмәслек" зур кешеләргә барырга ояла идем. Соңрак, диссертациямне яклагач аның группадашы, КАИның сызма геометрия кафедрасының өлкән укытучысы Әлфия ханым Халикова бик кыстагач, бергә бардык. Үткән тормышлары хакында сөйләгәндә, моңарчы килми йөргәнемә үкендем үкенүен. Чөнки аның үткәне, балалык еллары истәлекләргә бай, гыйбрәтле булган икән.

Мәхфүзә апа Ленинград шәһәрендә 1921 елның 31 нче октябрендә туган. Әнисе Мөршидә ханым ягыннан бабасы Гыйззәтулла (ул Изатулла дип сөйләде, шулай атыйк) Пенза мишәре, 9 бала атасы булган. Олы балаларын никахлап өйләндергән, кияүгә биргән. Балаларга дөньяви белем дә бирергә тырышкан. Кызы Мөршидә дә (Мәхфүзәнең әнисе) Гатчинода гимназия бетергән. Изатулла үзе шунда ресторан хуҗасы булган. Мал-мөлкәтле, киң күңелле кеше буларак, хәйриячелек буенча да танылган, хөрмәт иясе булып яшәгән. Үз балалары белән бергә ресторраннарында эшләгән официантларның балаларын да башкаланың уку йортларында укыткан икән.

Ә Мәхфүзәнең әнисе ягыннан бабасы Мөхәммәтгалим (үзе Алим дип сөйләде) Петербург татарлары хакында чыккан китапларда ике исеме белән дә искә алына (1857 нче елда туган). Дини һәм дөньяви гыйлемнәрне бертигез хөрмәт иткән, күрәсең. Ислам, Кәрим, Хафиз исемле улларын Истанбулның француз колледжында укыткан. Мәхфүзә исемле кызы Петербургта хатын-кызлар өчен ачылган Югары педагогия курсларында укыган. Башкаларда укыган татар яшьләре арасында сабакташы Сәлимә Якупова белән икесе дә аеруча активлыклары белән аерылып торганнар. Олуг әдибебез Гаяз Исхакый тарафыннан чыгарылган “Ил” газетасында икесенең дә 1914 елда милләтебез язмышына багышлангап язган мәкаләләрен укырга була. Мәхфүзәнең Петербургта 1914 нче елда үткәрелгән мөселманнар съездына карата язылган. “Съезд һәм мөселман хатыны” дигән мәкаләсе беркемне дә игътибарсыз калдырмаган. Ул мәкаләдә съезда хатын-кызлар катнаштырылмавына борчылып, үпкә белдереп язган. “Тормыш”, “Ил” газеталарында, “Сөембикә” журналында аны яклап язган мәкаләләр шактый.

Әмма бу талантлы кыз, ни кызганыч, бик яшьли үлеп киткән. Аның исемен 1921 нче елда Кәримнең кыз баласы тугач, ул балага биргәнннәр. “Апасы кебек уңган, булган, тәүфыйклы булсын” янәсе.

Алим Максудов хакында тагын берничә сүз әйтеп китү урынлы булыр дип саныйм. Инде мәгълүм булганча, башкалада яшәүче татарлар 1881 елда җәмигъ мәчете төзү, аның өчен акча җыю хакында киңәшәләр һәм эшкә дә керешәләр. 1889 елда, менә шул җыелган акчаларны, алар үзенең гадел холкы белән танылган “хөрмәтле

купец” Алим Максудовка ышанып тапшыралар һәм ялгышмыйлар. 1905 елда мәчет төзү буенча С.-Петербург мөселманнарының комитеты да төзелеп, Алим Максудов аның әгъзасы да булган. Моның өстәвенә Алим аганың “Коръән” бастыра торган “Әманат” исемендә типографиясе дә булган һәм шактый күләмдә китаплар да чыгарып таратылган икән.

Менә шундый бай, шөһрәтле, әмма “Алладан куркып, кешеләр алдында оялып” яшәгән Изатулла һәм Алимнең балалары өйләнешеп матур гаилә коралар. Кәрим дә, Мөршидә дә югары белем алган зыялылар, милләтебезгә күпме файда китерә алган булырлар иде. Тик Октябрь революциясе аларның бөтен киләчәгенә киртә сала. Истанбулда Шәрык телләрен өйрәнгән, һәркайсында иркен сөйләшә алган Кәрим баштарак Азчылык милләтләр комиссариатында, Почта идарәсендә эшләп йөрергә мәҗбүр була да, соңрак бөтенләй эшсез кала.

1929 елда Совет власте бөтен учреждениеләрне “чит элементлардан чистарту” кампаниясен башлап җибәрә. Бу чистарту бигрәк тә мәгариф һәм мәдәнияткә, динчеләребезгә кагыла. “Очистим партию от чуждых элементов. Чистка – важнейшая политическая компания!” дигән лозунг Ленинградта гына түгел, Россиянең барлык өлкәләренә таралган була. “Мәскәүдә 500 укымышлы, зыялы татарларыбызны җыеп кына алдылар” дип сөйләде ул хәлләрнең тере шаһите Зөһрә апа Баимбетова. Танылган олуг галимебез Равил Үтәбәй дә Татарстанда һәм Башкортстанда 600 дән артык муллаларыбыз кулга алынып, юкка чыгарылуларын язып чыкты. 1933 елда бик күп “хокуксыз элементлар” белән бергә Мөршидә ханым белән кызы Мәхфүзә дә Ленинградтан сөреләләр. Кәрим абый инде вафат булган (урыны җәннәттә булсын). “Ун көн эчендә бөтен мөлкәтне сатарга, теләсә кая китәргә кушылды”, – дип сөйләде Мәхфүзә ханым. Ул шулай, 4 нче сыйныфта укып йөргән кыз, әнисе белән Казанга күчеп килә. Бәхетләренә Мөршидә апаның сеңлесе Маһинур Финанс институтын тәмамлап, Казанда банк системасында эшкә урнаша алган, торыр урыны да булган була.

1940 елда Мәхфүзә Кәрим кызы, унынчы сыйныфны уңышлы тәмамлап, Казан авиация институтына укырга керә. “Ул елларда авиация белән җенләнмәгән яшьләр булды микән? Шәһәрдә

аэроклублар гөрләп эшли, планерлар ясау, алар өчен очу ярышлары үткәрүләр бик кызыклы иде. Мин моторлар төзү факультетын сайладым. Чөнки мотор ул – самолетның йөрәге. Шундый факультетны сайлаганыма бервакытта да үкенмәдем”, – диде ул.

Беренче курсны тәмамлауга сугыш башлана. Студентларны окоп казырга, урман кисәргә, заводта эшләргә җибәрәләр. Сугышка алмыйлар. “Без берничә кыз сугышка алуларын сорап, гаризалар күтәреп Хәрби комиссариатка бардык. Безне гел кире җибәреп тордылар. Ә егетләрнең кайберләре ничектер китә алдылар үзе. Тик күбесе кире кайта алмадылар шул. Нинди кызу ут эченә кеделәр бит”, – дип искә алды галимә.

1945 елда факультатны 14 кеше тәмамлап чыга. Мәхфүзә Каримовнаны институтта – ракета двигательләре кафедрасында эшләргә калдыралар.

Үз вазыйфаларының зурлыгын тирәнтен аңлаган, хезмәтеннән чын мәгънәсендә рәхәтлек тапкан кеше иде Мәхфүзә Кәрим кызы.

Хезмәттәшләре, студентлары арасында төпле киңәшләре, дустанә мөнәсәбәте белән дә аерылып торды. Берүк вакытта халкыбызның матур гадәтләрен дә олылый, сакларга тырыша иде. “Миңа институттан 12 метрлы бер бүлмә бирделәр дә, Маһинур апаның 20 метрлы бүлмәсе белән бергә кушып алыштыра алдык. Гоголь урамындагы йорттан квартира безгә шулай эләкте. Бервакыт йорт идарәсеннән: “Квартираның кем исеменә язабыз?” – дип сорадылар. Маһинур апа миңа карый. Мин нәрсә әйтергә теләгәнен аңладым да: “Апа, син татарларда яшьләрнең олылардан узганын кайчан күргәнең бар. Мине әллә үзеңнән олы саныйсыңмы?” – дип әйттем. Квартира шулай Маһинур апа исеменә язылды. Их, бөтен матур гадәтләребездән аерыла барабыз бит”, – дип тә уфтанган чаклары булды игелекле татар кызының.

Әнисе Мөршидә ханым 1987 елда, Маһинур апасы 1994 елда дөнья белән саубуллашалар. Мәхфүзә Кәримовна кияүгә чыкмады. 2009 елның 25 маенда тыныч кына җан биреп, Татар зиратында күмелде. Сүзләребез аны яратуыбыз, горурлануларыбыз, сагынуларыбыз билгесе булып рухына ирешсен иде.

## ДАН ИЯСЕ ДАНИЯ

*Халкың белән горурланыр өчен*
*Нигезең бар, татар баласы.*
*Татармын, дип сөен*
*Бөек халык!*
*Тарихларда мәңге каласы.*

*Гриф Хәйруллин*

Аллага шөкер, тарихыбызның тирәнлеген, халкыбызның бөеклеген аңлап, шул хәзинәбезне сакларга тырышып, хөрмәт итеп яшәүчеләребез бар. Алар шушы милли горурлыгыбыз, байлыгыбыз киләчәк буыннарга барып ирешсен өчен тырышучылар да. Мондый затлы шәхесләребезне 1990 еллардагы вакыйгалар тагын да ачыграк күрсәтте.

Шунысы куанычлы, хатын-кызларыбыз да бу хәрәкәтнең эчендә булды һәм аларның эшчәнлекләре бер Татарстан җире белән генә чикләнмәде. Татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә шул изге талпынуыбызда үзләренең хәләл көчләрен кызганмыйча мәйданга чыккан мөхтәрәмә затларыбыз күп булды. Шундый күренекле ханымнарыбыздан элегрәк Богырыслан шәһәрендә яшәп иҗат иткән, милләт байрагын югары күтәргән милләттәшебез Дания Кәримованың фидакарьлеге олы ихтирамга лаек.

Нәсел чылбырлары Казан ханы Ибраһимга (?–1479) барып тоташкан Әхмәтзыя белән Мәрьям Алтынбаевлар гаиләсендә туа Дания (нәселләре хакында Петербург архивыннан килгән рәсми кәгазь гаиләдә саклана). Буыннар хакын олылаган бу нәсел кешеләре гомер-гомергә гүзәл әхлакый сыйфатлары, тырышлыклары, изге хезмәтләре белән халык арасында олы хөрмәт казанучылар булганнар икән. Мисалга Самара өлкәсендәге атаклы Гали авылында исеме изге чишмәгә куелган Морат та шушы нәселдән икәнен генә әйтеп үтик.

Даниянең дөньяга килүе дә бик үзенчәлекле. Июль аенда, кызу печән өстендә туа ул. Үлем түшәгендә яткан Минҗиян әбисе яңа туган баланы кулына алып: “Син тудың, мин китәм инде, бәхетле-

тәүфыйклы бул, тулган аем”, – дип сөя дә, шул көнне дөнья белән саубуллаша. Әбисенең теләген хуплагандай, алма бакчаларына умарта күче килеп куна һәм шунда оялый. Халкыбыз сынамышларында мондый гамәлне гел яхшылыкка гына юрыйлар бит, шөкер, бүгенгә кадәр Даниянең тормышы нәкъ әбисе теләгәнчә бара әле, күз тимәсен. Олыны олы, кечене – кече итә белгән, бүтәннәргә мәрхәмәтле булган гаиләдә үсә кыз бала. Һәр җиде баласы туган саен сөенгән Зыя абзый, һәм аларга атап җиде агач утырткан.

Алма бакчасы үстереп, җимешләрен үзе авылдашларына, күршеләренә өләшеп йөргән ул, һәм халкыбызның гореф-гадәтләрен хөрмәтләп, көнкүрешендә кулланып яшәргә тырышкан. Авылдашлары өчен казыткан коесы да исән икән әле. Әтиләре шулай, матур гадәтләре белән, балаларына тормыш мәктәбен үзе биргән. Бары яхшы яктан гына искә алалар, сагыналар аны балалары. Мәрьям ханым да үзенең матур холкы белән, иренә һәм балаларына җылы мөнәсәбәте белән бик күпләр өчен үрнәк булып яшәгән. Урыны җәннәттә булсын.

“Оясында нәрсә күрсә, очканда шуны күрә”,– ди халык мәкале. Югары педагогик белем алып, Богырыслан шәһәр ЗАГСында өлкән инспектор булып эшли башлаган Дания, менә шул өендә алган тәрбия алымнарына таянып эшли башлый. Никахлашу тантанасына озын сөлге китерергә куша ул яшьләргә. “Тормышыгыз шундый матур, чиста, озын, тигез булсын дип, сөлгене җәеп уң аяклары белән бастырам яшьләрне. Соңыннан аларны сөлге белән урыйм да, ир белән хатын дип игълан итәм. Сөлгене кадерләп гомер буе сакларга куша идем – дип искә алды ул бервакыт. – Яшьләргә дә, әти-әниләренә дә бу күренеш бик ошый иде”.

Өйләнешкәч, ире Зөфәрнең әнисенә хөрмәтле карашы да шул өйдә алган затлы тәрбиядән. “Ун ел буе бергә яшәү дәверендә бианамнан мин күп нәрсәгә өйрәндем, бик матур яшәдек. Соңгы сәгате җиткәндә дә мине үз янымнан җибәрмәде, кулымны кулыннан төшермәде”, – ди Дания.

Богырыслан татарлары арасында Дания үткәргән, яки үткәрүдә катнашкан чаралар әйтеп бетергесез: ялгыз калган карт-карчыкларның, ятимнәрнең хәлләрен белү, ярдәмчесез калганнар вафат булса, аларны соңгы юлга озатуны оештыру, ярдәмгә мохтаҗларны

барлау, аларга хәлдән килгән булышлык күрсәтү – боларның барысын да Дания Кәримова башкара.

Ярый әле ире Зөфәр дә, аның туганнары да милли җанлылардан. (Зөфәрнең бертуган абыйсы Рәис Кәримов Богырысланда милли оешмаларны оештырган һәм җитәкләгән кеше). Менә шулай туганлашкан ике гаилә милли тормышыбызны җанландыруга, онытыла башлаган гореф-гадәтләребезне кабат торгызуга җиң сызганып тотына. Мәчет ачуда, аның уңышлы гына эшләп китүенә керткән өлешләрен дә хөрмәт белән искә алыйк. Даниянең татар балалары өчен ачылган бакчага гел ярдәм күрсәтеп, үткәрелгән чараларда катнашып, моның өстәвенә милли китапханә булдырып, укучылар конференцияләре үткәреп йөрүләрен Богырыслан халкы сагынып искә ала.

Татар иҗтимагый үзәге Богырыслан педколледжында татар бүлеге ачу мәсьәләсен күтәреп чыккач, аны гамәлгә ашыруда да Дания зур тырышлык куя. Бүләккә студентлар кабул ителә, ярты ел буе алар татар телен һәм әдәбиятын өйрәнәләр. Тик ана телен тиешле дәрәҗәдә укыта алырлык белгечләр булмаганга эш туктала.

Яшәвенең максаты итеп үз халкына хезмәт итүне куйган игелекле җан Богырыслан телевидениясендә “Наз” дигән тема ачып, якташлары, замандашлары хакында тапшырулар алып бара башлый. Бу тапшыруларга әнә шул педколледжда укыган татар яшьләрен бик теләп чакыра Дания. Студентларның да түбәләре күккә тия, шатлана-шатлана киләләр. Бу хәл моңарчы күрелмәгән булгангамы, әллә күркәм йөзе, ягымлы тавышы белән шәһәрдәшләре тормышын сөйләп, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтүе сәбәп булганмы – бөтен шәһәр аның тапшыруларын көтеп ала, фикерләшә, күпләр татар телен искә төшерә, сөйләшергә тырыша башлый.

Инде Даниянең тагын бер таланты хакында аерым бер ихтирам белән әйтми калып булмый. Дания – талантлы язучы да. Берничә ел дәвамында җирле “Бугурусланская правда” газетасында аның тырышлыгы белән татар халкы тормышына багышланган айга бер тапкыр “Умырзая” (“Подснежник”) кушымтасы чыгып килә. Нәкъ менә шуның битләрендә аның беренче хикәяләре, очерклары дөнья күрә. 2000 елда бу хикәяләр бергә тупланып “Такыя – венок из разнотравья” исемендә китап итеп чыгарыла. Язучының һәр әсәре чын тормыштан алынып, әйләнә-тирәдәге вакыйгаларга нигезләнеп

язылган. Аларның күңелгә кереп, тартып торуларының сәбәбе – тирән һәм кызыклы эчтәлекләрендә, кешеләрне һәм вакыйгаларны дөрес итеп тасвирлаудадыр. Әсәрләр шулкадәр җиңел укыла, аларны укыганда татар халкының катлаулы тарихы күз алдына килә, әби-бабаларыбызның йолалары, гореф-гадәтләре сокландыра. Әти-әнигә хөрмәт тә, балаларга мәхәббәт тә, татар җыры, моңы белән ләззәтләнү дә, табигатькә карап соклану, хозурлану кебек хисләр дә бар бу әсәрләрдә. Китабына язган кереш сүзендә ни өчен “Тәкыя” исеме бирүе хакында Дания болай ди: “Минемчә, кеше тормышын барлыкка китерүче илаһи серне бары тик үләннәр дөньясы белән генә чагыштырырга мөмкин. Алар да, барысы бер “ырудан” булсалар да, күп төрлеләр. Әмма иң “чәнечкеле”ләре дә бик еш очракта шифалы булып, матурлыклары һәм хуш исләре белән кабатланмас гүзәллек бүләк итәләр.

Ә минем “Тәкыям”да – минем ватандашларымның, милләттәшләремнең язмышлары да, йолалары да көнкүрешләре белән бергә үрелгәннәр. Кайчак алар бераз “ачы” булып тоелсалар да, аны бары тик яшереп бетерергә мөмкин булмаган тормыш хакыйкате белән генә аңлатырга мөмкиндер”.

Әйтеп үтик, бу әсәрләр кайчандыр Самара төбәгендә яшәп, соңрак Богырысланга күчеп килгән кешеләргә багышланган. Хикәяләр рус телендә, әмма аны укыганда чит тел тоелмый да кебек. Ничектер, татарча язылган, татар рухы сеңгән кебек аларга. Заманында мин аларның күбесен тәрҗемә итеп “Татарстан” радиосында яңгыраткан да идем. Күпме рәхмәт хатлары килде ул тапшырулардан соң, күпме җылы сүзләр, шигырьләр укылды, язылды Даниягә багышлап. Тәхәллүсен “Тулганай” дип бирә идек тапшыруларда. Ул исем дә бик ошады тыңлаучыларга.

*Тулганай ул кешегә көч бирә,*
*Тулганай ул маяк юлларда,*
*Шигырь язам менә сиңа атап,*
*Җырларымда кушып җырларга.*
*Изге эштә изгелекләр телим,*
*Адымыңны горур атла син,*
*Татар теле, әткәм-әнкәм теле*

*Мескен булып җирдә ятмасын*, – дип язды Наилә Насыйрова дигән ханым. Кабатлап искә алам, Даниянең тырыш хезмәтенә рәхмәт әйтеп язган хатлар бик күп булды. Шунысы кызык, алар барысы да шигырь белән язылганнар иде.

Ни кызганыч, китаптагы әсәрләрнең эчтәлеге белән таныштыру бер мәкалә кысасында гына мөмкин түгел. Әмма “Бер уч болай” хикәясен мин радиодан укыгач, минем үземә дә уннарча гына түгел, йөзләрчә кешеләр хатлар язды, күрешкәндә рәхмәт укыды.

Еллар үткәч, минем өемдә әсәрдә язылган Минәминәнең туганы шушы хәлләрнең чыннан да булган хәл икәнлеге хакында сөйләп утырган иде.

Кыскача гына эчтәлеген искә төшерим әле. Авыр сугыш еллары, ачлык, ялангачлык… Бригадир эшкә әйтеп ач хатыннарга чәчүлек орлык чистартырга куша. Өйдәге авыру әнисе, ач баласына дип Минәминә бер уч бодайны кесәсенә сала. Моны бригадир күреп ала да, милиционерларны чакырта. Минәминәне эш урыныннан ук төрмәгә озаталар. Кесәсеннән алган орлыкларны каргалар чүпләп кала.



*Дания Кәримова*

Төрмәдән кайткач, бөтен көчен куеп кечкенә генә өй сала Минәминә. Моңарчы землянкада яшәгән әнисе белән кызы хакына тырыша игелекле җан. Өй эшләнеп беткәч, идәннәрен юып чыгара да, баскыч төбенә ятып җан бирә.

Авыруыннан бераз терелгән әнисе кызының кабере янына баргач хәйранга кала. Кабер өстендә инде баш кысарга җыенган бодай үсеп утыра икән.

Менә шушы бөтен ил, бөтен татар халкы фаҗигасен Дания үз хикәясендә тирән ачыну, сагыш белән бирә алган. “Каз канаты”, “Җәйге челләдә”, “Кәҗә мамыгы”, “Әүлия тау серләре”, “Карама” кебек хикәяләрен укыгач та, тыныч кына калып булмый. Алар

йөрәкнең иң түренә, иң нечкә нокталарына үтеп керә, сызлата, сокландыра… Алардан аерылып булмый.

1992, 1997 елларда Дания Кәримова Бөтендөнья татар конгрессында делегат булып катнашты. Анда алган хисләрне, куанычлы очрашуларны онытып булмый, билгеле. Болар өстәвенә, һәр елны диярлек уздырылган журналистлар конференцияләрендә, 1994 елны “Ак калфак” оешмасы оештырган “Киленбикә” бәйге тамашасында катнашып, Галиәсгар Камал исемен йөрткән театр сәхнәсенә чыгып, “Уңганбикә” исеменә дә лаек булды әле ул. Ул бу бәйгедә аш-су пешерүдә уңганлыгын, тегү-чигүдә осталыгын, җыр-биюдә дә күпләрне таң калдыра алуын күрсәтте. Чыннан да, дан иясе ул Дания. Халыкның олы хөрмәтен тоеп, алкышларга күмелеп басып торган татар хатынына карап сокланмаган кеше калды микән. Иҗат кешесенә моннан да зуррак шатлык һәм бәхет бармы икән?

Бүген Дания белән Зөфәр Казанда, динебез кануннарын төгәл үтәп яшиләр. Зөфәр “Мөхәммәдия” мәдрәсәсен тәмамлады. Уңышлар насыйп булсын аңа. Алган белемнәре белән халкыбызга иглекле хезмәт күрсәтергә язсын.

Аллага шөкер, уллары Шамил дә, кызлары Камалия дә гаилә традицияләренә тугрылыклы булып яшиләр. Бәхетләре гомерлек булсын. Даниягә ихлас күңелемнән иҗатын туктатмавын, тагын да матур әсәрләре белән укучыларын сөендерүен телим. Амин, шулай булсын.

# МИЛЛӘТПӘРВӘР СҮРИЯ УСМАНОВА

Сүрия – матур, мәгънәле исем. Ялгышмасам, йолдыз, йолдызлык дигәнне аңлата. Бу исемне йөртүчеләргә кызыгып каравым күптәннән килә минем. Аның кечкенә генә тарихы да бар кебек.

Казан дәүләт педагогия институтында укыганда (1960 нчы еллар), Яңа тарих фәненнән безне университет доценты Мәҗитова Нәзифә Арифовна укытты. Лекцияләре генә түгел, программадан тыш сөйләгән гыйбрәтле сүзләре дә безнең өчен кызык, әһәмиятле була, йотылып тыңлый идек. Шулай бервакыт, Иран шаһы Риза Пәхләвинең хатыны Сүрия хакында сөйләде ул. Сүриянең чибәрлеге, акылы, Европада алган белеме, спорт белән шөгыльләнүе һәм мөселман хатын-кызларының азатлык өчен көрәшләренә теләктәшлеге турында җылы, матур бизәкләр белән сөйләп безне әсәрләндерде. “Их, бездә дә шундый кызлар булса иде”, – дип әйттек тыңлап бетергәч. “Аның өчен халыкның уңай шартларда яшәве кирәк, яшьләр”, – диде укытучыбыз. Үзебез өчен андый “уңай шартлар”ның булмаслыгын аңлый идек, шуңа күрә артык хыялланып маташмадык та. (Еллар үткәч, Үзәк телевидениедән Сүрия Пәхләви хакында Италиядә эшләнгән фильмны күрсәттеләр. Сүрияне, нәкъ Нәзифә апа сөйләгәнчә, матур итеп уйнады артистка).

Гомер эчендә язмыш безгә дә азрак мәрхәмәтлелек күрсәтте кебек. Бераз гына үзгәреш җилләре исеп, үткәннәребезне белергә мөмкинлек тугандай булды. Иң мөһиме, халкыбызның көрәш тарихында гасырлар буе каһарман ирләр белән иңгә-иң торып көрәшкән һәм гомерләре язгы аҗагандай ялтырап алган хатын-кызларыбыз булганын белдек. Шунысына куанабыз, замандашларыбыз арасында да исемнәре тарих битләрендә мәңге җуялмаслык, батыр йөрәкле, көрәшче кызларыбыз күтәрелеп чыкты. Аллага шөкер, чибәрлек, уңганлыклары белән дә, алган белемнәре белән дә башкалардан һич тә ким түгел алар. Алар тырыша-тырыша тудырган “уңай шартлар”ны искә алыйк әле.

1990 еллар башында Казанда һәм республикабызның башка шәһәрләрендә Татарстанның мөстәкыйльлеге һәм татар теленә дәүләт статусы даулап һәркөн саен диярлек оештырылган митингларда

меңләгән хатын-кызлар катнашты. Хатын-кызларның азатлык хәрәкәтенә кушылуы, татар зыялы кызларының (каләм иярәренең) төрле-төрле оешмалары барлыкка килү белән тәңгәл барды. Хатын-кызлар арасында иҗтимагый-сәяси эшчәнлекне җанландыру, милли гореф-гадәтләрне үстерү максатыннан, башка милли оешмалар белән берүк вакытта, Бөтентатар хатын-кызлары берлеге “Ак калфак” төзелде.

Менә шушы оешмабыз утырышларының берсендә “Сөембикә” журналы редакциясенә елмаеп килеп кереп, кояштай ачык йөзе белән тар бүлмәбезне киңәйтеп җибәргән ханым – иҗтимагый хәрәкәттә үзенең активлыгы белән танылып өлгергән Сүрия Әсхәт кызы Усманова катнашты.

“Чаллы мэриясе каршындагы гаилә, хатын-кызлар, балалар мәсьәләләре буенча оештырылган бүлекнең мөдире”, – дип тәкъдим итте Роза Туфитуллова. Ә минем каршыма, теге Нәзифә апа сөйләгән, кинода күргән Сүрия килеп баскандай булды. Әле дә гаҗәпләнеп бетә алмыйм, булса да булыр икән шундый охшашлык.

Сүрия безнең оешмабызның иң эшлекле әгъзасы, рухландыручысы булды дисәм, һич тә ялгыш булмас төсле. “Гыйффәт туташ”, “Киленбикә” конкурсларын үткәргәндә бик якын итеп, үз итеп катнашты. Матди ярдәмнәр оештыруны да һич авырсынмый үз өстенә алды бу игелекле җан. Рәхмәт аңа. Конкурсларның максаты – хатын-кызларыбызның асыл сыйфатларын, эчке матурлыкларын күрсәтү белән бергә, аларның борынгы тарихыбызны, сәнгатебезне, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне ни дәрәҗәдә белүләрен сынау да, сафлыкка, пакълыкка чакыру да булды. Чөнки халкыбыз ямьсез күренешләрдән, шәрә тәннәрдән соң дәрәҗәдә туйган, алҗыган иде ич.

Миллэтебез тормышында борынгыдан урнашкан гүзәл әдәп-әхлак күренешләре бездән һаман ерагая баруына борчылу Сүриягә туган туфрагыннан, нәселе, гаиләсе тәрбиясеннән киләдер. Ул – Чистай районындагы татар халкы хәлен гомере буе кайгыртып яшәгән олуг шәхесебез Гаяз Исхакый туган Яуширмә авылы кызы. Әнисе Саимә ханым Хөснелгата кызы гомере буе шушы авыл мәктәбендә рус теле укытып, белеме һәм гаделлеге белән укучыларның да, ата-аналарның да ихтирамнарын казанган кеше. Мәктәптә гел

“отличнo”га укыган кызы Сүриягә бердәнбер “дүртле” билгесен куйган әни дә шушы Саимә ханым.

Сүриянең әтисе – Әсхәт Харис улы Мирсияпов 17 яшьтән Бөек Ватан сугышында катнашкан. Аяклары бик каты яраланып кайткач, бухгалтер һөнәренә өйрәнгән һәм гомерен шул эшенә багышлаган. Шулай, мәгарифкә һәм тырыш хезмәткә хөрмәт белән карарга өйрәткән гаиләдә үскән Сүрия мәктәпнең иң яхшы укучысы, дружина советы рәисе, үзешчән сәнгатьнең иң актив әгъзасы (концертларның, әдәби кичәләрнең даими алып баручысы, ялкынланып шигырь сөйләүче) була. Соңрак атаклы җәмәгать эшлеклесе булып танылуына нәкъ менә шул мәктәп еллары нигез салуы һич тә шикләндерми диясем килә. Гел кеше күзе алдында, гел кешеләр арасында бит.

Һөнәр сайлаганда да иң кешелеклесен сайлый кыз бала. 1971 елда Казан дәүләт медицина институтына керә ул һәм, тагын иң яхшы билгеләргә генә укып, теш дәвалаучы табибә-стоматолог булып чыга. Студент елларны сагынып искә алмаган кеше бар микән? Сүрия дә сагына кайнап торган студент тормышын: ул группаның старостасы да, фәнни түгәрәкләрдә катнашып чыгышлар ясаучы да. Алай гына да түгел, Казандагы театрларның барсына йөрергә вакыт таба әле һәм хәтта машина йөртү таныклыгы алуга да ирешә. Болар гына аз тоелган күрәсен, ул парашют спорты белән кызыксына башлый, секцияләргә йөреп парашюттан да сикерә. Тормыштан тәм табып, яшьлектә яшьнәп яшәү шушы була торгандыр инде.

1976 елда диплом алгач, Нәсим Усманов исемле, химик-технолог һөнәре алган егеткә кияүгә чыга Сүрия. Хәзер очрашканда аларга карыйм да, “Ходаем бәхетләре гомерлек булса иде”, дим. Чөнки бер-берсен аңлап, килешеп яшәгән ир белән хатын гаиләсенә карау да сөенеч икән. Өйләнешкәч аларның икесен дә юллама белән Үзбәкстанга, Алмалык шәһәренә эшкә җибәрәләр.

Алмалык шәһәре яшьләргә балачакта тыңланган әкиятләр дөньясы кебек тоела. Бигрәк тә кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре сокландыра. Чыннан да, тыйнак һәм серле киенгән ир-атлар бер-берсен кулларын күкрәкләренә куеп, бил бөгеп сәламлиләр, баш киемнәрен салып үзара хөрмәт күрсәтешәләр икән биредә. Халыкның гадәтләре дә үзгәрәк: шулкадәр итагатьле, олыны олы, кечене

кече итә беләләр. Ә нарасый балага искиткеч хөрмәт күрсәтелә икән монда. Баласын урамга алып чыккан анага һәркем юл бирә, кибеттә дә, базарда да бернинди чиратсыз теләгән әйберсен бирәләр. Нинди матурлык! Төркиләрнең бу гүзәл уртак гадәтен үзбәкләр саклаган икән, шөкер. Бу игелекле кешеләргә яхшылыкларны игелек белән кайтаралар яшьләр. Сигез ел буе алар үз һөнәрләренең чын белгечләре икәнен күрсәтеп эшлиләр. Сүрия шәһәрнең иң яхшы теш табибы булып таныла. Тик,

*Рәхәт булса да торган җир,*

*Сагындыра туган ил,* – дип җырлыйлар бит җырда да. Туган җирне сагынып, 1984 елны Усмановлар Татарстанга кайта. Сүрия Чаллы шәһәренең стоматология поликлиникасына эшкә урнаша. Ике балалары – Наил белән Данил матур гына үсеп килә. Тормыш та җайланган кебек. Әмма Алмалыктагы матур мөнәсәбәтләр искә төшә, үзебезнең гаиләләрдәге матур гадәтләрнең югала баруы, дөньяда кешелекнең гомер җебен дәвам иттерүче Аналарның авыр хәлгә төшүләре борчый аны. Татарның киләчәге дә иң элек ана карынында, бишектә хәл ителә бит. Сүрия шушы борчыган мәсьәләләре хакында биредә оешкан җыр һәм бию ансамбле чыгышлары алдыннан залдагы халыкка сөйли. Гаиләләр язмышы борчылмаслык та түгел. Мисал өчен, 80 нче еллар азагында русларда урнашкан гаилә мәсьәләләрен өйрәнү, хәл итү юнәлешендә Россиядә әллә ничә институт, департаментлар оешкан иде. Социологлары дөньяда күпме рус хатын-кызы барлыгын исәпкә алып, рус гаиләләренә багышланган һәм тулы анализ биргән җыентыклар да чыгарып бардылар. Башка илләрдә, башка милләтләр арасында калганнарының хәлләре хакында һәм аларны саклап калу юллары хакында фәнни хезмәтләр язылды. Татар хатын-кызлары алдында да шул ук мәсьәләләр торды (һәм хәзер дә тора), тик боларны чишү юлында алар ялгыз иде.

1990 елда Чаллы шәһәр Советы депутаты булып сайланган Сүрия Усманова, 1992 елда Чаллы шәһәре хакимиятенең гаиләгә социаль ярдәм, аналар һәм балалар мәнфәгатен яклау бүлегенә эшкә чакырыла. Димәк, шушы иң авыр проблемаларның берсе өчен ул җаваплы. Җиң сызганып, күңел биреп тотына ул эшкә һәм “Гаилә” дип аталган комплекслы программа төзеп финанслатуга ирешә.

1995 елда халыкка хезмәт итүне гомеренең бурычы итеп санаган Сүрия ханым Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутат итеп сайлана. Сайлаулар алдыннан ул, үз бурычларын ачык итеп куя. “Татарстан балалары” программасын “Гаилә сәясәте концепциясе” кабул иттерергә тырышачакмын, пособияләр мәсьәләсен күтәрәчәкмен”, – ди. Һәм сайланганнан соң биш ел дәвамында шул биргән вәгъдәләрен үти дә. 1997 елда Дәүләт Советы мөнбәреннән “Татарстан балалары” программасын тормышка ашырырга бюджеттан акча сораган чыгышын ул мондый сүзләр белән башлаган иде: “Хөрмәтле депутатлар! Мин хатын-кыз, инде менә дүрт ел сезнең алда – ир-атлар алдында басып торам һәм балаларга акча сорыйм. Сез, балалардан кала барысына да акча табасыз…”.



*Сүрия Усманова*

Сүриянең бу чыгышын Татарстан телевидениесы күрсәтте. Мин аны әсәрләнеп тыңладым. Мине генә түгел башкаларны да игътибарсыз калдырмагандыр, депутатлар да күңелдән тетрәп чыккан сүзләргә битараф булмадылар. Әлеге программа, шөкер бүгенгә кадәр эшләп килә ич. Балалар өчен бюджеттан Сүрия сорап алган акчаның күп кенә өлеше сәламәтлек саклау өлкәсенә – бала тудыру йортларына кирәкле җиһазлар, аппаратлар алырга тотыла. Ә бу исә күп кенә балаларның һәм аналарның гомерләрен саклап калырга булыша. Бу гамәлләрнең мөһимлеген үз язмышында кичергән кеше генә бәһали аладыр. Әйтеп үтим, бу чорда Сүриянең парламентта төп ярдәмчеләре, иң якын фикердәшләре Фәндәс Сафиуллин белән Туфан Миңнуллиннар эшли. Милләт җанлы бу хөрмәтле затларыбыз һәрдаим аралашалар, бергәләп барлык мәсьәләләр хакында “җентекләп” сөйләшәләр. “Тел, мәгариф, мәдәният мәсьәләләрен күтәреп чыгарга, аларны да хәл итү юлларын табарга тырыша идек. Барыбызны да китапка, сәнгатькә мәхәббәт, татар язмышы өчен борчылу, иҗтимагый хәрәкәттә чыныгу алу

берләштерә иде. Ул вакытларны сагынып искә алам”, – ди үз истәлекләрендә Сүрия ханым.

Сагынадыр, ышанам. Тик халкыбыз да депутат Сүрияне сагына. Аның киләсе сайлауларда депутатлыктан төшеп калуы аяз көнне яшен суккандай булды. Шулай итеп мондый оешмаларга бик актив эшләүчеләр кирәк түгеллеген аңлый башладык. Шунысы бик аяныч – милләтебезнең киләчәге хакында тирәнрәк уйласак, әле генә искә алган гүзәл шәхесләребезгә мохтаҗлыгыбыз да ачык аңлашыла бит.

Ә Сүриябез югалмады, югалып кала торган затлардан түгел ул. Ныклы характерлы булуы да нәселдән үк килә. “Мин холкым белән әнигә охшаганмын, ә әни – Хөснелгата бабаема. “Кулак” дип аны сөргенгә сөрергә тиеш булалар. Йорт-җирен, булган бөтен малын тартып алалар. Ә ул Әлмәт районы Елховой авылыннан биш баласын, хатынын атка утырта да чыгып кача. Өйләрен сүтеп Чирмешәнгә алып китәләр. Бабай урман уртасында өй салып, гаиләсе белән шунда яши. Кызларына дип Мәскәүгә барып бирнә өчен кирәкле нәрсәләрне әзерли, ул әйберләргә дә налог салып алып китәләр. Тырышлыгы, үҗәтлеге белән ачлык елларны да ачтан тилмертмәгән балаларын”, – дип хөрмәт белән искә ала ул бабасын.

1999–2003 елларда ул үзенә юридик белем кирәклегенә тәмам ышангач, икенче югары белем алырга уйлый һәм ала да. Табибә дипломы янына юрист дипломы да өстәлә. Мондый белем аңа медицина хокуклары буенча эшләргә – лекцияләр укырга, фәнни хезмәтләрен язарга да ярдәм итә. Моның өстәвенә, ул “Медицина эшчәнлеген хокукый яктан тәэмин итү үзәге” иҗтимагый оешмасы (“Центр правового обеспечения медицинской деятельности”) җитәкчесе вазыйфаларын башкара. Талантына, сәләтенә берүк күз генә тимәсен. Аның “Что необходимо знать каждому, кто обращается за медицинской помощью” һәм “Что необходимо знать призывникам и родителям” исемле белешмә китаплары кулдан-кулга йөреп укыла, кат-кат басыла. Һәр гаиләдә өстәл китабы булырга тиешле китаплар болар. Сүзебез уңаенда “Әнием – мама” фонды белән конференцияләр, “түгәрәк өстәлләр” әзерләүдә, үткәрүдә катнашканын әйтеп кенә үтик әле тырыш ханыбызның.

“Иң зур уңышым – гаиләм, ди Сүрия. – Ирем үзе яраткан химия өлкәсендә эшли. Улларыбыз икесе дә татар мәктәбен тәмамладылар.

Наилнең ике югары белеме, фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәсе бар. Иран дәүләте буенча белгеч. Алты телне яхшы белә. Хатыны Диләрә белән оныгыбыз Зөһрә дә уртак куанычыбыз. Данил Кытайны өйрәнә, диссертациясен тәмамлап килә. Биш телдә иркен сөйләшә. Хатыны Алинә белән гаиләбезгә шатлык өстәп Сәет һәм Муса исемле оныклар бүләк иттеләр.

Мәкаләмне Иран шаһинәсе Сүрияне искә алып башлаган идем. Мәкаләмдә эшләгән эшләре, белеме хакында әле бик аз гына мәгълүмат биргәндә дә “Кара, безнең Сүриябез дә халкыбызның горурлыгы, мактанычы булырга бик тә лаеклы кызы ич”, – дип уйлап сөендем. Тик, ни кызганыч, татар кызлары хакында фильмнар төшерелми шул. Дөнья халыклары арасында гадәти булмаган каһарманлыклар күрсәтсәләр дә юк ул фильмнар. Тик бер өмет бар: яшьләребез татарның талантлы шәхесләрен белсеннәр, гомер юлларын, кылган гамәлләрен белеп соклансыннар иде инде. Амин.

## ШӘФКАТЬ ИЯСЕ ТАБИБӘ ЛИЛИЯ ХАНЫМ

Сүземне иң күренекле һөнәр ияләре – табиб, табибәләр хакында башлыйсым килсә дә, бераз тарихыбызга күз салыйк әле…

Олуг галимебез Шиһабетдин Мәрҗанинең әнисе Бибихәбибә баладан үлә. Иң соңгы минутларында Шиһабетдинне чакырып китереп, баласының башыннан сыйпый, үзәк өзгеч саубуллашу сүзләрен әйтеп калдыра.

Бер шәкерт Шиһабетдинне әнисенең җеназасы артыннан күтәреп зиратка алып барган…

Ни кызганыч, ул заманнарда хатыннарга табиб чакыру гадәткә кермәгән әле. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә дә шундый язмышка дучар булган. Нәни Габдулла әнкәсенең җеназасын алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлендә, капка астыннан үкереп елый-елый йөгереп чыгып: “Әнкәйне бирегез!” дип мәет күмүчеләр артыннан йөгерә…

Табиб чакырылмауның сәбәбе хәзер билгеле, чөнки, бердән, ул вакытларда татар хатынының гәүдәсе, бөтен җире гаурәт саналган. Аны чит-ят күзләргә күрсәтергә ярамаган. Икенчедән, авылларда гына түгел, шәһәрләрдә дә табиблар юк дәрәҗәдә.

XIX гасыр урталарында (елын төгәл генә күрсәтә алмыйм) Казан губернасында ваба авыруы тарала. Татар авылларына ярдәм белән килгән “урыс докторларын” надан муллалар кертмиләр. Бу авырудан бигрәк тә хатын-кызлар кырыла, инде әйтеп үткәнебезчә, татар хатынының гәүдәсе – гаурәт, күрсәтергә ярамый. Менә шунда Ш.Мәрҗани, бу фаҗигага чыдый алмый, губернатор кәнсәләреннән торып, муллаларга фәтва бирә: “наданлык корбаны булмагыз, докторларны авылга кертегез, дәвалауны оештырырга ярдәм итегез”, – ди. Бу мөһим чараның кирәклеген бөтен кискенлеге белән аңлау яралгысы әнә теге чакта – әнисе җеназасы артыннан барганда салынмады микән олуг шәхесебезгә?

Бүген медицина хезмәткәрләре арасында татар хатын-кызларының сан ягыннан күпме икәнлеген әйтә алмыйм, кызыксынганым юк. Тик, хастаханәләргә йомышыбыз төшсә, табибларның кайсы милләттән булулары белән кызыксынабыз. Үз табибларыбызга, үз

ана телебездә сөйли алсак, хәлебез ничектер җиңеләя, сәламәтләнергә ышанычыбыз арткан төсле була. Шөкер, милләттәшләребез арасында соклангыч матурлыкка ия булучы табибәләр бар. Тышкы матурлык хакында әйтүем түгел, ә бәлки тышта, йөздә чагылган, саф әдәплелек, горурлык, югары әхлак белән чорналган эчке матурлыкны әйтәм. Эчке эшләр министрлыгы каршында ачылган госпитальдә 20 елдан артык намус белән хезмәт иткән Сәфәргалиева Лилия Хәтим кызы әнә шул сыйфатларга ия.

1965 елның 9 нчы маенда Кукмара районы Балыклы авылында туган ул. Җиде яше тулгач, Лилия туган авылындагы башлангыч мәктәпкә укырга керә. Дүртенче сыйныфтан соң Олыяз авылы мәктәбендә укып, урта мәктәпне 1982 елда Янил авылында тәмамлый. (Шулай үз туган авылында беренче сыйныфтан унынчыга кадәр уку бик күпләр бәхетенә эләкмәде әле ул елларда да). Аның мәктәп еллары тарихи вакыйгаларга, төрле үзгәрешләргә бик бай еллар булмаса да, халыкта өмет кузгала, тыныч тормышка ышаныч туа башлаган еллар иде. Өметле яшьләр күпләп уку йортларына агылдылар, республикабызда яңа уку йортлары ачылды ул вакытта.



*Лилия Сәфәргалиева*

Лилия дә күңеле тарткан уку йортына – медицина институтына керергә хыяллана. Тик беренче талпыну уңышсыз чыга, авылына кире кайта, үзе укыган мәктәпкә эшкә урнаша һәм ике ел пионер-вожатый булып эшли. Хезмәтен никадәр яратса да, медицина күңеленнән чыкмый кыз баланың. Ул тагын Казанга килә һәм имтиханнарын уңышлы тапшырып, медицина училищесында укый башлый. Кечкенәдән зирәк, кызыксынучан, һәрнәрсәгә үз акылы белән төшенергә, аңларга омтылган Лилиягә бу уку йортында уку авыр булмый. Ул 1987 елда, Кызыл диплом алып, укуны тәмамлый да, ниһаять күптәнге хыялы – Казан медицина институтының лечебный (дәвалау) факультетына керә.

Әйтеп үтик, кыз баланың үз максатына ирешер өчен шундый ныклык күрсәтүендә әбисенең сеңлесе Мөхтәрәмә ханымга карата олы хөрмәт ятадыр кебек. Чөнки 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашып, Берлинга кадәр барып җиткән һәм соңыннан 4 авылга фельдшерлык хезмәте күрсәткән бу олы йөрәкле татар хатынының хезмәте халкыбыз алдында зур ихтирамга лаек. Урыны җәннәттә булсын.

Институтта укыган елларын сагынып искә ала Лилия ханым. Чыннан да, бай тарихлы, медицина өлкәсендә зур ачышлар ясап, исемнәре бөтен дөньяга шаулаган галимнәре белән дан тоткан уку йортында укуы белән ничек шатланмасын да, хәзер ничек сагынып искә алмасын кыз бала! Үз хезмәтләренең чын осталары булганга студентларның олы хөрмәтен казанган гыйлем ияләре Салихов Илдар Газыйм улы, Терегулова Венера Салих кызы һәм башкаларның лекцияләрен йотлыгып тыңлый, киләчәктә үзе дә нәкъ менә шул остазларына охшарга тырыша. Уку елларында (1987 елдан 1995 нче елларга кадәр) Казан шәһәренең №1 (Шамов ис.) хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшли, һөнәренең үзенчәлекләрен ныклап өйрәнә, зур практик белем, тәҗрибә туплый.

Шулай санаулы студент еллары үтеп китә. Лилия Хәбибрахманова кулына врач дипломын алып Эчке эшләр министрлыгының хастаханәсенә эшкә килә. Аллага шөкер, бәхетенә бу дәвалау йортының коллективында да үз эшләренә намус эше итеп караган чын һөнәр ияләре эшли. “Мин эшкә килгәндә терапия бүлеген зур белемле, ифрат акыллы, искиткеч кешелекле Курашов Михаил Игъ-

натьевич җитәкли иде. Үзенең белемен, тәҗрибәсен һич кызганмый, аның белән киңәшләшү бик рәхәт иде. Шунда ук Әнисә Нигъмәтовна, Галиева Хәҗәр Шәфигулловналар эшли – бик пөхтә, акыллы табибәләр, эш тәҗрибәләре, белемнәре соклангыч иде. Исхакова Әлфия Нурмөхәммәтовнадан да күп нәрсәгә өйрәндем. Зур белем иясе, тырыш һәм чын мәгънәсендә зәвыклы, зыялы белгеч, республикабызның атказанган табибәсе. Менә шундый үз эшләренең чын осталары белән эшли башлавыма сөенәм, – ди Лилия Хәтимовна. – Хәзер дә коллективыбызда горурланып искә алырдай белгечләребез күп”.

Лилия ханым санап киткән табиб-табибәләребез хакында исемнәрен генә язсак та, мәкаләбез бик озынга китәр иде, аларның авырулар өчен күңел биреп тырышканнарына сөеник тә, барысына да рәхмәт әйтик.

Ә кыз баланың гаилә тормышын искә алыйк. Чөнки кеше сәламәтлеге өчен тырышкан, һәр авыруы өчен борчылып ярдәм иткән табибәнең үзенә дә зур терәк кирәк. Бу яктан Лилия Хәтим кызының, Аллага шөкер, зур бәхете, арка терәге бар. 1988 елда якташы Илфат Сәфәргалиев белән өйләнешәләр алар. Нур өстенә нур булып 1989 елда кызлары Диләрә, 2000 елда уллары Ильяс туа. Олы мәхәббәткә нигезләнгән тәртипле гаиләдә балалар тууы да тырыш хезмәткә киртә салмаган, шөкер. 2003 елдан Лилия Сәфәргалиева терапия бүлеге җитәкчесе, танылган белгеч. Аның медицина журналларын укып, үз белгечлеге буенча шәһәребездә үткәрелгән төрле конференцияләрдә, симпозиумнарда катнашып йөргәнен белгәч: “Фән белән кызыксынасыз, диссертация язарга уйламыйсызмы?” – дип сорадым. Үз җавабында Лилия ханым тыйнак кына итеп: “Фәннән бөтенләй аерылып булмый ул, дөрес. Ә диссертациягә тотынгач, теләсәң-теләмәсәң дә бер генә юнәлешкә, шул темага игътибарны күбрәк бирмичә булмый. Ә минем авыруларны төрле яктан карап, төрлечә дәвалау ысулларын өйрәнеп дәваласым килә. Мин хаклы микән ә?” – дип сорау куйды.

Аның хаклы икәненә мең кат ышанам. Чөнки үземә бик авыр хәлдә бу игелекле табибә кулында дәваланырга туры килде. 27 яшьлек бердәнбер баламны фаҗигале төстә югалткач кердем хастаханәгә. Минем туганым да, якыным да түгел Лилия Хәтимовна. Ә

җаннарымны эретерлек рәхимлелеге, йомшак мөгаләмәсе, кешелекле карашы белән дәвалады ул мине. Аңа Олы рәхмәтем булсын. Әйтеп үтим, миңа гына түгел иде бу рәхимлелек. Палаталарда яткан барлык авыруларга да бу матур мөнәсәбәт, чын күңелдән хәлебезгә керә белү җитә иде. Һәр авыруның күңел тирбәлешләрен, кайгыхәсрәтләрен сизә, һәрвакыт елмаюлы карашы, йомшак, җылы сүзләре белән аларны таратырга булыша ул. Шуңа күрә, әнә бит дәвалanучылардан күпме рәхмәт ишетә.

Әнә шундый чын, олы табибә булып җитешкән Лилия Хәбибрахманова-Сәфәргалиеваның әнисе Нурҗиһан Котдус кызының рухы шатлансын. Гаиләсендә иреннән аерылып та юньле балалар үстерә алган ул, рәхмәт. Кызына да, ир баласы Газинурга да кешеләр соклана. Хәбибрахманов Газинур – Кукмара районында бүген дә эше гөрләп барган “Урал” колхозы җитәкчесе. Рәисебез Рөстәм Нургали улы Республикабызда үрнәк эшләре белән макталган шәхеснең исемен үзе белем алган мәктәбенә бирергә тәкъдим иткән. Зур куаныч бит бу. Киләчәктә дә аларның эшләре гел шулай сөенечләр китерсен. Талантлары, бәхетләре гомерлек булсын.

## ТАНЫШ ӨЯНКЕЛӘР ДӘ РӘХМӘТ ӘЙТӘ…

Әтнә районының Күлле Киме авылы күңелемә бик якын, газиз җир. Мин монда урта мәктәпне тәмамладым. Укырга йөргәндә Киме авылы бик зур, анда яшәүчеләр дә башкачарак, зәвыклырак кебек тоела иде. Ни кызганыч, бу аерымлыкны сизгән күңелгә Киме тарихын, анда яшәгән һәм эзләре калган шәхесләрне белү, алар хакында ишетү насыйп булмаган шул. “Бабабызның кече балаларыннан Бибигайшә бинте Габденнасыйр Киме имамы мелла Фазыл бине Ибраһим бине Арслан […] никахында булып, 1267 (1850) елда мөхәррәм аенда вафат булды […] утыз сигез яшендә Киме каберлегендә җирләнде”, – дип яза олуг галимебез Шиһабетдин Мәрҗани. Димәк, җеназасында үзе дә катнашкан. Кимедә булып та, авыл имамнары, затлы, зыялы кешеләре белән аралашмыйча китүе мөмкин түгел.



*Луиза Шәмсиева*

Бибигайшәнең оныгы, тарихыбызда билгеле шәхес, Киме имамы Габдрахман мулла янына бөек Тукаебыз да килгән. Бу хакта, Аллага шөкер, хәзер дә исән, укытучыбыз Җәләлиева Рәмлә апа сөйли. Аңа бу хакта әнисе күп мәртәбәләр сөйләп калдырган.

Кимедә туып-үскән, яисә нәсел җепләре бу авыл белән тыгыз бәйләнгән шәхесләр күп әле. Тик аларның берсе Халык шагыйре Сибгат Хәким, дөресрәге аның музеен оештыручы игелекле җан Луиза Әһли кызы Шәмсиева хакында язасым, сөйләсем килде. Бу хөрмәткә лаеклы, бик тә лаеклы ханым ул Луиза.

“Сибгат абый һәм аның гаиләсе белән кырык елга якын аралашып яшәдем, – дип яза ул үз истәлекләрендә. – Хатлар алыша идек. Бер хатында: “Хөрмәтле Луиза. Бөтен токымыгыз белән, Габдулла Сабировтан башлап, минем беренче уку елларымнан башлап, гомеремнең ахырынача Сез булыштыгыз. Бөтен нәселегездә татар культурасына, аның вәкилләренә тирән ихтирам яши. Сезнең кебек кешеләр булганда безнең әдәбият үсәр, яшәр, киләчәге өметле”, – дип язып, мине канатландырды”.

1935 елның 28 июлендә Кимедә туган кыз баланың тормыш юлына күз салыйк әле. Аның әтисе Әһлиулла Сәмигулла улы авылдашлары хәтерендә бик тәвәккәл, халык арасында зур абруйлы, оста оештыручы, үтемле сүзле кеше була. Революция ярлыларга бәхет китерә дип ышанган, шуңа күрә яңа тормыш төзү өчен хәләл көчен кызганмаска тырышкан. Колхозлар төзелә башлагач, Күәм авылында рәис булып эшләгән, тик бу яңалыкларны кабул итә алмаучылар тарафыннан чак кына үлмичә калган. Тик Совет властена уңган, булганнарның кирәге бетә, Әһли абый да шәхес культы корбаны булып дөньядан китә. Сөекле хатыны Хәтимә белән бары 8 ел яшәп кала алган ул. Әтисе үлгәндә Луизага бары ике яшь була.

Әнисе Хәтимә Сабирҗан кызын Луиза иң җылы, күңел түреннән чыккан иң олы хөрмәт белән искә ала. Ваклап сорашсаң, һәр адымын, һәр хәрәкәтен, эшен сөйләп бирер кебек. Чыннан да, Күлле Киме авылында кызлардан беренче булып җидееллык мәктәпне тәмамлауга, Югары Көек башлангыч мәктәбенә мөдир итеп билгеләнә Хәтимә. Шуннан бер туктаусыз мәгариф эшендә 34 ел үткәреп, 1960 елда пенсиягә чыга.

Хәтергә төшерсәк, кеше тормышында иң авыр еллар бит бу. Сугыш, сугыштан соңгы елларның газабын сөйләп тә, язып та бетерерлек мени?

“Әнием кечкенәдән кызыксынучан, тынгысыз, кулы нәрсәгә тотынса, шуны эшләп булдыра торган бала булып үсә, – дип сөйләде

Луиза. – Шуңа күрә этисе, ягъни минем бабаем аңа еш кына: “Кызым, син ялгыш кына кыз бала булып тугансың, синең белән эшләве бик җиңел”, – дия торган була”. Шул уңганлыгы тормыштагы авырлыкларны җиңәргә булышкандыр дип уйлыйм Хәтимә апа хакында.

Чынлап та, читтән торып укып белемен күтәрү дисеңме, ничә авыл мәктәбендә мөдир, кулында энисе һәм тагын ике бала, күпме өелеп торган җәмәгать эшләре – барысына да өлгерергә кирәк. Әмма иң авыры – якыннарының нахакка хөкем ителүләре, алар өчен борчылып яшәү. Хәтимә апаның бертуган абыйсы Габдулла Сабиров – Сибгат Хәкимнең укытучысы, шәхес культы буенча хөкемгә тартылып, 10 ел утырып исән-сау кайткан кеше. Шагыйрь белән гомер буе аралашып, серләрен уртаклашып яшәгән.

Хәтимә апа матур моңлы тавышлы җырчы булган икән. Күңел яраларын, хәсрәтләрен җыры белән төзәтергә тырышкан. “Кешеләр аның җырларын сәхнәләрдә тыңлап, елап кайгыларын баса торган булганнар. Юморга бай, көләч йөзле, йомшак тавышлы әниемне халык ихтирам итте: яшьләр дә, аксакаллар да киңәш, йомыш белән әледән-әле киләләр иде”, – дип искә ала Луиза.

Йә, шундый гаиләдә үскән кыз нинди һөнәр сайларга дип баш ватамы соң? Билгеле әнисе, абыйсы юлыннан китә, Казан педагогия институтын тәмамлап укытучы була. Луиза укыткан вакытта мәктәпкә барырга да, дәресләренә керергә дә туры килмәде. Әмма бертуган энем Габделәхәт Сәфәров: “Апай, син укытучылыкка укыйсың бит, Луиза апай кебек укытсаң иде син, кайтып, кер әле шуның дәресләренә”, – дип үтенә иде. Бер җәйне, Сабан туена кайткач, күрше егете, сабакташы Нәҗмиев Харис белән Кимегә алып барып, таныштырдылар алар безне. Шушы бер очрашудан алган тәэсир, бу чын мәгънәсендәге укытучы, тирән белемле, олы җанлы, саф намуслы затлы-зыялы шәхесне бәяләргә, аның белән аралашып яшәвемне тормышымның бер матур, куанычлы бизәге дип тоярга ярдәм итә. Рәхмәт Луизага, шулай туганыдай күреп, якын итүе өчен. Мондый матур мөнәсәбәтләр бер минем белән генә түгел бит, шунысы да куанычлы.

“Мин укытучы кызы булуым белән горурланып яшәдем, – ди Луиза. – Укытуыма тел-теш тия күрмәсен дип тырыштым. Җәмәгать эшләренә дә, колхоз эшенә дә катнаша идем. Өстәвенә “Алга”

колхозы каршында чыга торган стена газетасын җитәкләдем. Радиоузелдан атнасына ике тапкыр колхоз һәм мәктәп яңалыклары белән тапшырулар алып бардым. Күп тапшыруларымда Сибгат Хәким дә катнашты.

Эшемне яраттылар, рәхмәт. Макталдым, бүләккә бирелгән грамоталарым да күп”.

Луиза – Россиянең мәгариф отличнигы, ТР Президентының “Рәхмәт хаты” иясе. Аллага шөкер тормышы төзек. Ярты гасырдан артык бергә яшәгән ире Мансуры, балалары Айрат белән Алмаз, оныкларының олы хөрмәтен, күңел җылысын тоеп, сокланырлык матур яшиләр алар. Ходай гомерлек итсен.

Луизаның халкыбызның мәдәниятенә күрсәткән олы хезмәте – Сибгат Хәким музеен оештыру, ачу һәм аны зур хәзинәбезгә әверелдереп, саклап тотуы. Музей, шагыйрь үзе исән вакытта ук, 1981 елның 26 декабрьдә әдәби бүлмә буларак ачыла. Шул вакыттан бирле шагыйрьнең әдәби мирасын, тормыш юлын халыкка җиткерү өчен күпме тырышлык куелган бит. Юкка гына Сибгат Хәким: “… Мин Сабировлар яшәгән чорда дөньяга чыгып калганмын әле. Шуңа шат, алар канатландырды…”, – димәгәндер. Луизаның әтиәнисе, абыйсы һәм үзе белән якын дуслар булып яшәгән шагыйрь әнә шулай бәяли, шулай әйтә рәхмәтен.

Каләмдәш дуслары, гаиләсе, артистлар белән кайта шагыйрь үз музеена. Истәлекләр китабына: “Туган җиргә, туган туфракка кайттым, яшьлеккә, балачакка, истәлекләргә. Миңа багышланган бу музей шуларның барысын да искә төшерде. Оештыручыларга зур рәхмәт”, – дип язган.

Музей хәзер яңа төзелгән мәктәпнең 90 кв.м. урынын алып тора. Фонды бик бай, кызыксынучылар, эзләнүчеләр өчен бик кызыклы. Шагыйрьнең, гаиләсенең шәхси әйберләре күп: ул укыган китаплар, кулланышта булган савыт-сабалар, утырып шигырь язган өстәл-урындыклар – барысы да шагыйрьнеке. Шагыйрь үскән йортның рәсеме, әтисе Хәким абый эшләгән урындык, газиз әнкәсе көйли-көйли тирбәткән кабык бишек, арба, чыгыр – барысы да “без аның балалык шаһитләре” дияләр төсле.

С.Хәкимгә килгән хатлар – музейның зур байлыгы. Г.Афзал, Н.Нәҗми, Г.Әпсәләмов, М.Кәрим, С.Сөләйманова, С.Кудаш һәм

башкаларның хатлары ул. Алар шагыйрьгә, аның иҗатына тагын да якынрак килергә, эчке дөньясын ачарга ярдәм итәләр. Шуңа күрә күпләр музейга махсус килеп шагыйрь мирасын өйрәнәләр дә.

Кайдан гына килмиләр шагыйрьне олылап. Казан, Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән шәһәрләреннән дә, Кукмара, Балтач, Әтнә, Арча, Биектау һ.б. районнарыннан да татар теле һәм әдәбияты укытучылары музейда булып төрле-төрле чаралар үткәрүдә якыннан катнашканнар икән. Мондый чараларның тематикасы төрле: “Сибгат Хәким – туган як җырчысы”, “Татар язучылары һәм шагыйрьләре Бөек Ватан сугышында”, “Шагыйрь лирикасында – табигать”.

Бу чараларны, укучылар конференцияләрен уздыру Луизадан күпме көч таләп иткәнен аңлашыладыр дип уйлыйм. Әле ул үзе дә шагыйрьне күреп белгән, гаиләсе белән, әйтеп үткәнемчә, аралашкан. Килүче кунакларга шагыйрь хакында җанлы кеше итеп, дус якын итеп сөйләве дә ни тора бит. Өстәвенә күпме шигырен яттан белә, сөйли. Шуңа күрә дә тыңлаучылар күп вакыт йә бергә кушылып шигырь сөйләргә тотына, йә җырлап та җибәрәләр икән. Ә рәхмәт әйтеп язылган сүзләр күпме:

*Кан тартмаса, җан тарта ул, диләр*
*Кан да, җан да алып килде мине*
*Киләчәккә өмет белән яши.*
*Өмет белән сулый Күлле Киме.*

*Халыкның киләчәккә табыну урыны булырлык итеп җыелган бу байлыкның олы киләчәге бар! Бу байлык өчен мең рәхмәт.*

*Мөдәррис Әгъләмов*

*С восторгом и восхищением посетила музей. Даже представить себе невозможно, что в глубинке Татарстана можно сделать такой музей, с таким глубоким содержанием и любовью.*

*С искренним уважением к Луизе Аглиевне, которая сумела сотворить чудо, Надеюсь на сотрудничество.*

*Ректор ТИСБИ –*
*Нэлла Матвеевна Прусс*

*Рәхмәт инде,*
*Авылдашлар, барысы өчен,*
*Авылыгызда шундый шагыйрь үскән өчен,*
*Рәхмәт инде, Сибгаткә*
*Тел ачкычы биргән өчен…*
*Рәхмәт инде,*
*Җитәкчеләр музей ясап,*
*Сибгатне үлемсез иткән өчен.*
*Рәхмәтемнең иң зурысы Луизага.*
*Теләк телим киләчәктә*
*Музей эшен дәвам итсен өчен,*
*Җан азыгы биргән өчен.*

*Сибгат Хәкимнең хатыны*
*Мөршидә Хәкимова*

*Музейда булып узган очрашуда катнашуыма чиксез шатмын. Сез булганда татар яшәр, татар авылы мәңге югалмас. Эчкерсез, самими, сабыр авыл кешеләре алдында сокланып башым иям. Музей бик кирәк һәм аның эшчәнлеге киләчәк өчен бик мөһим. Бик зур рәхмәт.*

*Проф. Фирдәвес Гарипова*

Бу язмалар – диңгездән бер тамчы. Әмма язмамны Луизаның үз сүзләре белән төгәлләсем килә:

“Минем балачагым ләгънәтле сугыш елларына, аннан соңгы илне тергезү белән бәйле авыр заманда үтте. Сугыш алып килгән фаҗигаләр, авырлыклар күңел түрендә саклана.

Сугыш беткәнгә 70 ел, миңа 80 яшь. Күпме сулар аккан, күпме җилләр искән. Тик балачактагы әрнүләр һаман сыкрый әле. Кеше язмышларын ачып бетереп булмый, бу – табигый хәл.

Күлле Киме – минем язмышым, гомерем юлы. Телем шушы авылда ачылган, бөтен гомер туган авылда, Сибгат Хәким кебек олы шәхесләр белән аралашып узды. Бәхет түгелмни бу?

Ходай биргән бар гомерен дә бәхет, шатлыклар эчендә, сәламәтлек белән узсын Луиза! Сиңа рәхмәтне хәтта шагыйрь сокланган өянкеләр дә әйтәләр кебек.

# САБЫРЛЫКНЫҢ ГҮЗӘЛ БЕР ҮРНӘГЕ ИДЕ

Заманабызның иң затлы шәхесләребездән саналырга хаклы Чәчкә апа Мостафина белән дуслыгыбызга чын күңелемнән шатлана идем. Әмма хәсрәтле язмышы йөрәгемне әрнетә иде шул.

“Халык дошманы балалары” дип Себергә озатылганда Чәчкәгә – 8, сеңлесе Гөлкәйгә – 6 яшь тулган була.



*Чәчкә Сәлах кызы Атнагулова-Мостафина*

Әти-әниләреннән кала иң якын кешеләре – әби-бабаларыннан да аерып, аларны “кечкенә җинаятьчеләр” өчен махсус оештырылган колонияләрнең берсенә, Свердловск өлкәсендәге Ирбит (Эрбет) шәһәренә җибәрәләр. 2 яшьлек энеләре Вил (киләчәктә талантлы шагыйрь булып танылачак) Казандагы колониядә калдырыла. Бер мизгелгә генә үзеңне әлеге сабыйлар урынына куеп карасаң, җаннарны тетрәткән бу фаҗиганең ачылыгын шунда ук аңлыйсың…

Бу балалар талантлы шәхесләр гаиләсендә туган һәм нәселдән килгән затлылыкны мирас итеп алган. Әтиләре Сәлах Садри улы Атнагулов – педагог, сәяси эшлекле, публицист, язучы. Милләт мәҗлесе депутаты (1917–1918), Үзәк татар-башкорт комиссариатында Хәрби коллегия әгъзасы (1919–1920), “Кызыл Армия”, “Эшче” (Мәскәү), “Татарстан” газеталары мөхәррире, Гыйльми Үзәк рәисе (1927–1929), Башкортстан тарихына, татар теленә һәм орфографиясенә багышланган фәнни хезмәтләр, әдәби китаплар авторы. 1936 елны кулга алынганда, ул Казан педагогия институты доценты була.

Әниләре Зөһрә Сөләйман кызы Мостафина башта атаклы Фатыйха Аитова мәктәбендә, соңрак гимназиядә, икенче баскыч совет мәктәбендә белем алган. Политехника институтының икътисад

факультетын тәмамлаган. ВКП(б) ҮК каршындагы коммунистик оешмалар бүлеге нәшриятында эшләгән.

1926 елда “Азат хатын” журналы чыга башлагач, Зөһрә ханым аның җаваплы секретаре була. Татиздат юлламасы белән аспирантурага хәзерлек курсларында да укый әле. Сәлах абыйның да, Зөһрә апаның да тавышлары бик матур булган, халык җырлары белән бергә, алар төрле арияләр, романслар да оста башкарган. Музыкага мәхәббәт әти-әнисеннән Чәчкә апага да күчкән.

Киләчәккә матур өметләр белән канатланып яшәгән тормыш җимерелә. 1936 елның 1 сентябрендә (олы кызлары Чәчкәнең 1 сыйныфка укырга кергән елы) – Сәлахны, ә 1937 елда Зөһрәне кулга алалар. Колониягә озатылганчы, балалар Зөһрә апаның әти-әнисе янында кала. Әбиләре аларны үз янында гына яшереп калырга бик тырыша да, тик һаман кайларда гына яшереп бетерәсең соң?

Чәчкә апаның көндәлегендә әти-әнисе хакындагы истәлекләр байтак. “Әтиемә ял эләксә, безнең белән бергәләп урамда йөрергә, төрле әкиятләр сөйләргә ярата иде. Безнең өчен матур-матур хикәяләр яза, җырларга өйрәтә”. “Шулай бервакыт, – дип сөйли ул, – әти белән Казансу буйлап “Троицкий урманы” дип йөртелгән урманга хәтле бардык. Алда тимерчыбык белән уратып алынган койма, эчтәрәк шыксыз бер йорт күренә. “Бу нинди йорт?” – дип әтиемнән сорагач, ул миңа: “Яшь җинаятьчеләр тотыла торган йорт”, – дип аңлатты. Мин бик курыктым, тизрәк китүебезне үтендем. Язмыш шаяруы дими ни дисең, 1937 елның 12 сентябрендә үзебез шул йортка эләктек… Бу вакытта анда шулай ук әти-әниләре кулга алынган 12 яшькәчә балалар тотыла иде. Монда китерелгәч, шактый гына танышларымны да күрдем.

Көндезләрен безне чәнечкеле чыбык белән уратылган ишегалдына йөрергә чыгаралар иде. Бер чыгуыбызда исемнәребез белән дәшкән тавышка койма янына бардык һәм ярыктан әбиебезне күреп алдык! Ул шундый ерак җиргә җәяүләп безне күрергә дип килгән икән, бичара. Ә бераздан безне Эрбет каласына озаттылар”.

Эрбеттә туганнар аерылыша. Дөресрәге, аларны аералар – икесен ике балалар йортына урнаштыралар. Чәчкә апа үзе эләккән балалар йортының директорын рәхмәт хисе белән искә ала. Балаларга рәхимле була ул кеше. Чәчкәнең музыкага сәләтен күреп,

хәтта музыка укытучысына дәрескә йөрергә дә куша. Бер елдан соң кызларны Зөһрә апаның әтисе Сөләйман абзый эзләп таба һәм Казанга алып кайта. “Ул чакта бабайның өстенә кигән киемнәрен күреп, аны бик кызганганым истә, – дип сөйли Чәчкә ханым. – Аларның үз гаиләләрендә дә кулга алынучылар күп булган. Бөтен булган мөлкәтләре тартып алынган, тормыш итәргә җай да калмаган”. И дөнья! Сәлах Атнагуловның архивтагы шәхси эшендә гаиләсеннән тартып алынган әйберләр исемлеге саклана. Өй җиһазлары, савыт-саба, кием-салым, бай китапханә тартып алынганга исем китмәде. Әмма “детские чулки – 1 штук” дигән язуны күргәч, тетрәндем. Бик озак тынычлана алмадым: бер сыңар оекны балалардан тартып алып, оялмыйча шуны исемлеккә кертеп язып утырырга кемнәрнең, ничекләр кулы күтәрелде икән?

Чәчкә Сөләйман бабасы фамилиясен ала (соңрак балаларның өчесе дә Мостафин фамилиясендә йөри). Тик кара сакал бер иярсә, артыңнан каламыни ул?! 1940 елда – бабалары, 1943 елда әбиләре вафат була. Балалар әниләренең бертуган сеңлесе Хәдичә апалары кулында кала. Апаларына еш кына эш буенча командировкага китәргә туры килә. Шуңа күрә күп вакыт балалар өйдә үзләре генә дә тора.

Аларның тормышы никадәр авыр булуын күзаллау кыен түгел. Унынчы сыйныфта укыган Чәчкәнең мәктәпкә йөрергә юньле кикеме дә булмый. “1946 елны әни лагерьдан телогрейка киеп кайткан иде. Мәктәпкә шуны киеп йөрдем. Телогрейка эченнән кияргә кофтам юк иде. Яхшы укыгач, мәктәптә математика түгәрәге алып бара идем. Беркөнне түгәрәк җитәкчеләренә директорга керергә куштылар. Өске кикемемне класста салып калдырырга кирәк иде. Телогрейканы сала алмагач, кермәдем инде. Гарьлегемнән бик каты еладым шул чакта”, – ди Чәчкә апа. Ул елларда, бик-бик авыр сәгатьләрдә өметсезлектән, күңел төшенкелегеннәнниләр коткарып калды икән аны?

Мәктәптә “отлично” билгеләренә генә укый Чәчкә. “Математикага сәләт әтидән күчкәндер”, – ди ул тыйнак кына. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлагач, университетка керә. Яхшы укыган кызны комсорг итеп сайламакчы булалар. Тик ярамый – “дошман баласы”. Бишенче курста укыганда университетның математик анализ кафедрасы мөдире, профессор, атаклы галим Гагаев Борис Михайлович

аны: “Аспирантурага бары үземә киләсең”, – дип чакыра. Университет Советы ризалык бирми – әлеге дә баягы, “дошман баласы”. Номерлы предприятие вәкилләре эшкә чакыргач, Чәчкә: “Миңа ярамый”, – дип үзе баш тарта.

Татарстанның Куйбышев районы үзәгендәге педучилищега укытучы булып урнаша ул. Физика, математика, методика, немец теле фәннәре укыта. Биредә Чәчкә дүрт ел эшли. Шул еллар буе училище директоры Насыйров Гата Сираҗетдин улы аны аспирантурага керергә өнди. Әмма Чәчкә аспирантурага имтиханнарны педучилище ябылып, Казанга кире кайткач – 1955 елны гына тапшыра.

Аспирантура тәмамлау белән Алабуга педагогия институтына эшкә китә. Биредә математика кафедрасында өлкән укытучы, физика-математика факультеты деканы, фән һәм укыту буенча директор урынбасары вазыйфаларын башкара. 1963 елдан Казанга кайтып, дәүләт педагогия институтының алгебра һәм геометрия кафедрасында эшли һәм 1984 елда ялга китә. Чәчкә Мостафинаның математика буенча дистәләрчә фәнни хезмәтләр авторы икәнен әйтеп китү дә урынлы булыр.

Ул гаилә архивын күз карасы кебек саклап тота, барлый, мәгълүматлар өсти. Әтисе хакында язылганнарны бөртекләп җыя, төрле кешеләрнең истәлекләреннән эзләп табып, тулы бер образын тудырырга тырыша. Әтисенең ниндидер могҗиза белән исән калган хезмәтләрен китап итеп бастырып чыгарырга хыяллана – аларны латиннан кириллицага күчерә.

Гаилә фотоларын караганда, аңардан әнисе Зөһрә апа хакында сорашам. Утызынчы елларда татар кызлары аспирантурага керә алмаган. Керергә теләүчеләр күп булса да, гел киртә салып торганнар аларга. Ә Зөһрә апа – кергән.

– Әнием төрмәдән кайткач, үз эченә бикләнебрәк яшәде, күп нәрсәләрне сөйләмәскә тырышты, белеме буенча эшкә дә урнаша алмады. Безнең янда сәясәт турында ялгыш бер сүз әйтү юк. Бик якын дуслары белән генә аралаша иде. Элегрәк ул дуслыкка бәя биреп бетерә алмаганмын, ахры. Дуслары Гөлчирә апа Гафурова (“Азат хатын” журналы редакторы), Хәрирә апа Биктаһирова (Гомәр Гали хатыны), Мөхтәрәмә апа Рәхмәтуллина (пединститутның

элеккеге укытучысы) – барысы да әнием кебек хәсрәт дәрьясын кичкән кешеләр булган. Ирен, биш баласын югалткан Зәйнәп апа Хәсәни дә әниемнең дусты иде.

Чәчкә апа башта сеңлесе Гөлкәйне, соңрак энесе Вилне дә соңгы юлга озатты. Гөлкәй бигрәк кыска гомерле була – улы Алик әнисеннән дүрт кенә яшьлек булып кала. Аны үз баласы кебек күреп, Чәчкә апа үстерде һәм ни кызганыч, соңгы юлга да озатты.

Әнисенә бирелгән кечкенә генә фатирда яшәде Чәчкә апа. Аллага шөкер, зиһененә, акылына күз тимәсен: укучыларга математика серләрен өйрәтте, имтиханнарга әзерләде. Илдәге, дөньядагы хәлләр белән танышып бара иде, үткәннәрнең кабатланмавын теләп яшәде. Элекке студентлары белән дә аралашып торды. Районнардан гына түгел, Владивосток, Рязань кебек ерак шәһәрләрдән дә хатлар, тәбрикләүләр җибәрәләр иде Чәчкә Сәлах кызына. Казанга килеп чыксалар, янына күрешергә керми калмыйлар иде. Педагог өчен бик зур шатлык бит бу.

Бүгенге яшьләр татарның никадәр талантлы шәхесләре булганын белсен һәм алар кичергән авырлыкларның сәбәбен йөрәкләре белән аңласын иде…

# АЛАР – МӘРҖАНИНЕКЕЛӘР

*Шиһабетдин Мәрҗани бер иде. Кадерен, кыйммәтен белмәк аның өчен түгел, безләр өчен ифтиһардыр.*

*Исмәгыйль Гаспралы*

Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани – татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер тарихында күренекле галим, фикер һәм акыл иясе. Аның исемен әйткәндә үк күңел ничектер олы хөрмәт хисе, чиксез горурлык белән тула. Аллага шөкер, бу олы шәхесебез хакында фәнни хезмәтләр языла, иҗатына багышланган конференцияләр үткәрелә, исеме дә шулай югалмас әле дип ышаныйк, чөнки күңелендә иман нуры сүнмәгән һәр мөселман, һәр татар өчен бу шәхеснең исеме якын, изгедер дип уйлыйк. Ул яшәгән йорт та кайчандыр төзәтелер (тышкы ягы гына түгел), шәһәребездә үзәкләштерелгән якты бер истәлек музее да ачылыр әле дип өметләник. Бөек галимебезгә һәйкәл куелачак икән дигән хәбәргә дә күтәрелеш елларында күпме сөенгән идек. Шәһәр җитәкчеләре һәйкәлгә нигез ташлары салганда бик тә ышандырып сөйләгән иделәр ич. Якын туганнары, буыннары куанычын сөйләп тә бетерерлек түгел иде. Менә шул өметле куанычлар эчендә, бергә булган газиз дусларым, “Мәрҗанинекеләр” дигән исемне горур йөрткәннәр хакында язасым килде. Алар – турыдан-туры Мәрҗани оныкларының кызлары: Суфия, Наҗия, Галия, Оркыя апалар. Төрле яклап кыерсытылган, изелгән, кешелек хокукларын югалткан хәлдә гомер кичергән туган халкымның матур бер өлеше бу кызлар. Яшьлек еллары – белемле, иманлы кешеләрнең, ягъни мәгърифәтчеләре безнең, имамнарыбызның, остазларыбызның меңәрләп үтерелгән заман туры килгән. Әмма бу нәсел кешеләре намус – вөҗданнарына хилафлык китерерлек гамәлләрдән сак булырга тырышкан затлар. Алар өчен халык, милләт дигән төшенчәләр изге булгандыр диясем килә.

Белгәнебезчә, Шиһабетдин хәзрәт, кече кызы Һаваны, үзе хөрмәт иткән, илаһият галиме булып танылып килгән Габдулла хәзрәт Апанаевка үзе димләп бирә. Аларның никахыннан Гайшә, Оркыя, Фатыйма, Яхъя, Идрис, Әминә, Зәйнәп, Әюп исемле балалар туган.

Бу балаларның тормышлары хакында бераз язылды инде. Алар, шөкер, барысы да ата-ананың йөзенә, исеменә тап төшерми яшәгән, әмма, әйтеп үткәнебезчә, гаделсез заманның кырыслыгын татып дөньядан киткән затлар.

Балаларның өченчесе Фатыйма апаның кызы Галия ханым белән матур гына аралашырга, дуслашырга туры килде. Фатыйма апа гомеренең соңгы елларын Галиясе тәрбиясендә үткәрде. Яшьлегендә (1915 елда) Верный (Алма-Ата) шәһәрендә яшәгән татар бае Исхак Габделвәлиевнең улы, югары белемле егет Котдуска кияүгә чыккан. Октябрьдән соң совет властена туры килмәгән сыйныф вәкилләре буларак, күргән михнәтләре үзе бер китап. Әмма гыйлемгә мәхәббәт сүнмәгән аларда. Балаларына ничек тә булса югары белем бирергә тырышканнар.

Уллары Фоат – ветврач. Ашхабад авыл хуҗалыгы институтын бетергән. Кызларның берсе Асия – Ивановода химия-технология институтын тәмамлаган, химия фәннәре кандидаты дигән мактаулы дәрәҗә иясе булган. Икенче кызлары – әле искә алган Галия, белемне Ленинградта алган. Казан институтларында укырга рөхсәт итмәгәннәр. Ветеринария фәннәре кандидаты иде. Белгечлеге буенча микробиолог. Тагын бер уллары Фатыйх – Фрунзе педагогия институтын тәмамлаган. Тарихчы галим. Хәзер барысы да мәрхүмнәр инде.

Миңа Галия апа белән генә аралашып йөрергә насыйп булды. Чын мәгънәсендә зыялы – зәвыклы кеше иде. Аның белән ешрак күрешә, сөйләшә алмавыбыз бик кызганыч. Бер шәһәрдә булсак та яшәгән урыннарыбыз, араларыбыз ерак иде шул. Ул гаиләсе белән Дәрвишләр бистәсеннән дә арырак “Научный городок” дигән җирдә яшәде. Бергә гомер иткәндә теләсәң дә, һаман-һаман очрашып торып булмый бит. Мин эшли идем әле, Галия апа оныкларын үстереште. Аерылырбыз, сагынырбыз дип тә уйланылмады микән. Ешрак очрашырга, үткән тарихыбыз хакында күбрәк сөйләшергә кирәк булган икән. Галия апаның әтисе Котдус абый Чыңгыз Айтма-

товның әнисе Нәгыймә апа белән ике туган да булганнар әле. Күпме истәлекләр дә сөйләнми калган. Үкенеч. Истәлегем дога булып барсын.

Оркыя апа – Хава ханымның алтынчы баласы Әминәдән туган кыз. Әминә апа үзе заманында Казан университетының юридик факультетын тәмамлаган юрист, “Хокук вә хәят” журналының нашире һәм мөхәррире, Октябрьдән соң репрессиягә дучар булган Шәехгаттар Хәсән улы Иманаевның хатыны булган. Кызлары Оркыя апа шушы никахтан туган бала. Ул озак еллар Казан университетында эшләгән галимә. География фәннәре кандидаты. Без танышканда сәламәтлеге бик әйбәт түгел иде инде. Очрашканда фәндәге табышлары, гомер юлы хакында тыйнак кына искә ала. Әмма Мәрҗани хакында сөйләшкәндә чиксез горурланып, яратып сөйли иде.

Мәрҗанинең оныгы Нәгыймә апаның кызы Наҗия апа искиткеч зыялы шәхес иде. Нәгыймә апа үзе яшьлегендә 1903–1907 елларда Каһирәдәге Әл-Әзһәр университетын тәмамлаган Таһир Әхмәтҗан улы Ильясига кияүгә чыккан. Никахларын Мәрҗани үзе укыган. Таһир Ильяси “Хөсәения” “Мөхәммәдия” мәдрәсәләрендә гарәп теле укытучысы, 1916 елдан “Хөсәения”нең директоры, “Мәрҗани” мәчетенең имамы (1922–1925) булган. Татарстанда ачлык башлангач, татар халкына ярдәм оештыру максатыннан Төркиягә барган. Сәфәре уңышлы булган. Бу хакта “Ил язмышын салып иңнәренә” дигән китабымда язган идем. Ни кызганыч, ул да репрессия корбаны.

Наҗия апа әтисенең иң матур сыйфатларын үзенә сендергән гаҗәеп ханым буларак хәтеремдә калды. Казан университетын тәмамлаган, белеме буенча математик, астрономия фәненнән дә киң мәгълүматлы белгеч иде. Соңлап кына олуг әдибебез Әмирхан Еники белән никахлашып, аны тәрбияләп соңгы юлга озатты. Аш-суга оста иде. Борыңгы ысуллар белән нинди генә тәмле ашлар хәзерләмәде икән. Шулкадәр матур төгәллеге, үзенә һәм башкаларга таләпчәнлеге белән дә аерылып торды.

Язмышымның алар белән үткәргән көннәремә рәхмәтле. Шулай дүрт кыз – Суфия апа (араларында иң олылары), Галия, Оркыя, Наҗия апалар үзләре җыелышканда мине дә чакыралар иде. Никләр генә хәтеремә ышандым, никләр генә алардан ишеткәннәремне язып

бармадым икән дип үкенәм. Алар сөйләшкәндә күз алдына җанлы тарих килеп баскан кебек була иде. Шунысы да сокландыра иде әле, күпме генә гаделсезлекләрне күрсәләр дә, рәнҗешле сүзләр ишетмәдем алардан. Сорашсам да, “шулай инде, бер без генә түгел иде бит”, – дип куялар, тагын тормыш юлларында очраган шәхесләрне санынып искә алалар иде.

Алардагы тагын бер матур сыйфатны хөрмәт белән искә алам. Берсе авырса, шунда ук барлык эш-гамәлләрен ташлап авыруның хәлен белергә, ярдәм итәргә җыелалар, киңәшләшәләр иде. Әнә бит, Нәҗия апаның да авырган вакытында соңгы көннәренә кадәр янында туганы Суфия апа булды.



*Шиһабетдин бине Баһаветдин әл-Мәрҗани оныкларының балалары. Сулдан уңга: утырганнар – Суфия Мостафина, Галия Габделвәлиева. Басканнар – Нәҗия Ильясова, Оркыя Иманаева*

Суфия апа Хава ханымның кече кызы Гайшәдән туган. Әтисе Абдулла ага Мостафин Салихҗан хәзрәт Баруди шәкерте булган. Соңрак атаклы Акчуриннарның Гурьевкадагы фабрикасында инженер механик булып эшләгән. Алар хакында да язганым булганга,

тормышларын тәфсилләп язып тормыйм. Тик Суфия апаның 87 яшенә кадәр эшләп йөргәнен, акылының шулкадәр төзек, үзенең гаять хәрәкәтчән, эшсез тик йөрүне бер дә яратмаган гүзәл бер ханым икәнен әйтми мөмкин түгел. Аллага шөкер, мине үзенең якын дусларының берсе итеп санады.

Казан авиация институтында укытып йөргән вакытта таныштык. Ул үзе дә КАИ студенткасы булган. 4 курста производство практикасы үтәр өчен анкета тутырганда бабаларының Мәрҗани, Апанаевлар булганлыгы ачыкланган һәм институттан куылган. Кулына диплом ала алмаганына эче поша, кимсенә иде.

Мин аның һәр фәннән мәгълүматлы булуына гаҗәпләнә идем. Илдә барган вакыйгаларга да үз бәясе, үз фикере бар иде. Аның хакында да “Ил язмышын салып иңнәренә” дигән китабымда язган идем. Тик тагын бер матур сыйфаты хакында гына аерып әйтәсем килә. Ул борынгыдан килгән риваятьләрне, мәкальләрне искиткеч күп белә иде. Аның миңа сөйләгән бер риваятен укучыларга да тәкъдим итәм:

– Борын заманда бер ташчы егет яшәгән. Шулай бер өйнең нигезен салганда, җир казый башласа, бер сандык таба бу. Алып карый. Хәйран гына авыр сандык. Шыпырт кына өенә алып кайта да, ача сандыкны. Тик алтын-көмеш дип өметләнеп ачкан сандык эчендә бер кәгазьдән башка берни дә булмый. Кәгазь битендә ике чәчәк ясалган була. Бер чәчәктән елан угы итеп ясалган ук чыгып тора икән. Икенче чәчәк өстендә (бу баллы чәчәк булган күрәсен) умарта корты ясалган.

Егет уйга калган. Нишләп елан агуы белән умарта корты ясалган икән дип. Дусларыннан сораган – белмәгәннәр. Олылардан сораган – әйтә алмаганнар. Бары бер карт әйткән: “Бездән ерактагы тау буенда бер авыл бар. Шунда бик олы яшьтәге карт белән карчык яши. Бик күп белә торган кеше дип әйтәләр картны. Шуңа барып кара”.

Егет киткән кәгазьне алып. Барган авылга, тапкан, исәнләшеп кергән картларның өйләренә. Болар бик нык бетәшкән, йончыган картлар икән. Карт кәгазьне алып бик озак уйлаган, әмма берничек тә аңлатып бирә алмаган. “Син, егет, мине олылап килгәнсең, –

дигән ул. – Тик мин бу табышмакны чишә алмыйм. Минем күрше авылда абыем бар, әйтсә ул әйтер”, – дигән.

Күрше генә дип әйтсә дә, авыл арасы шактый ерак булып чыккан. Әмма егет киткән, беләсе килә бит инде. Картның авылын, өен эзләп тапкан. Капкадан керсә, өй алдында бер бик чибәр хатын утырып тора икән. Хатынның буенда да бар, бала көткәнлеге, бик бәхетле хатын булганын бөтен кыяфәте әйтеп тора икән.

Егетне ул ачык йөз белән каршылаган. Йомышын әйткән егеткә ул: “Ай, бераз көтәргә туры килер инде. Чөнки хуҗам ял итәргә ятты, үзе тормыйча уятмыйм, йокысын бүлмим инде”, – дигән. Егеткә хәйран озак көтәргә туры килгән.

Ярар, хуҗа уянган. Хатынына егетне алып керергә кушкан. Егетнең исе киткән. Каршыда бер бик чибәр, гайрәтле кеше утырып тора икән. “Бу, чыннан да теге бабайның өлкән абыйсы микән соң? – дип бик гаҗәпләнгән егет.

Егет үз йомышын әйтеп кәгазьне күрсәткән. Хуҗа әйткән: “И, моны мин сиңа бик җиңел аңлатып бирәм. Тик менә син юлдан килгән кеше, ашап-эчеп алыйк. Башта ризыгымнан авыз ит”, – дигән. Ашап бетергәч, хуҗа хатынына әйткән. – Бар, икенче катка мен дә, карбыз алып төш, кунак безнең карбызны да авыз итсен, – дигән. Хатын йөкле булса да, бер дә карышмыйча менеп киткән. Карбызны алып төшкән. Ире: “Нишләп бу өлгермәгән карбызны алып төштең, бар әле әйбәтен алып төш”, – дип өч мәртәбә яңадан кире меңгергән хатынын. Хатыны чыраен да сытмыйча, карбызның берсен алып менеп, икенчесен алып төшеп торган.

Өченчесен ошаткан хуҗа, карбызны бергәләп ашаганнар. Шуннан соң кәгазьгә карап ир сөйли башлаган:

– Монда, әллә ни чишелмәс табышмак юк. Бер чәчәктә елан агуы ясалган. Чәчәкне ясаучы кешенең, кызганыч, хатыныннан бәхете булмаган икән. Менә кара бу чәчәккә. Анда әгәр хатының акыллы, уңган, тәмле телле булса, үзең дә бал корты кебек эшләсәң, тормышыңда юклык күрмәссең, күңелен тыныч, ризыгын тәмле булыр. Әгәр хатынның авызыннан агу чәчсә, үзең дә еланга әйләнерсең, тормышың кара, ризыгың агу булыр дигән фикер ята.

Егетнең исе киткән. Гаҗәпләнмә, – дигән ир. – Син бит күрдең минем энемне. Хатыны бик зәһәр, гайбәтче булды, эш яратмады. Шуңа күрә бик бәхетсез булдылар, бик иртә картайдылар.

Ә менә мине, минем хатынымны күреп торасың. Минем хатынымның холкын да күрдең. Өч мәртәбә карбызга менде ул, бер каршы сүз әйтмәде. Ә өске катта безнең карбызыбыз берәү генә иде. Ул шулай, бер карышмыйча менеп, кеше алдында миңа үзенең олы хөрмәтен күрсәтте. Син дә безнең тормышыбыз әйбәт, җитеш, карбызларыбыз күп дип уйладың. Тартынмыйча ашадың. Менә минем хатыным шул матур холкы аркасында гел картаймый, яшь, матур көе тора. Безнең кечкенә генә куанычыбыз да олы шатлыкка әйләнә. Мин үзем дә аны бик хөрмәт итәм. Аның тормышын җиңеләйтер өчен көчемне дә, иркәләвемне дә кызганмыйм. Аның шатлыгы – минем шатлык. Шуңа күрә ул миңа ул яки кыз бүләк итәргә йөри әле, – дигән.

Егет шунда уңган, зирәк хатынның тормышта ире өчен кем булганын аңлаган.

Суфия апа мондый гыйбрәтле риваятьләрне күп белә иде. 2005 елның 10 маенда безнең белән саубуллашып бакыйлыкка күчте. Барыбыз да өзелеп сагынабыз аны. Хәтер көнендә Ирек мәйданына чыгып басып тора, “бер кеше булса да кеше саны булсын дип чыгам”, – дия иде. Өзелеп сагынуларыбыз рухына шатлык булсын.

## УКЫТУЧЫ ДУСТЫМ, АЙ, ХАЛИСӘ!

*Саумы, яшьлек!*
*Өлкән җырларымның,*
*Хыял-уй-хисләрем яшьлеге!*
*Меңе мең язмышка карап киткән,*
*Яшьтәш, дус-ишләрем яшьлеге!*
*Илдар Юзеев*

Еш кына миннән “Ник үзеңнең яшьлек дусларың хакында язмыйсың? – дип сорыйлар. Җавабымда “мин язучы түгел бит”, – дим. Ә ныклап уйласам, үземнең дус-ишләрем арасында да гыйбрәтле язмышлылары күп икән. Әмма үземне гомер буе кылган гамәлләре, ихлас күңеле, әдәп-әхлаклы тормышы белән сокландырганы, иң якыны – дустым Халисә икән.

Кукмара районының Күкшел авылы кызы ул. 1961/62 уку елында Казан дәүләт педагогия институтының тарих факультеты татар теле, әдәбияты һәм тарих бүлегендә укый башлагач таныштык аның белән. Бу танышлык еллар үткәч чын, матур дуслыкка әйләнде, Аллага шөкер. Бердәнбер балам – Айратымның фаҗигале үлеме көннәрендә чын туганым кебек янымда торып, кайгыларымны уртаклашып яшәде. Мин үтенеп сораганга түгел, ишетү белән үзе килде. Бу якынлыкны ничек итеп бәһаләп бетерергә мөмкин?

Группабызда барыбыз да авылдан килүчеләр: яртылашы эшләп, яртысы мәктәпне әле генә тәмамлаучылар иде. Кураторыбыз Мәдинә Шәйхи кызы Җәләлиева кандидатлык диссертациясе якларга хәзерләнеп йөргән вакыты булганга, дилбегә безнең кулда булды. Һәр чараны үзебез оештырдык, үзебез, ягъни эштән укуга күчүчеләр, башлап йөрүчеләр. Авыр еллар, матди хәлебезнең кыенлыклары сәбәпле үзәккә үткән көннәре күп булды. Әмма нәкъ шул студент булып, яшь булып, янып йөргән чаклар сагындыра. Авырлыклар әллә булган, әллә булмаган, алары искә алынмый икән.

Үткән балалык еллары да кайсыбызның җиңел булды соң ул заманда. 1939 елда туган Халисәнең әтисе Мөхәммәтнәҗип абый

сугыш башлану белән, хатынына 3 баланы тапшырып, фронтка китә. Исән кала, шөкер. Сугыш беткәч, Мәскәүдә Третьяковның сәнгать галереясын ремонтлауда катнаша. Авыл кешесенә, татар кешесенә хас булган тырышлыгы белән сокландырган ул андагы җитәкчеләрне. Мәскәүдә калырга, хәтта гаилә белән торырлык фатир бирергә вәгъдә итеп, китмәскә үгетләгәннәр аны. Тик туган туфракның тарту көче көчле булган. Нәҗип абый авылына кайткан.



*Халисәнең Сонгарда эшләгән вакыты. 1977 ел*

Сугыштан соңгы авыл халкы күргән җәфаларны язып торырга кирәк микән? Күрдек, исән калдык, үткән елларыбыз битебезгә кызыллык китерерлек булмады, бер Аллаһы Тәгаләбезгә шөкер.

1946 елда Халисә Күкшел мәктәбенә укырга керә. 7 нче сыйныфны тәмамлаган елны авылга Казаннан кирпеч заводына эшкә барырга өндәүче (вербовщик) килә. Әле 15 яшенә генә чыккан кыз бала ялына-ялына шул авыр эштә эшләргә алуларын сорый. Яшенә 1 ел өстәп яза вербовщик.

Әмма ул елларда төзелешләр күп түгел, кирпеч заводы җәй көне генә эшли, кышларын Халисәгә яңадан авылга кайтып фермада эшләп йөрергә туры килә. Соңрак ферма Казанның яшелчә саклау базалары белән алмашына. Тагын да соңрак автобуста кондуктор булып (кулга 5 еллык паспорт алу бәхетенә ирешкәч) эшләргә туры килә.

Ниһаять, күптәнге хыялы – укытучы буласы килү теләге Халисәне институтка китерә дә инде. Ә укытучы булу теләге әнисе – Зөләйха апа Әлмөхәммәт кызы үрнәгендә тугандыр дип уйлыйм. Бу гаҗәеп язмышлы ханымның тормыш юлына тукталыйм әле.

Ул Троицк шәһәрендә туа. Атаклы татар сәүдәгәрләре Яушевларның килене Гайния ханым ачкан дарелмөгаллиматтә (мөгал-

лимәләр хәзерли торган уку йорты) белем ала. Бу югары уку йортында мөдирә булып репрессиягә эләгеп атылып үтерелгәнгә (1937 елда) кадәр, атаклы Мөхлисә ханым Буби укыта. Кызлар дини һәм дөньяви фәннәрне бик тирәнтен өйрәнәләр биредә.

Гайния ханым Октябрьдән соң чит илгә китеп өлгерә. Әйтеп үтим, 1920–21 еллардагы ачлык вакытында Татарстан мөгаллимнәренә азык-төлек посылкалары җибәрергә дә үз малыннан өлеш чыгарырга мөмкинлек тапкан ул. Урыны җәннәттә булсын, үрнәк булырлык сыйфатлары соклангыч бит.

1930 елларда Яушевларның илдә калганнарын талаулар, кулга алулар башлана. Ул фамилиядәге кешеләрне генә түгел, алар белән хезмәттәшлек иткәннәрне дә төрмәгә утыртулар, эзәрлекләүләр бик ешаеп китә. Зөләйха ханымның эти-әниләре дә Күкшелгә, ата-бабалары туфрагына кайтырга мәҗбүр булалар.

Зөләйха балалар укыта башлый. Атаклы уку йортын тәмамлаган яшь белгечкә укыту авыр булмый. Балалар да, өлкәннәр дә үз итәләр, яраталар аны. Башлангыч мәктәп укытучысына ярдәм сорап, еш кына башка, өлкән сыйныфларда укыганнар да килә. Барысына да булыша яшь укытучы. Озакламый авыл егете Мөхәммәтнәҗип белән матур гына гаилә дә коралар, бәхетле булган кебек кыз бала. Тик кайсы илдә яшәгәнебезне генә онытмыйк, бигрәк тә без татарлар өчен бәхет озак юлдаш түгел бу илдә. Зөләйхага да шулай. Әтиләренә кунакка килгәч, намаз укыганын күрәләр аның. Тиешле җиргә хәбәр барып ирешә, талантлы укытучыга мәктәп белән саубуллашырга туры килә. Бу гаделсезлектән, укучыларын сагынудан йөрәккәйләре сызлаган вакытлары булгандыр аның. Балалары да әниләренең фаҗигасен аңлаганнардыр, шуңа да әниләре яраткан хезмәткә үзләрен багышларга уйлаганнардыр дип уйлыйм. Чөнки Халисә белән бер вакытта ук диярлек, сеңлесе Миңсылу да пединститутта укый башлаган иде. Шөкер, аңа намуслы хезмәт итеп, зур дәрәҗәләргә ирешеп, пенсиягә киткәнче балалар укытырга насыйп булды.

Халисә ике ел гына укыды безнең белән. Ул укырга кергән елны этисе үлеп киткән иде. Гаиләдә өлкән бала булып калды, өлкән бала өстенә төшкән вазыйфаны аңлап, читтән торып уку бүлегенә күчте. Чөнки әнисе кулында берсеннән-берсе кечкенә (сугыштан

соң туган) энеләре, сеңелләре бар, аларны үстерешергә ярдәм кирәк иде әле. Шулай итеп, кичәге студентка үз авылларыннан ерак түгел Борбаш мәктәбендә рус теле укытырга туры килә.

Тик, кыз баланың шәхси тормышы да бар бит әле. Шулай эшли генә башлагач, Якут республикасында шахтер булып эшләп йөргән сабакташы, яшьлек дусты Вилсур Мәрдәнов суларга да ирек бирмичә алып китә аны. "Сигез ел көткәнем аз түгел бит инде, Халисә", – ди ул аңа. Аллага шөкер, матур гына гаилә корыла. Ә Халисәгә Якутск университетына күчүдән башка чара калмый. Бер килсә килә бит, монда да читтән торып укырга туры килә. Чөнки бик матур игезәк балалары туа, аларны тәрбиялисе бар.

Университетны тәмамлагач, үзләре торган Сангар дигән шахтерлар шәһәрчегендә 20 ел тарих укыта минем дустым. 20 ел рус телендә. Хәзер ана телендә укытмыйча, рус телендә генә белем алып, балаларын "әлләкем" итәргә хыялланган ата-аналарга әйтер идем. "Без дә бар бит әле, әнә Халисә – авыл кызы, татар кызы, рус телендә балалар укытты. Ничек кенә укытты әле. Ирешелгән уңышлары өчен алган дәрәҗәле исемнәрен, СССР Мәгариф министрлыгыннан алган рәхмәт хатларын, үзе риза булмаганга гына санап язып чыга алмадым. Мактанудан булмасын, Татар теле бүлеген тәмамлап чыгып, утыз елга якын Казан авиация институтында партия тарихын укыттым, Аллага шөкер. Нинди генә студентлар иде әле! Гомеремнең иң матур, канатланып, үз һөнәремне яратып эшләгән вакытым – шушы институтта эшләгән чорым иде. Кыен булды, әмма ул рәхәт кыенлык иде. Шуңа да аңлыйм дустымның хәлен, тырышлыгына, ирешкән уңышларына сөенәм.

Кешене ашар ризыгы йөртә ди халык мәкале. Тормышлар шулай матур гына барганда Сангардан яшь калага – Нюренгерига күчәргә туры килә аларга. Сәбәбе дә кызык кына: Якутиянең куе урманы эчендә татар кызы, геолог Саимә Кәримова кокска бай күмер ятмалары таба. Аның тырышлыгы белән шахталар эшли башлый, шәһәр төзелә. Яшь, алдынгы шахтерларны шул яңа күтәрелеп чыгып килгән яшьләр шәһәренә чакыралар. Вилсурның барасы килгәч, Халисә дә каршы килми. Торырга уңайлы, матур фатирлар да әзерләнеп куелган була. "Килгәч, шәһәр тарихын өйрәнгәндә, үз халкым өчен чын күңелдән горурландым. Чөнки

тайга уртасында салынган, гаҗәп матур уңайлыклары булган шәһәр диварында

*Не каждому дано, так щедро жить,*
*На память людям города дарить! –*

дип язылган иде. Бу сүзләрне нәкъ менә Саймә ханымга атап язылган дип кабул иттек”, – ди Халисә. Шәһәрдә яшәүчеләр дә Саимә Кәримова исемен матур итеп, җылы итеп искә алганнар икән.

8 ел бередә дә шәһәр мәктәбендә тарих укыта татар кызы. Тик матур гына яшәп ятканда тагын үзгәрешләр, борылышлар чыгып куя. СССР таркала. Вилсур вафат була. Уллары Рафаил Новосибирскида хәрби училище тәмамлагач, Чечняга җибәрелә. Бу вакытта Кизлярда котычкыч сугышлар барган вакыт. Бер срокка җибәрелгәннәргә алмаш килми, тагын калдыралар. Кызы – Земфирасы Улан-Удэда Азык-төлек институтын бетереп, Ленинград өлкәсендәге Приозерск шәһәренә эшкә җибәрелгән була. Ул анда уңышлы гына эшләп китә. Кияүгә чыга. “Эше дә, акчасы да, Аллага шөкер”, – ди дустым.

1992 елда сеңлесе Миңсылу туган якка кайтырга чакыра Халисәне. Кайта, булган бөтен тормыш шулай таркала. Өр-яңадан тормышын кора ул. Биектау районы Усад авыл хуҗалыгы механизаторлар училищесының тулай торагында тәрбияче булып эшкә урнаша.

Рафаил Чечнядан исән-сау кайткач, Мәскәүдәге Фрунзе исемендәге Хәрби Академияне тәмамлый. Тольятти шәһәрендә эшли, хәзер Биектауда. Нинди генә дәрәҗәләр, эш урыннары тәкъдим итсәләр дә, Татарстаннан еракка китәсе килми аның. Әнисе аның эшеннән дә, тормышыннан да канәгать. Гел янына килеп, әнисенә гел ярдәм итеп тора ул бала. Рәхмәт яусын.

Һәм тагын тормышындагы бер үзгәрешен язмый кала алмыйм икән дустымның. Кайту белән Казандагы Мәрҗани мәчете мәдрәсәсенә укырга керде ул. Мәдрәсә ремонтка ябылгач, Нурулла мәчете мәдрәсәсендә 2 ел укып дин белеме алды. Хәзер Усадта авылдашларына үзе дин дәресләре бирә. Коръән укыганда, сокланмаган кеше юк үзенә. Ни куаныч (куанычыбыз гомерлек булсын), бүген якын дустыбыз балаларының, оныкларының, туганнарының, авыл-

дашларының олы хөрмәте эчендә. Аллаһе Тәгаләбез үзенә дә халкыбызга игелек күрсәтеп яшәргә язсын әле.

Халисәнең зәңгәр күзләреннән әз генә көнләшеп, сокланып йөргәнем хәтеремдә. Шуңа күрә сүземне күренекле шагыйребез Гали Хуҗи сүзләре белән танылган "Халисә" җырын искә төшереп, үземчә тәмамлыйм.

*Чәчәкләрнең матур зәңгәрләрен*
*Хәтерләтә синең күзләрен…*
*Сокланабыз, дустым, хәзер дә әле*
*Яшьлегебез кебек гүзәл син!*

# ТАТАРСТАНДА АЧЛЫК ФАҖИГАСЕ

*Шатлыкларны хәсрәт алыштырган,*
*Булалмаган гел-гел шат кала.*
*Узган дәверләрнең фаҗигасе*
*Изге ташларыңда саклана.*

*И.Юзеев*

Татарстан автономияле республикасы төзелү белән үк, аның өстенә төшкән бәла-казаларның иң дәһшәтлесе, мөгаен, 1920 елда башланган ачлык булгандыр. Бу ачлык афәте хакында тарихыбызда, әдәбиятыбызда бераз язылды инде, халкыбызның буыннан-буынга күчкән истәлекләре дә саклана әле. Чөнки ул – бөтен халык хәсрәте, аны онытып мөмкин түгел һәм онытырга хакыбыз да юк. Әмма ачлыкның чын сәбәбен 1921 елда булган корылыкка, иген уңмауга гына сылтап калдыру һич тә дөреслеккә туры килми. Тарихчы галимнәребезнең биргән бәяләре башкача һәм аны белү безнең генә түгел, киләчәк буыннар өчен дә зарур[1]. Бу мәкаләне язырга алынуымның төп сәбәбе дә әнә шул зарурлыкны күбрәк кешегә белдерәсем килүдән килеп чыкты.

Ачлык ни сәбәптән башланган һәм шундый коточкыч дәрәҗәдә таралган соң? 1921–1924 елларда ТАССРның Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы рәисе булып эшләгән Рәүф Әхмәтсабир улы Сабиров (1894–1937) үзенең “Татарстан җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык” дигән мәкаләсендә болай дип яза: “Ачлыкның башлыча сәбәпләре ашлык уңмау, йогышлы авыру һәм сугышлар икәнлегендә шөбһә юк. Шулай ук мәмләкәтнең бәгъзе бер икътисади шартлары, халыкның фәкыйрьлеге, мәдәният ягыннан артта булуы, юлда нәрсә йөртү әсбапларының җитешсезлеге һ.б. төрле

[1] Таһиров И.Р. Гасырлар чатында. Казан: Мастер-Лайн, 1998. 236–245 б.; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. С.177–188; Вәлиев Р. Өзелгән дога. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 23–30 б.; Әхмәтҗанов М. Ачлык фаҗигасе // Мәгариф. 2012. №2. 82–83 б.

күп кенә сәбәпләр хуҗалык эшләрен зәгыйфьләндереп, ачлыкның тизрәк килүенә ярдәм иттеләр”[2].

Хак сүзләр. Ачлык ул – фәкыйрьлекнең аерылмас юлдашы. Ә халыкны фәкыйрьлеккә дучар иткән сәбәпнең нигезендә рус хакимиятенең татар халкына карата гасырлар буе алып барган рәхимсез сәясәте ята. Ул хакта да ачыктан-ачык әйтә алган Рәүф Сабиров. “Әгәр дә без халкыбызның тарихын тикшереп карасак, татарларның искедән бирле зур бер кысынкылык астында яшәп килгәнлекләрен күрәбез. Иван Грозный тарафыннан Казан алыну белән татарлар үзләренең өсләрендә инде кысынкылыкның башланганын сизделәр. Идел, Кама буйларындагы әлегә кадәр биләп килгән мөнбит (уңдырышлы) җирләрен татарлар урысларның тәзаййыкы (кысуы) астында ташлап китәргә мәҗбүр булдылар. Җүнсез һәм уңайсыз җир кайда бар – татарлар шунда утыртылды. Билгеле, бу хәл үзе генә татарларның икъдисади яктан начарлануына сәбәп булды”[3].

Ни кызганыч, бу сәясәт, бу кысулар һаман тагын да нечкәрәк, тагын да мәкерлерәк юллар белән дәвам итә.

Мисал өчен: “1861 ел Нигезләмәсе” буенча, Казан губернасында рус крестьяннары крепостнойлыктан азат ителгән вакытта, ревизия үткән һәр җан башына (на ревизскую душу) уртача 3–4 десятинә җир алалар. Шул ук вакытта дәүләт крестьяннарына җан башына бирелгән җир мәйданы уртача 5,23 десятинә тәшкил итә. Ә татар крестьяннарының иманасы ревизия үткән һәр җан башына 1 десятинә генә була. Моның өстәвенә, татар авылларында атлар саны азлыгын да күрсәтергә кирәк. 1884–1891 елларда ук татарның 34,8 проценты атсыз, 46,2 проценты бер атлы һәм бары тик 14,8 проценты гына ике атлы була[4]. Шуның аркасында сөрүлек җир мәйданнарының күләме азая һәм икмәк тә җитәрлек булмый. Өстәвенә, татарларның урман, олы юл һәм елга буйларыннан куылуын, яшелчә һәм җимеш бакчалары үстерергә хокуклары булмавын, тереклек

[2] Безнең юл. 1922. №1. 21 б.

[3] Шунда ук. 22 б.

[4] Таһиров И.Р. Юныс Вәлиди: “Игенчеләргә ярдәм итеп, аларны эшлекле хуҗалар дәрәҗәләренә җиткерүне онытмаска кирәк” // Гасырлар авазы–Эхо веков. 1996. №1/2. 75–76 б.

итәр өчен уңайсыз урыннарга төпләнергә мәҗбүр булуларын да искә төшерик.

Җирсезлектән тилмергән крестьяннарның тормыш-көнкүрешен төрле-төрле салымнар да кыен хәлгә куя. Салымнарның түләнми калган өлеше – недоимкалар елдан-ел үсә. Аларны түли алмаганнарның терлеген, барлы-юклы игенен, актык мендәрен, самоварын тартып алалар. “Карьямездә ачлык көннән-көн көч алмакта, – дип яза “Казан мөхбире”, – бала-чага, хатын-кыз ач тамак, ялан өс, суык өйдә калтырап, туңып утыралар… Өстәвенә, бу бичара ач крестьяннардан һәр көн имана сорыйлар”[5].

Ач-ялангач калган мескен крестьян, иманасын ташлап, шәһәргә эш эзләп китәргә мәҗбүр була. Казан губернасындагы авыллардан эш эзләп читкә китүчеләр саны 1899 елда ук 154185 кә җиткән. “Авылларда барча ирләр диярлек Баку, Мәскәү, Идел буйларына хезмәт эзләп таралганнар. Авылда күбесенчә хатыннар калып, кыр эшләренең барысын башкаралар”, -дип яза “Әл-ислах”газетасы[6].

1914 елда башланган империалистик сугыш хезмәт кешесен тәмам бөлгенлеккә төшерә. Шушы ел эчендә генә дә Казан губернасында дүрт тапкыр мобилизация үткәрелә һәм барлык хуҗалык эшләре хатын-кызлар һәм яшүсмерләр кулында кала. Бу сугышка ялганып киткән Гражданнар сугышы татар халкын, аеруча татар авылларын аяктан ега. Чәчү мәйданнары тагын да кими, терлекләр саны бик нык кыскара.

Дөрес, халык хуҗалыгының шулай бөлгенлеккә төшүе Россиядә бер Казан губернасына гына хас күренеш түгел. Сугыш аркасында бушап калган иген кырлары, җимерелгән завод-фабрикалар, шахталар, тимер юллар, ягулык һәм сәнәгать өчен чимал җитешмәү Россиядә яшәүче халыкларның хәлен чиктән тыш авырайта, бигрәк тә азык-төлек мәсьәләсе кискенләшә. Җитештерелгән ашлыкны “бүлешүчеләр” дә күбәя. Образлы итеп әйткәндә, нәкъ “Чапаев” кинофильмындагы кебек: “Белые пришли грабят, красные тоже начали грабить”. Инде мәгълүм булганча, ВЦИК (БҮБК)ның 1918 елның 13 маенда кабул ителгән декреты нигезендә авылларга икмәк җыю өчен продотрядлар җибәрелә. Ә 1919 елдан продразверстка планы

[5] Казан мөхбире. 1906. №106.
[6] Әл-ислах. 1908. №29.

кертелеп, икмәк крестьян хуҗалыкларыннан көчләп тартып алына башлый һәм бу талау галәмәте сугыш беткәнгә кадәр дәвам итә.

Октябрь инкыйлабыннан соң да, татарларга караш уңай якка үзгәрми. Совет дәүләтенең социаль һәм милли сәясәте нәкъ элеккечә, романовларча дәвам итә.

1920 елда ниһаять, бик авыр сәяси һәм икътисади шартларда ТАССР төзелә. Әмма бу хәл шовинистик үзәккә, аларның бүлгәләп хакимлек итү максатларына һич тә туры килми. Республиканы төзү хакында сүз алып барганда ук, шушы 1920 елның башында Татарстанга 10 млн 120 мең пот икмәк хәзерләү планы йөкләнә. Бу планның биниһая зур булуы хакында Татарстан партия өлкә комитетының беренче конференциясендә бюро әгъзасы Иван Дерунов болай ди: “Әгәр дә без шушы 10 ярым миллион пот икмәк разверсткасын үтәргә тырышабыз икән, ачлыктан котылып булмаячак. Бу планны берничек тә үтәп булмый. Чөнки инде без авылның соңгы җебенә кадәр тартып-йолкып бетердек. Анда бер бөртек ашлык калмады. Республика составына кергән Минзәлә һәм Бөгелмә өязләре дә шушы ук авыр хәлдә. Алар да республика планын үтәрлек хәлдә түгел”[7]. Болай дип әйтүчеләр арасында бер Дерунов кына булмый.

Татарстанның шундый кыен хәлдә калуына карамастан, яңа оешкан хөкүмәт башында торган Сәхибгәрәй Сәетгалиев[8] һәм аның тарафдарлары Үзәктән төшерелгән планны аеруча үҗәтлек белән үтәргә керешәләр. Бик тиз генә крестьяннарга мөрәҗәгать әзерләнә. Мөрәҗәгатьтә разверстка планының берсүзсез үтәлергә тиешлеге, үтәмәгән кешенең җавапка тартылачагы әйтелә.

Мөрәҗәгатькә каршы чыгучылар да була. Мәсәлән, бу вакытта ВРК (Вакытлы революцион комитет) секретаре булган Шамил Усманов: “Мин халкыма чыгарылган үлем карарына кул куярга теләмим”, – ди. Җир эшләре Халык комиссары Юныс Вәлидов та әлеге канэчкеч документка кул куймый.

Мәскәү каршында яхшы исем казанасылары килгән сәетгалиевчеләр бу каршы чыгуларга колак салмыйлар. Республика гаять өлгерлек белән разверстканы үтәргә керешә. Тиз генә өч продтри-

[7] Таһиров И.Р. Гасырлар чатында. Казан: Мастер-Лайн, 1998. 238 б.

[8] 1920–1921 елларда Вакытлы революцион комитет (ВРК) һәм Халык Комиссарлары Советы рәисе.

бунал төзелә. Алар теләсә кайсы вакытта, теләсә кемгә хөкем карары чыгарырга вәкаләтле булалар. Разверстка планы һәр хуҗалыкка чәчү мәйданыннан чыгып таратыла, әмма гаиләдәге кеше саны исәпкә алынмый. Кем дә булса планын үтәмәсә, аны бөтен авыл халкы үтәргә тиеш була.

Крестьян бөтенләй хокуксыз бәндәгә әверелә, чөнки ул мәҗбүри хезмәткә тартыла. Һава шартлары, үз хәле, хуҗалыгы нинди булуга карамастан, ул теләсә нинди түрәнең әмерен тыңларга, теләсә нинди эшкә чыгарга мәҗбүр ителә. Бу ирексез чарадан хәтта дин әһелләре дә котылып кала алмый. Алардан юл салу һәм ремонтлау, утын хәзерләү, төяү һәм бушату өчен хезмәт батальоннары төзиләр. Күп кенә урыннарда мәчетләр эшләүдән туктарга мәҗбүр ителә.

Авыл халкына карата кабул ителгән карарлар коточкыч була. “Мондый хәлне бер ил дә, бер халык та, бер кайчан да күрмәгән”, – дип яза олуг галимебез И.Р.Таһиров[9].

Чынлап та, архивларда сакланып калган документларны укыганда, авыл халкының ыңгырашканын, җан газабын тойгандай, күз яшьләрен күргәндәй буласың. Кантоннардан килгән хәбәрләрдә продотряд кешеләренең аеруча кансызлыгы, явызлыгы хакында сөйләнә[10]. Бу миһербансызлыкка каршы ач үлемгә дучар ителгән крестьяннар баш күтәрәләр. Арча кантонының Арбор, Шубан, Әтнә, Кышлау крестьяннары, тартып алынган ашлыкны кире кайтарырга теләп, һөҗүмнәр оештыралар. Минзәлә, Бөгелмә кантоннарында тарихка “Сәнәкчеләр хәрәкәте” исеме белән кереп калган восстание башланып, тиз арада башка кантоннарга да җәелә[11].

Сүз дә юк, бу чыгышлар рәхимсез бастырыла. Балык Бистәсе районыннан алынган бер документта “чыгышларны бастырырга 3 взвод солдат һәм милиционерлар җибәрелде. Алар Масловка һәи күрше волостьтагы восстаниеләрне бастыруда зур активлык күрсәттеләр”, – дип әйтелә[12].

[9] Таһиров И. Гасырлар чатында. Казан: Мастер-Лайн, 1998. 240 б.

[10] ТР ДА. П-15 ф. 1 тасв. 110 эш. 12, 51, 73 б.; 104 эш. 42 б.; 197 эш. 3, 17 б.

[11] Шунда ук. 197 эш. 31 б.

[12] ТР ДА. П-15 ф. 1 тасв. 104 эш. 141 б.

1920 елның 1 декабренә разверстка планы 102 процентка үтәлә. Ашлыктан тыш, декабрь ахырларына крестьяннардан талап тагын 380 мең поттан артыграк ит, 1 млн 652 мең пот бәрәңге, 17 миллион данә йомырка, 11 мең пот май, 8880 пот бал, 227344 данә тире, 13276 пот йон, 4838 пот җитен, 4639 пот киндер сүсе җыеп тапшырыла[13]. Шулай итеп, крестьяннар киемсез калырга мәҗбүр була, чөнки күп вакытта алар үзләре өчен кием-салымны мал тиресеннән, йоннан, киндердән эшлиләр. Республиканың тегү һәм аяк киемнәре хәзерләү предприятиеләре булган запасларыннан армия өчен кием-салым тегеп җибәрәләр. Бу хәлләргә карамастан, Бөтентатар гадәттән тыш комиссиясе (Всетатчека) рәисе урынбасары Аким Денисов җитәкчелегендә көчләп җылы кием җыю кампаниясе җәелдерелә. Крестьяннарга азык-төлекне бары тик кибетләргә генә тапшыру рөхсәт ителә, базарлар ябыла. Ә кибетләрдә халыкка кирәкле керосин, тоз, шырпы, мануфактура товарлары бөтенләй диярлек булмый.

Болар өстәвенә, халыктан "чәчүлек орлыгын җыеп, җәмәгать амбарларына салабыз" дигән мәкерле сылтау белән, тагын 2 млн ярым пот икмәк тартып алына[14]. Димәк, 1921 елга халык икмәксез, чәчүлек орлыксыз килеп керә һәм рәхимсез ачлыкка, ялангачлыкка дучар ителә.

Шәһәр халкының да хәле авырая. Сугышлар тынгач һәм хәрби заказлар туктатылганнан соң, сугыш ихтыяҗлары өчен эшләп килгән предприятиеләр дә туктап кала. Шулай итеп, меңнәрчә кеше урамга чыгарып ташлана, барлы-юклы тиеннәрдән дә мәхрүм ителә.

1921 елның кышы бик салкын килә. Ашарга эзләп чыгучыларның күбесе юлда катып үлә. Салкын кыштан соң коточкыч корылык башлана. Яздан бирле күктән бер тамчы яңгыр төшми, җирләр яргалана. Ашарга яраклы үләннәр корып бетә. Кешеләр этләр, мәчеләр ашыйлар. Йорт хайваннарының саны бик нык кими. Идел буенда, чын мәгънәсендә ачлык, ялангачлык котырына.

Кантоннардан ачтан үлүчеләр хакында җан әрнеткеч хәбәрләр килә. "Җиде волостьтан алынган мәгълүматларга караганда, – дип хәбәр итәләр Чистай кантоныннан, – 1921 елның февраленә үлүчеләр саны – 50 мең кеше. Калган 18 волостьтан хәбәрләр килеп

[13] Вәлиев Р. Өзелгән дога. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 23 б.
[14] Шунда ук.

җитмәде”[15]. Мондый хәбәрләр Тәтеш, Спас, Минзәлә, Бөгелмә һәм башка кантоннардан да килә[16]. Мисал өчен, Спас кантоныннан килгән хисапта мондый саннар китерелә: кантонда яшәүчеләр саны барысы 236606 кеше. Шулардан – читкә азык эзләп китүчеләр саны – 23610, тулы ятим балалар – 3376, ярым ятимнәр 9385, ачлыктан шешенеп авыручылар – 25000. 1921 елның 4 нче августыннан 15 нче октябренә ачтан үлгән балалар саны 4077, олылардан – 4808 кеше исәпләнә[17]. Ни кызганыч, мондый тетрәндергеч хәбәрләрне һәм үлүчеләр саны турындагы белешмәләрне Татарстан кантоннарыннан килгән мәгълүматларның барысыннан да укып була. 1921–22 елларда ВЦИК (БҮБК) каршында һәм РСФСР Милләтләр эше буенча Халык комиссариатында ТАССРның вәкаләтле вәкиле Али Гани улы Ганиевнең Үзәккә җибәргән хәбәренә караганда, халыкның 70 проценты ачлыктан үлү дәрәҗәсенә җиткән[18].

Ачлык үзе белән тагын бер афәтне алып килә. Ул да булса – тиф авыруы. Ачлыкка һәм ялангачлыкка дучар булган халык бу афәтне дә җиңә алырлык хәлдә булмый инде. Тифтан үлүчеләрнең саны 1920 елда ук 218 меңнән артып китә[19].

Бу вакытта крестьяннарны тәмам бөлгенлеккә төшергән бәлаләрнең тагын берсе – янгыннар. Моны корылыктанмы, әллә башка сәбәпләре дә булганмы – әйтүе кыен. Янгыннар коточкыч дәрәҗәгә җитә. Бу афәт барлык кантоннарда да күзәтелә. Тулы бер авыллар дөрләп яна. Янгын беркемне дә аямый. Мәсәлән, Минзәлә кантонының Сарсаз авылында янгын чыгып – 150, Клюково авылында 80 йорт кара кисәүгә әверелә. Арча кантонының Яңа Шимбер авылында 228 йортның 128-е яна. Спас кантоны Тенишево авылында да 80 йорт янып бетә[20]. Янгыннарның бик тиз генә бөтен авылны камап алуы, бәлки, бер яктан, йортларның күпчелеге салам түбәле булуы да сәбәпледер. Икенчедән, ачлыктан интеккән кешеләрнең янгынга

[15] ТР ДА. Р-128 ф. 1 тасв. 179 эш. 1 б.
[16] ТР ДА. П-15 ф. 1 тасв. 118 эш. 5 б.
[17] Шунда ук. 19 б.
[18] Жизнь национальностей. 1922. №10. С.8–9.
[19] ТР ДА. Р-738 ф. 1 тасв. 219 эш. 5 б.
[20] ТР ДА. П-15 ф. 1 тасв. 197 эш. 31 б.

каршы торырлык көчләре дә булмагандыр дип, уйларга да җирлек бар.

Халык тәмам куркуга төшә. Крестьяннар бу хәлләрне “коммунистлар сәясәте” дип уйлый[21]. Алар гомер иткән җирләрен, ата-баба туфрагын ташлап, кан-кардәш халыкларга – Урта Азиягә, Себергә барып сыенырга телиләр. Юллар мөһаҗирләр белән тула. Татарстанны бу чорда 232 меңнән артык кеше ташлап китәргә мәҗбүр була. Аларның язмышлары хакында Татарстан Милли архивында кайбер мәгълүматлар сакланган. 1921 елда Бөтентатар гадәттән тыш комиссиясенә бирелгән язма отчетында комиссия әгъзасы Семенов Александр Республикадан китәргә теләп юлга чыгучыларның хәлен болай дип күрсәтә. “На основании Вашего приказа произвел вторичный осмотр мест расположения беженцев и рабочих на станции Устье[22], отправляющихся в хлеборобные губернии по нарядам Наркомтруда. При въезде на Устье находятся 1200 чел. совершенно под открытом небом, а часть в самодельных палатках.

По правой стороны Устья тоже находятся под открытом небом 300 чел. и далее под навесом около тысячи чел. Среди них обнаружены разлагающиеся трупы.

На станции также обнаружены больные и под открытом небом до 1000 чел. Все просят не бросать их на произвол судьбы. Начался сильный дождь, ветер. У беженцев кроме тряпья, чтобы огородить себя от холода, ничего нет. Медицинская помощь им не оказывается. Трупов, хотя и обращались к милиции, никто не убирает…”[23]

А.Семенов тырышлыгы белән качакларны Игумный бистәсендәге бушап калган казармаларга урнаштырганнар. Тик аларның күпмесе исән калган, күпмесе үлгән – билгесез. Югарыда искә алынган отчетында А.Ганиев мондый хәлләрне ачыктан-ачык күрсәтергә мәҗбүр булган. “Развитие тифа и смертность от голода среди беженцев не поддается сколько-нибудь даже приблизительному подсчету”, – ди ул Үзәккә бирелгән хисабында[24].

[21] ТР ДА. П-15 ф. 1 тасв. 197 эш. 3, 17, 40 б.

[22] Элек Казан елга порты Казансу елгасы тамагында урнашкан булган. Устье – шуны аңлата.

[23] ТР ДА. П-15 ф. 1 тасв. 202 эш. 79–80 б.

[24] Жизнь национальностей. 1921. №22. С.27.

Әйтергә кирәк, ачлык афәте көннән-көн көчәя барып, масштаблары киңәйгәч, 1921 елның августында Совет хөкүмәте, В.И.Ленин үзе ярдәм сорап, халыкара хәйрия оешмаларына мөрәҗәгать белән чыгарга мәҗбүр була. Илнең билгеле, дөньякүләм танылган шәхесләре, җәмәгать эшлеклеләре чит илләрнең мәһшүр зыялыларына хатлар язалар. А.М.Горький Герберт Гувер (Американың 1921 елдан сәүдә министры, 1929–1933 елларда президенты) аркылы Америка халкыннан ярдәм сорый, бигрәк тә ач балаларны коткарырга кирәклегенә басым ясый: "Ваша помощь будет вписана в историю как уникальное, гигантское свершение, достойное величайшей славы", – ди ул. Хатын-кызлар хәрәкәтенең күренекле җитәкчесе А.Коллонтай Норвегия галиме Фритьоф Нансенга мөрәҗәгать итә. Ниһаять, 1921 елның 18 июлендә БҮБК рәисе М.И.Калинин җитәкчелегендә Ачларга ярдәм оештыру буенча Үзәк Комиссия (Помгол) төзелә. Мондый комиссияләр тиз арада ачлыктан интеккән башка төбәкләрдә дә оештырыла. Татарстанда 28 нче июльдә төзелгән комиссияне Башкарма комитет рәисе Рәүф Сабиров җитәкли. Комисия үз эшен ачларның төгәл санын исәпләү, нинди һәи ничек ярдәм оештыру хакында төгәл мәгълүмат булдырудан башлый. 1921 елның җәендә урыннардан алынган мәгълүматларга караганда, Республикада соң дәрәҗәдә ачыгучылар барысы 2 млн 462599[25] кеше исәпләнә.

Бу факт ачлык 1921 елның көзендә башланган дигән фикернең ялгышлыгын раслый. Ачлык, 1920 елда, әйтеп үтелгәнчә, разверстка планын үтәп, халыкны тәмам талап бетереп, икмәксез, азыктөлексез калдырган вакытта ук башлана.

Помгол ҮКы эшкә тотыну белән, Россиянең хәвеф-хәтәрсез, уңышлырак губерналарына ачлыктан һәм корылыктан аеруча интеккән өлкәләргә ярдәм итүне йөкли. Татарстан Петроград һәм Владимир губерналарына беркетелә. Моннан тыш Смоленск, Витебск, Кострома, Тверь, Псков, Ярославль, Пенза һ.б. – барысы 11 губерна үзләрендә булган икмәктән Татарстанга өлеш чыгарырга тиеш булалар. Украина белән Белоруссия дә бу эштә шактый яхшы ярдәм күрсәтә. Республикага барысы 3 млн пот ашлык килә[26]. Азәрбәйҗан,

[25] ТР ДА. П-15 ф. 1 тасв. 197 эш. 98 б.

[26] ТР ДА. П-36 ф. 2 тасв. 3721 эш. 280 б.

Финляндия, Германия, Швеция кебек илләрнең ярдәмнәре дә килә башлый. Ниһаять 1921 елның 3 сентябрендә Казанга Американың ачларга ярдәм комиссиясе (АРА) вәкилләре килә. Башында Г.Гувер торган бу комиссиянең ярдәме хакында бераз соңрак тукталырбыз әле.

Болардан тыш, РСФСР Азык хәзерләү Халык комиссариаты 60 мең баланы тукландыруны үз өстенә ала. Аның акчалата ярдәменә 13100 пот икмәк, 5 мең пот он, 7450 пот ит, 14800 пот бәрәңге, 740 пот тоз алырга мөмкин була[27].

Татарстаннан разверстка белән тартып алынган азык-төлек күләме белән чагыштырып карасак, инде күрсәтеп үткәнчә, ачлыкка дучар булган 2 млн 462599 кеше өчен әлбәттә, бу ярдәм бик тә аз була. Республикага килгән ашлыкның күп өлешен 1922 елның язына кирәкле чәчүлек материалы итеп тә салып куярга туры килә. Татарстанга чәчүгә яраклы бөртек Россия төбәкләреннән барлыгы 4414 мең пот, чит илләрдән 160 мең пот китерелә.

Ачлык башлану белән, эмиграциягә киткән татар зыялыларының илдә калган олы шәхесләребезгә ярдәм итүләре хакында да әйтеп китәргә кирәк. Бу эшне башлап йөрүчеләрдән Манчьжуриягә китеп урнашкан, 1915 елда Троицкида үз акчасына мөгалимәләр хәзерли торган уку йорты ачкан игелекле җан Гайния Яушева һәм Вәли Апанаевларның исемнәрен атап китәргә кирәк. Алар, азык-төлек посылкалары салу өчен, исән калган зыялыларыбызның, укытучы-мөгаллимнәребезнең адресларын сорыйлар. Риза Фәхретдин аларга Сөнгатулла Бикбулатов, Борһан Шәрәф, Җамал Вәлиди, Фатыйх Әмирхан, Әхмәтһади Максуди, Зәкәрия Садретдинов, Гобәйдулла Буби, Ибраһим Терегулов, Габдулла Сөләйманов һәм Мөхетдин Корбангалиевләрнең адресларын җибәрә.

Ачларга ярдәм оештыруда Диния нәзарәтенең нәтиҗәле эше аеруча игътибарга лаек. Нәзарәттә мөфти Г.Баруди җитәкчелегендә халыкны ачлык афәтеннән коткару планы төзелә һәм Мәскәүдә өч кешедән торган Вәкаләтле комиссия оештырыла. Комиссиянең рәисе итеп Нәзарәтнең казые, халык арасында гыйлеме һәм әхлакый сыйфатлары белән зур хөрмәт казанган Кәшшафетдин хәзрәт Тәрҗемани билгеләнә. Ул бу Комиссиядә 1923 елның ахырына кадәр

[27] ТР ДА. П-36 ф. 2 тасв. 202 эш. 417 б.

эшли. Г.Баруди 1921 елның 25 августында Милләтләр эшләре буенча халык комиссары И.Сталинга рәсми булмаган хат яза. Ул фаҗиганың нинди куркыныч күләмдә җәелүен һәм продразверстканы ачлыкның төп сәбәбе икәнен ачыктан-ачык күрсәтеп бирә.

Шулай итеп, Диния нәзарәте Үзәктә оештырылган комиссия (Помгол) белән бергәләп эшли башлый. Чөнки бары тик бу оешма аркылы гына чит ил мөселманнары белән бәйләнешкә керергә мөмкин була. Ярдәм комиссиясенә күренекле дин әһелләре дә чакырыла. Мисыр, Манчьжурия, Финляндия, Кытай, Әфганстанга ярдәм сорап үтенеч хатлары җибәрелә. Мөселман дөньясында зур абруй казанган дин галимнәреннән Таһир хәзрәт Ильяси, Гобәйдулла Бубый Төркиягә, Садыйк хәзрәт Иманколый Урта Азиягә ярдәм җыярга китәләр. Әйтеп үтик: Төркия республикасы бу вакытта үзенең бәйсезлеге өчен Антантага каршы тигезсез сугыш алып барырга мәҗбүр була. Шулай да, Т.Ильяси һәм Г.Бубый Төркиягә килеп җиткәч, андагы газеталар: "Россиядән килгән диндәшләребез Әнкарага китә. Ачлыктан кырылучы шималь төркиләре өчен, Анталия мөселманнарының шәфкатенә өметләнеп мөрәҗәгать итәчәкләр," – дип язып чыгалар һәм халыкны ярдәм күрсәтергә чакыралар. Төркия халкы хәйрия җыя. Иң беренче нәүбәттә, азык-төлек тутырылган 125 посылка Татарстанның ач мөгаллимнәренә җибәрелә. Бер посылкада 2 пот ярым ак он, 5 кг кукуруз ярмасы һәм шул ук күләмдә шикәр һәм 20 банка куертылган сөт була[28]. Атап җибәрелгән бу посылкаларны татар халкының үз мәгърифәтчеләренә, зыялыларына олы ихтирамын күрсәтә торган гаҗәеп матур күренеш, дияр идем.

Татар зыялыларының һәм бигрәк тә мәгарифенең ни дәрәҗәдә аяныч хәлләрдә булганын язу – үзе бер тема. Тик архивтагы материалларны кем дә булса киләчәктә өйрәнеп язып чыгар микән? Бөтен мәгариф хезмәткәрләре, уку йортлары өчен уртак булган бер генә мисал китереп үтәм. 1921 елның ахырында Мамадышта эшләп килгән педагогия курслары ябыла. Сәбәбе: укыту өчен әсбаплар, кабинетлар, мастерскойлар һәм иң мөһиме – педагоглар җитешмәү. Күп кенә фәннәр бөтенләй укытылмый. Курсларны Алабугадагы

[28] Кара: Биктимирова Т. Ил язмышын салып иңнәренә. Казан: Алма-Лит, 2006. 120 б.

шундый ук курсларга кушалар. Ә бу уку йортының да аянычлы хәле хакында кантон мәгариф бүлеге отчётында мондый сүзләр язылган: “Курста укучыларның барысы да Татарстаннан, күбесе уңыш булмаган ач районнардан. Күпчелек укучыларның әти-әниләре ачтан үлгәннәр. Берничә укучыны хастаханәгә җибәрергә мәҗбүр булдык, чөнки алар ачтан шешенделәр…”[29].

Татар зыялыларының хәле, аларга Помгол тарафыннан җибәрелгән ярдәмнең ничек барып җиткәне хакында олуг язучыбыз Ф.Әмирхан истәлекләренә дә мөрәҗәгать итик. “Рамазан гаетенең өченче көнендә (9.X.1921) миңа Г.Баембитов һәм милиция начальнигы Х.Габидуллин килгәннәр иде. Гыйлемдар…. сөйләде: “Мәркәз рус мөхәррирләрен яхшы тәэмин итә. Монда да әле карт рус журналистларыннан берсе мәркәзнең әмере белән КаПУдан (Казанское продовольственное управление) үзенә тәмам җитәрлек микъдарда хосусый паек алып тора. Паегын алырга килгәндә сүз чыгарып, большевикларны, хәзерге властьны каты гына сүгеп, тәнкыйть итеп алырга да онытмый. Менә шундый бер тәэмин Тат. җөмһүрияттә татар мөхәррирләренә вә шул җөмләдән сиңа да ясалырга тиеш.

– Мин Совет мөәссәсәләренә (учреждениеләренә. – *Т.Б.*) йомыш төшеп барып, – дип яза аяксыз утырган татар классик язучыбыз, – бер нәтиҗә чыгаруның никадәр уңайсыз эш икәнен һәм үз тәҗрибәм һәм үземә мәгълүм башка кешеләрнең тәҗрибәләре белән бик яхшы белгәнлектән, бу мәсьәләне кузгатырга уйлап та карамадым”[30]. (1921 елдан хәзерге көнгә кадәр рус һәм татар мөхәррирләренең хәлләре арасындагы аерма хакында фикер йөртүне укучыларның үз хөкеменә калдырам. – *Т.Б.*).

Ачыгучы башка өлкәләр белән чагыштырганда, Татарстанга күрсәтелгән ярдәм хакында Мәскәүнең республикадагы чит илләрдән килгән оешмалар эшчәнлеген күзәтүче тулы хокуклы вәкиле В.А.Мускат, Үзәктәге җитәкчесе А.В.Эйдукка 1922 елның 7 февралендә җибәргән доклад язуында бик ачык итеп болай дип яза: “Мин Сезгә ата-аналарның ачтан үлгән балаларын ашаулары хакында рәсми хисап җибәргән идем, – ди ул. – Мондый очраклар, безнең

[29] ТР ДА. Р-3682 ф. 1 тасв. 394 эш. 10 б.

[30] Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 188 б.

бәхетсезлеккә каршы, һаман күбәя. Бу хәл үзе генә дә Татарстандагы катастрофик ачлык үзенең иң соңгы ноктасына җиткәнен күрсәтү өчен җитмиме?

Минем Сезгә тагын мәгълүматларны саннар белән генә күрсәтәсем кала, ул саннар, өстәп бернинди аңлатмасыз да, чит илләрдән, Помгол һәм дәүләт тарафыннан Татарстанга күрсәтелгән ярдәмнең ни дәрәҗәдә мескенлек икәнен күрсәтерләр. Мин, аңлы рәвештә Татарстан республикасына дип ассызыклап әйтәм, чөнки Россиянең ачлык булган башка районнарына ярдәм күбрәк күрсәтелә. Татреспубликага җибәрелгән вәкил буларак, бу нормаль булмаган хәл турында әйтүне үземнең бурычым итеп саныйм.

Әйе, Татреспубликада хәзер АРА эшли. Ә бүтән районнарга АРА шундый ук күләмдәге ярдәмне күрсәтмиме? Башка районнарда моның өстәвенә төрле-төрле башка ярдәм оешмалары, мисал өчен Нансенныкы, хәтта өлкәннәргә дә ярдәм итәләр. Татреспубликада мондый хәл бөтенләй юк.

Статистика мәгълүматларына караганда, Татреспубликада барысы 2797527 кеше исәпләнә, шуларның 969900е – балалар. Ярдәм оешмалары күрсәтүенчә, шушы халыкның бары тик 3 проценты гына яңа уңышка хәтле ярдәмсез барып җитә ала. Калганнары ач үлемгә дучар ителгән.

АРА 320000 баланы туендырлык азык бирә. Ә бит Чуваш өлкәсенә шушы паекларның 31000е, Мари өлкәсенә 16000е җибәрелә. Бу паеклар Татреспублика балаларына өстәмә ризык дип саналса да, аның бердәнбер, хәтта күп очракларда бөтен гаилә өчен икәне сер түгел.

Татпомгол, дәүләт рәсми оешмалары белән бергә, бары 254150 паек бирә. Алар исәпләвенчә, аның 75%ы балаларга, калганы – өлкәннәргә. Швеция оешмасының бөтен ярдәме 12 вагон он булды. Ул он Спас һәм Тәтеш кантоннарына җибәрелде. Германиянең Кызыл Хач оешмасы китәргә хәзерләнә, алар белән бергә Швециянеке дә китә. Димәк бу аз гына ярдәмнән дә мәхрүм калабыз.

Без күрәбез: 300000 бала бөтенләй ярдәм ала алмаячак, язмыш кочагына ташланган өлкәннәр хакында әйтеп тә торасы юк”[31].

[31] ТР ДА. Р-128 ф. 1 тасв. 174 эш. 1–2 б.

В.А.Мускатның Татарстан халкына карата күрсәткән шушы кайгыртучан хисләре, борчылулары өчен рәхмәт белән искә аласы килә. Аның язмаларына өстәп, тагын бер тетрәндергеч документны китерә.

Анда 1922 елның 15–22 гыйнварында, ягъни бер атна эчендә үлүчеләр хакында кантоннардан алынган аянычлы мәгълүматлар теркәлгән[32].

*Таблица 1*

| Кантоннар исемлеге | Барлык ачыгучылар | Үлүчеләр | |
|---|---|---|---|
| | | Ачлыктан | Тифтан |
| Арча | 388735 | 30 | 15 |
| Бөгелмә | 240310 | 5110 | 3063 |
| Буа | 147428 | 57 | 10 |
| Мамадыш | 152935 | 2371 | 121 |
| Минзәлә | 175530 | 1928 | күрсәтелмәгән |
| Зөя (Свияжск) | 165309 | 100 | 40 |
| Спас | 158271 | 217 | 20 |

Әйтеп үтик, документта бу саннарның әле тулы булмавы хакында да искәртелә.

Татарстан республикасында яшәгән балалар язмышына күз салсак та, шул ук фаҗигане күрәбез. Статистика мәгълүматларына карасак, 1920 елда республикада барлыгы 1208875 бала исәпләнә. (А.В.Мускат балалар санын 969900 дип күрсәтә. Димәк, 1922 елның февраленә балалар саны 236875 кә кимегән дигән сүз). Балалар хәлен яхшырту буенча төзелгән комиссия отчетына караганда, ул балаларның 253892се – дәүләт органнары, 25080е – Мәгариф комиссариаты һәм 9000 бала – Сәламәтлек саклау комиссариаты карамагында булганнар. Барысы 287972 бала. Тагын Казанда 27 ашханә ачылып, анда көнгә бер мәртәбә 24000 баланы ашата алганнар. Дөрес, 1921 елда балаларны Россиянең икмәкле өлкәләренә озату өчен Мәгариф комиссариаты каршында эвакуация бюросы оеша. Аның җитәкчесе итеп РКП(б) Өлкә комитетының хатын-кызлар бүлеге җитәкчесе һәм Мәгариф коллегиясе әгъзасы Зөһрә Әхтәм

[32] ТР ДА. П-15 ф. 1 тасв. 197 эш. 98 б.

кызы Баимбетова билгеләнә. Урамнарда, пристань, вокзалларда, ишек алларында, олы юлларда аунап яткан ачтан шешенгән, ертык киемнәрдән, тәннәрендә җаннары көч-хәл белән калган балаларга беренче ярдәмне күрсәтү өчен Казанда һәм кантоннарда 291 пункт ачыла. Әлеге пунктларда эшләү өчен хатын-кызлар бүлекләрендә эшләп килгән вәкиләләр җыелышлары әгъзалары һәм югары уку йортларында укучы студентлар тартыла. Алар эшне балалар өчен дарулар, кием-салымнар, ашханәләр өчен савыт-саба, кашыклар җыюдан башлыйлар (чөнки кайбер ашханәләрдә 80 балага бер кашык туры килгән). Нәкъ менә шул хатын-кызлар тырышлыгы белән балалар файдасына "Балалар атналыгы", "Кызыл Хач атналыгы", "Ачларга ярдәм атналыгы" һ.б. оештырыла.

Икмәкле өлкәләргә озату өчен балаларны башта беттән арындырырга, мунча кертергә, өс-киемнәре табарга, медицина ярдәме күрсәтергә кирәк була. "Үзләре дә ач хатын-кызлар балаларны коткару өчен чын көрәш фронты ачтылар", – дип яза хатын-кызларны оештыручы, танылган журналист Абруй Сәйфи[33].

Балаларны икмәкле өлкәләргә озату өчен махсус санитар поездлары оештырыла. Беренче поезд 1921 елның сентябрендә китә. Түбәндәге таблицада шундый 19 поезда кайсы өлкәгә күпме бала озатылганы күрсәтелә.

*Таблица 2*

1921 елның 6 октябреннән 1922 елның 19 маена кадәр
Казаннан озатылган ач балалар саны[34]

| Вакыты | Бару урыны | Барысы күпме | Шулардан | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | татар | рус | керәшен һ.б. |
| 6.09.1921 | Петроград | 499 | 381 | 118 | |
| 8.09.1921 | Тверь | 412 | – | 412 | |
| 8.10.1921 | Тверь | 473 | 400 | 73 | |
| 23.09.1921 | Бологое | 443 | 272 | 114 | 50 |
| 8.10.1921 | Омск | 490 | 318 | 126 | 46 |
| 12.10.1921 | Витебск | 612 | 251 | 361 | |
| 18.10.1921 | Семипалат | 476 | 476 | – | |

[33] Сәйфи А. Татар хатын-кызлары азатлык юлында. Казан, 1927. 45 б.
[34] ТР ДА. Р-3682 ф. 1 тасв. 356 эш. 20–21 б.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 21.10.1921 | Винница | 620 | – | 620 | |
| 6.11.1921 | Новгород | 588 | 244 | 344 | |
| 24.11.1921 | Баку | 460 | 422 | 38 | |
| 28.11.1921 | Харьков | 602 | – | 602 | |
| 4.12.1921 | Тула | 495 | 246 | 249 | |
| 10.12.1921 | Сәмәрканд | 300 | 287 | 13 | |
| 18.12.1921 | Винница | 550 | – | 550 | |
| 22.12.1921 | Семипалат | 601 | 245 | 356 | |
| 5.01.1922 | Гомель | 425 | 106 | 277 | 22 20 |
| 22.01.1922 | Винница | 590 | – | 445 | 113 32 |
| 25.04.1922 | Винница | 895 | 551 | 319 | 25 |
| 19.05.1922 | Гомель | 988 | 455 | 492 | 36 |

Татарстаннан барлыгы 30 меңнән артыграк баланы озату күздә тотылган. Ләкин архивларда озатылган 15 мең бала хакында гына мәгълүматлар бар.

Икмәкле өлкәләргә озатылган балаларның да хәлләре бик әйбәттән булмаган икән. Балаларның кире, ач Татарстанга әйләнеп кайтулары хакында хәбәрләр күп. Мисал өчен Татарстан Мәгариф комиссариаты күрсәткән саннарга карасак, 1922 елның сентябренә РСФСР өлкәләреннән 800 бала кире кайткан. "Бүгенге көндә балаларны коткару пунктларында 20000 бала бар, – дип күрсәтелә отчетта, – тик аларны киендерергә дә Комиссариатның мөмкинлекләре юк. Балалар 2 ай буе мунча кермәгәннәр, алар ач, туңалар, өсләре ялангач диярлек"[35].

Шул ук отчетта Самара, Сембер, Гомель "өлкәләреннән дә балаларның качып кире кайтулары хакында язылган. Бер бала хәтта Читадан кадәр кайткан. Сәмәркандта балаларны "балалык"ка дигән булып, батраклыкка алу фактлары булган һ.б.[36]

Республикада беспризорниклар (бөтенләй караучысыз балалар) 15 мең исәпләнә дип күрсәтелә отчетта. "Эвакоприемникларда Казаннан җыелган шундый 2500 бала бар. Аларның 70% тулы ятимнәр, 14000е балигъ булмаганнар"[37].

---

[35] ТР ДА. Р-3682 ф. 1 тасв. 356 эш. 35 б.

[36] Шунда ук.

[37] Шунда ук. 38 б.

1922 елда балаларны озату өчен җаваплы Зөһрә Баимбетова Бохара республикасына җибәрелә. Эвакуация комиссиясен Гришина Лидия Гавриловна җитәкли башлый. Аның ярдәмчеләре итеп И.А.Егоров, В.И.Никитский, И.Я.Чураев, Г.И.Иванов һәм С.М.Бессоновлар билгеләнә.

Нилектән бу балаларны озату һәм яңадан республикага кайтару бурычы йөкләнгән комиссиягә бер генә татар кешесе дә кертелмәде икән? Әмма аларның (хәзер мәрхүмнәр бит инде) татар балалары өчен җаннары кыйналмагандыр дип уйлыйм. Рухлары рәнҗемәсен. Кире кайтарылмаган бит күп кенә балаларыбыз!

Эвакуацияләнгән татар балаларының бер өлеше Тулага эләгә. Монда озата баручы Әхмәтов Һарун тырышлыгы белән махсус татар балалар йорты ачылган. Аның өстәвенә, Һ.Әхмәтов аларга татар телендә белем бирүгә дә ирешә алган. Тик Татарстанга кайткач, сүзлекләр төзү буенча фәнни мәкаләләр язып та тарихыбызда үз эзен калдырган бу олы йөрәкле җанның гомер юлы 1936 елда ук өзелә.

Петроградка эләккән татар балаларының язмышлары бәхетле булган икән. Аларны урнаштыру, торак һәм мәктәпләр белән тәэмин итү эше белән шәһәрнең Милләтләр эше буенча комитеты шөгыльләнгән. Балалар 13 йортка урнаштырылган. Мәктәпләрдә рус теле белән бергә татар теле дәресләре дә укытылган. Җәй көннәрендә аларны хәтта дачаларга алып чыкканнар. Бу эштә Казан университетының медицина факультеты студенткасы Зәйтүнә Яфуняеваның тырышлыгын аерым күрсәтергә кирәк. Үзенә бирелгән характеристикада аның балалар яныннан бер дә китмичә, хәлсезләрен күкрәге белән җылытып, күтәреп йөрүе хакында әйтелә. Татар укытучылары ирле-хатынлы Мостафа һәм Васфия Айнижановалар да шундый ук фидакарь җаннар булганнар. Васфия Ростов-Дон шәһәрендә "Исламия" мәдрәсәсен бетергән булган. Сембер губернасындагы Красный Остров мәктәбендә укытучы булып эшләгәч, 1921 елда Петроградка килгән һәм татар балалар йортында эшли башлаган, аларга үз ана телебездә белем биргән. Мостафа Айниҗан улы да хезмәттәшләре арасында "тәҗрибәле укытучы,

намуслы тәрбияче” булып хөрмәт казанган. Тик шәхес культы елларында репрессиягә эләккән һәм гаепсезгә үлемгә хөкем ителгән[38].

Ленинградтан балалар 1925 елда кире кайтарылган. Кайберләре, туган җирләрендә якыннары булмау сәбәпле, рөхсәт алып, бөтенләйгә шунда торып та калганнар[39].

1921 елның 3 сентябрендә Казанга Американың ачлыкка каршы көрәш комиссиясе килгәнен күрсәткән идек. Комиссия әгъзалары, килү белән, балалар учреждениеләрен ныклы күзәтү астына алалар. “Американлылар алып килгән азыкның беренче партиясе 50 мең баланы ашатырга җитте, – дип яза “Жизнь национальностей” газетасы. – Тагын 10 мең балага җитәрлек азык-төлек шушы елның 1 октябренә килеп җитәчәк. Моның өстәвенә, комиссия вәкилләре дарулар да китерәчәкләрен әйттеләр”.

Американлылар, республикадагы фаҗиганы күреп, ярдәмнең күләмен арттырырга вәгъдә бирәләр һәм шул вәгъдәләрендә торалар да. Ә шул ук вакытта Үзәктән (Мәскәүдән) килергә тиешле ярдәм һаман тоткарлана. Баштарак ярдәм поездлары Мәскәү белән Казан арасын 5 көндә үтсәләр, соңрак 20–30 көндә дә килеп җитә алмыйлар[40].

Американлылар Тәтеш, Чистай, Чаллы, Минзәлә, Пьяный Бор кантоннарында булалар. Аларга Татарстандагы юлларның начар хәлдә булулары бик нык комачаулый. Шуңа күрә алар, язын юллар өзеклеге башланганчы, ярдәмнәрен ничек тә ерак районнарга илтеп тапшыру өчен бик нык тырышалар. Урыннардагы хәлләрне үз күзләре белән күреп өйрәнгәч, азык-төлекне ерак районнарга да үзләре алып килгән автомашиналарга төяп илтәләр.

Американың ярдәм комитеты 1921 елның октябрендә 216031, ноябрьдә 574730 кешене туендырса, 1922 елның гыйнвар аенда бу сан 1291168 гә кадәр җитә[41]. Һичшиксез, АРА оешмасы, ярдәм оештырганда, иң беренче нәүбәттә балаларны күз алдында тота.

---

38 Тагирджанова А.Н. Книга о Мусе-эфенди, его времени и современниках. Казань, 2010. С.526–527.

39 Жизнь национальностей. 1922. №10. С.9.

40 ТР ДА. Р-128 ф. 1 тасв. 211 эш. 69 б.

41 Шунда ук. 174 эш, 1–2 б.

Ә Татарстанның бу вакытта бары 25 мең баланы гына ашатып торырга хәленнән килә. Түбәндәге таблицаларда АРА оешмасы тарафыннан Татарстанга күрсәтелгән ярдәмнең кайбер саннары китерелә.

*Таблица 3*

1921 елның сентябрь – декабрь айларында АРА тарафыннан татарстанлыларга бирелгән азык микъдары (потларда һәм кадакларда)[42]

| Ашамлыклар | сентябрь | октябрь | ноябрь | декабрь |
|---|---|---|---|---|
| Какао | 374,20 | 880,09 | 437,02 | 1431,16 |
| Шикәр | 1315,04 | 6441,18 | 1866,23 | 6213,20 |
| Сөт | 2460,17 | 9325,33 | 3908,18 | 15791,14 |
| Он | 8230,16 | 30211,37 | 10396,18 | 40402,34 |
| Кузаклылар | 1632,07 | 6460,24 | 2454,03 | 6462,30 |
| Дөге | 2818,35 | 10361,30 | 4064,08 | 4787,21 |
| Туң май | 775,24 | 1612,19 | 843,29 | 2745,21 |
| Кузаклылар өчен ярма | | | | 8543,23 |

*Таблица 4*

Шул ук ашамлыклар 1922 елда да бирелгән (потларда һәм кадакларда)[43]

| Ашамлыклар | гыйнвар | февраль |
|---|---|---|
| Какао | 1918,04 | 636,38 |
| Шикәр | 7617,24 | 4120,19 |
| Сөт | 16662,17 | 10727,13 |
| Он | 40586,01 | 52203,13 |
| Кузаклылар | 719,11 | 994,37 |
| Дөге | 1093,17 | 22032,13 |
| Туң май | 4048,31 | 1179,03 |
| Ярма | 14035,30 | 2843 |

Ашамлыкларга өстәп 1243 пот 24 кадак сабын январьда, 323 пот 16 кадак сабын февральдә китерелә[44].

[42] ТР ДА. Р-128 ф. 1 тасв. 174 эш. 14 б.
[43] Шунда ук. 15 б.

Болардан тыш АРА оешмасы балаларга кием-салым, дарулар, урын җир әйберләре белән дә ярдәм иткән. Таблицада ул ярдәм түбәндәге саннарда күрсәтелә.

*Таблица 5*

Балалар өчен җибәрелгән кием-салым[45]

| Кием-салым төре | 1921 елда | | 1922 елда |
|---|---|---|---|
| | Казанга | кантоннарга | |
| Ир балалар өчен костюмнар | 1039 | 3119 | 1077 |
| Кыз балалар өчен костюмнар | 1039 | 3119 | 1360 |
| Пальтолар | 510 | 7720 | |
| Аяк киеме | 1400 пар | 12012 пар | |
| Оеклар | 13412 пар | 11176 пар | 5491 пар |
| Свитерлар | | | 5447 |
| Панталоннар | | | 4748 |
| Кофталар | | | 2061 |
| Юбкалар | | | 2416 |

Моның өстенә, Америка ярдәм оешмасының медицина бүлеге 1921 елның сентябреннән 1922 елның мартына кадәр 12 вагон дарулар һәм хастаханәләр өчен кирәк-яраклар да җибәргән. Шулар арасында 5280 җәймә, 3746 одеал, 3213 пижама, 6803 сөлге, 16894 пар йон оекбашлар һәм 3103 пот медикаментлар булган. (Отчетта дарулар һәм сабын 3103 пот дип күрсәтелә)[46].

Шулай итеп, Американың шәфкать оешмасы Татарстанның 1 млн 200 меңнән артык кешесен ач үлемнән саклап кала. Бу сан республика халкының яртысын (!) тәшкил итә. Океан артыннан, ерак юллар аша Татарстан халкына ярдәм итеп, балалар оекларына кадәр китергән Америка халкына рәхмәттән башка сүз юк. Тик шунысы әрнетә: Ни өчен безгә бу яхшылыкны оныттырырга тырыш-

[44] ТР ДА. Р-128 ф. 1 тасв. 174 эш. 15 б.
[45] ТР ДА. Р-128 ф. 1 тасв. 174 эш. 17 б.
[46] ТР ДА. П-36 ф. 2 тасв. 21 эш. 62 б.

тылар соң? Тарих дәресләрендә бу олы җанлылыкка гел кире бәя бирелде. Ә бит тарих шаһит, ни кадәр бозып, кирәгенчә төзәтеп язсалар да, дөреслек бер калкып чыга. Ачлык башлану белән, Мәскәүдән ярдәм сорагач: “Сез автономияле республика, үзегез турында үзегез кайгыртыгыз”, – дигән җавап та архивта сакланып калган. Үзгәртеп кору (перестройка) елларында да шуңа охшаш сүзләрне ишетте бит Республикабыз.

Тагын мең тапкыр рәхмәт Америка халкына. Ә менә тарихка Татарстанның иң беренче Министрлар советы рәисе булып кереп калган, хәзерге көнгәчә урамга бирелгән исеме сакланган Сәетгалиев кайчан да булса вөҗдан газабы кичерде микән? Бу сорауны мин Мәскәүдә очрашкан вакытларда Зөһрә апа Баимбетовага (ул 1986 елда вафат булды) бирдем. Аның җавабын, үзгәртмичә бирергә тырышам, дәфтәремдә сакланган. “Җан газабы кичергәндер дип уйламыйм. Намуссыз кеше иде бит, – диде ул. – 1921 елда Мәскәүдәге хатынын ташлап (анысы татар иде), Казанда телеграфистка булып эшләгән Ольга исемле марҗага өйләнде. Шәһәр уртасындагы “Совет” кунакханәсендә бик зурлап туй ясады. Татарстанда ул вакытта Запастагы армия дә бар иде бит әле. Туйга менә шул армиянең оркестрын чакырды. Тәрәзәләрне ачып куеп, кунаклар күңел ачты. Ә шәһәр урамнары ачлыктан шешенгән, кая барып бер телем икмәк табарга тилмергән халык белән тулы иде. Туйдан соң Мәскәү гәзитләре “Пир во время чумы” дип язып чыктылар. Хәтерем ялгышмаса, аны Татарстаннан куып җибәрделәр.

Мәскәү аның бу “тырышлыгын” бәяләп, алтын сәгать бүләк итте. Татарстаннан соң Кырым республикасына җибәрде. Кырымда да ул ачлык оештырды. Аннан да кудылар. Соңрак Мәскәүдә төрле оешмаларда эшләп йөрде. Бүтән кирәге калмагач, культ елларында юкка чыгардылар үзен”.

Татарстан республикасы зур югалтулар белән ачлыктан чыга. 1923 елда хәл бераз җиңеләя төшә. Ләкин ярты миллионнан да артык (600 мең дип исәпләнә)[47] кешесен югалткан республиканың

[47] Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. 53 б.

хәле авыр булган дип белик. 86 мең (!) крестьян хуҗалыгы бөтенләй юкка чыга. Бу саннар төгәл түгел дип уйларга да җирлек бар. Чөнки авылларда кабер казырга да кешеләр булмаганда, нинди йөрәк, нинди көч табылсын да, кем төгәл итеп саный алсын? Кем юлларда үлеп калучыларны барлап, санап йөри алсын? Шуңа күрә дә халкыбыз тарихындагы бу фаҗигале еллар һәрберебезне бик җитди уйландырырга, халыкны ялганнан аера белергә өйрәтергә тиеш. Туган җиребез өстенә төшкән афәтләр дә ачлык белән генә дә бетми бит әле…

## ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТУГАН ҖИР ТАРИХЫ

Халидә Зиннәт кызы (Сафиуллина) Баһаветдинова – туган җиребез, мәркәзебез Казанның бай һәм катлаулы тарихын җентекләп өйрәнгән галимнәребезнең берсе. Ул 1961 елның 12 декабрендә Татарстанның Биектау районы Ямаширмә авылында эш сөючә Зиннәт абый белән Әминә апа гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылында ала. Кызының укырга сәләтен күргән әтисе аның алга таба да укып, зур белемнәргә ирешүен тели. Шуңа күрә Халидәсен Казан шәһәренең татар телендә белем бирә торган атаклы 10 интернат-мәктәбенә китереп урнаштыра.

Кызыксынучан укучы кыз өчен Казан шәһәре үзенә күрә бер гыйбрәтле дөнья – тарихи белем чыганагы булгандыр дисәм, ялгышмам төсле. Дәресләрдән тыш Казан буйлап оештырылган төрле экскурсияләр, Казанның атаклы галимнәре белән очрашу кызны тагын да канатландыра. Ул үзе дә киләчәктә белемнәрен тирәнәйтергә, шул тарихның билгесез сәхифәләрен ачарга хыяллана.

Мәктәпне уңышлы тәмамлау белән, Халидә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәи тарих институтына килеп, лаборант булып эшкә урнаша, бер үк вакытта Казан дәүләт университеты татар филология факультетының читтән торып уку бүлегенә укырга да керә. Эшне, укуны бергә алып бару җиңелдән булмаса да, тырыша Халидә, 1986 елда кулына диплом ала. Ул бу вакытта үзенә рухи һәм гыйльми үсештә зур ярдәм күрсәткән атаклы тарихчыгалим Җәмил Гыйльмановны рәхмәт хисләре белән искә ала. Аның бүген дә олуг галимгә булган ихлас ихтирамы сокландыра.

Ниһаять, Халидә Баһаветдинованың фәнни мәкаләләре бер-бер артлы дөньяга чыга башлый. Алар барысы да татар халкының бай мәдәният, мәгариф тарихын өйрәнүгә багышланганнар, туган мәркәзебезгә тирән хөрмәт, җылы хисләр белән сугарылып язылганнар. Алар җиңел укыла, укучыда зур кызыксыну тудыра.

Халидә бүген йөздән артык фәнни мәкаләләр, хезмәтләр авторы. Кайберләре үзе эшләгән Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәттәшләре белән бергәләп язылганнар.



*Халидә Баһаветдинова*

Шунысы куанычлы, ул яңа исемнәрне, мәгълүматларны фәнни бәйләнешкә кертә. Мәкаләләрендә күрсәтелгән вакыйгаларның заман тормышы белән тыгыз бәйләнешен ассызыклый. Аларның һәрберсен архив материаллары һәм газета-журналлардагы фактлар белән раслый.

Моннан тыш, Х.З. Баһаветдинованың каләменә тарихи чыганакларга җаваплы караш хас. “Олы тарих, милләт тарихы янәшәсендә, нәкъ менә шуларны баетып татар авыллары, сәүдә мәйданнары, көнкүреш үзенчәлекләре дә торырга тиеш”, – ди ул. Әйе, “Тамчылардан күл җыела” дигән мәкальдәгечә, авылларыбызның тарихи язмышы шәрехләнсә, халкыбызның бай тарихлы милләтләрнең берсенә әйләнүе шиксез бит.

Ә менә революциягә кадәр булган татар авыллары фәкыйрьлектә яшәгән дигән фикер белән килешми автор һәм шушы фикерне Казан арты районнарына караган авыллар тормышы белән раслый.

1944 елда Казан университеты тарихында беренче тапкыр татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. Бу эшне башлап йөргән һәм зур хезмәт күрсәткән Рабига Хәкимова хакында ул киң күләмле фәнни

мәкалә чыгарды. Бу хезмәт укучыларда зур кызыксыну тапты һәм 2024 елда юбилей уңае белән үзенең тиешле бәясен алды.

Болар өстәвенә, Халидәнең киң күңеллелеге белән аерылып торганын әйтми үтәргә һич тә ярамас. Ул – кызыклы шәхес. Эш сөючәнлек, иманда ныклык, милли мираска ихлас мәхәббәт – аның аерылмаслык сыйфатлары. Башка каләмдәшләренә карата эчкерсез ярдәмчел булганын да ассызыклап әйтеп китәм. Архивта аларның хезмәтләренә кагылышлы яңа материаллар тапса да шатлана, шунда ук яңалыклар белән бүлешә, уртаклаша. Шулай итеп, дистәләрчә яңа тарихи мәгълүматлар дөньяга чыга, фәнни әйләнешкә керә.

Кыз баланың шәхси тормышы да бар бит әле. Халидә Башкортстанның Кыйгы районыннан килеп Казан университетында укыган Зиннур исемле егет белән матур гаилә кора. Нияз исемле уллары туа. Тик кеше бәхете озакка барамыни ул. Зиннур инде вафат, урыны җәннәттә булсын. Ә уллары Нияз – Казан дәүләт университетының икътисад факультетын тәмамлый. Гарәп илләре икътисадын, банк системасын өйрәнгән. Игелекле белемнәр, якты киләчәк телик үзенә.

Ә Халидәгә иҗат уңышлары, сәламәтлек һәм бердәнбер баласының матур тормышына куанып, аның хөрмәтендә яшәсен дигән теләкләребезне юллыйбыз.

# УЛ ДӨНЬЯГА ИЗГЕЛЕК КЫЛУ ӨЧЕН ЯРАТЫЛГАН

Ходай кайбер кешеләрне, күрәмсең, җиргә гел изгелек кылу өчен яраткан. Язмам шундый изге затларның берсе, ТФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының тыйнак кына үз эшен җиренә җиткереп башкаручы хуҗалык бүлеге мөдире Әлфинур ханым Гыймадиева турында булыр.

Аның тормыш юлына күз салыйк. Татарстанның Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылында дөньяга килеп, сигезьеллык мәктәпне туган авылында, унынчы сыйныфны Яшел Үзән шәһәренең 5 нче номерлы мәктәбендә тәмамлаган кыз, бер ел “Серго” заводында эшләгәч, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетының журналистика бүлегенә укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлый. Яшь белгеч 1984 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалына караган Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият бүлегенә эшкә урнаша, 1996 елда Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтына күчә. Максаты – фәнгә кереп китү, гыйльми мәкаләләр язу, халкыбызның үткәндәге онытыла барган әдәби мирасын барлауга үзеннән өлеш кертү. Ләкин тормышның адәм баласы үзе дә киләчәктә ни көткәнен белми торган язылмаган кануннары бар шул. Кияүгә чыгу, бер-бер артлы өч бала табу, көтмәгәндә-уйламаганда җәмәгатенең үлеме, ялгыз әнисен карау – боларның барысы да аны фәннән читләштерә, әмма ул фән дөньясы кайнаган казан яныннан китми, инде менә 43 ел Фәннәр академиясе системасында галимнәргә эзләнүләр алып баруда уңай шартлар тудыручылар рәтендә хезмәт куя. Эш бүлмәләренең чисталыгы, конференцияләр вакытында кунакларны каршы алу һәм аларны кунакханәләргә урнаштыру, ашату-эчертүне оештыру, институт китапханәсен тәртиптә тоту, төрле юбилейлар уздыру, гыйльми диссертацияләр яклау, транспорт мәсьәләләре, ремонт эшләре һәм башка шундый бер караганда күзгә күренми торган вак-төяк булып тоелган мәшәкатьләр аның сан ягыннан артык зур булмаган бүлегенә карый. Хезмәт ветераны Әлфинур ханым үз вазыйфаларын җиренә җиткереп башкара, аның “Казанның 1000 еллыгы” медале, дәүләт оешмалары тарафыннан бирелгән күпсанлы рәхмәт хатлары, мактау грамоталары, бүләкләр иясе булуы бу фикерне ачык дәлил-



*Әлфинур Гыймадиева*

ли. Миңа калса, аның өчен иң мөһим бүләк – хезмәттәшләренең олы хөрмәте, тирән ихтирамы. Аңа киңәш, ярдәм сорап килүчеләрне ул игътибар белән тыңлар һәм һич тә кире бормас, хәленнән килгәнчә изгелек кылырга тырышыр, үзенә дә бер канәгатьлек хисе алыр. Ш.Мәрҗани исемендәге институтта булып киткән күпләр авызыннан: “Бинагызның эчке ягы бигрәкләр дә чиста, матур инде, коридорлардагы тәрәзә төпләрендә чәчәк атып утырган гөлләрегез генә дә ни тора!” – дигән сүзләрне минем еш ишеткәнем бар. Чыннан да, бина эче татар мохитенә хас булганча, балкып тора, аннан ниндидер бертөрле җылылык бөркелә сыман. Әлеге рухны “өрүче” дә Әлфинур ханым.

Тагын шунысын да билгеләп үтәсем килә: ул, “Әлмәт энциклопедиясе” проектында гыйльми мәкаләләре белән катнашып, үзеннән фәнгә аз гына булса да өлеш кертүгә иреште һәм яшьлеге теләген күпмедер дәрәҗәдә тормышка ашыра алды.

Гаиләсенә килгәндә, Әлфинур ханым – балаларының бүгенге көндә дә ныклы терәге һәм сөйгән әниләре, оныкларының яраткан юмарт әбиләре. Ике улын һәм кызын бер ялгызы югары белемле итте, өйләндерде, кияүгә бирде, гомерен шуларга багышлады. Туганнарын, күршеләрен, аны якыннан белүчеләрне гаять сокландыр-

ганы – Әлфинурның инде 90 ның теге ягына чыккан әнисенә карата булган эчкерсез мәхәббәте, җылы мөнәсәбәте, күрсәткән кадер-хөрмәте! Аллаһы Тәгалә әниемә озын гомер бирсен, саулыктан аермасын, дип яши ул, кылган догаларында Ходайдан шуны сорый.

Әлфинур туган авылындагы нигезне дә таркатмыйча саклый. Гаиләдә иң олысы булып үскәнгә, энекәшләрен үз тирәсенә туплап, йортны, мунча-каралтыларны төзек тота, бакчасында барысына да җитәрлек итеп җиләк-җимеш, яшелчә үстерә.

Әлфинур ханым кылган изге эшләре белән мактанып йөрмәс. Әйтик, аның институтта җыештыручы булып эшләп, күптән инде лаеклы ялга чыккан 91 яшьлек ялгыз карчыкның, кимендә атнага бер мәртәбә генә булса да, хәлен белешеп, табиблар чакыртып, юындырып, ашарына-эчәренә әзерләп йөрүен күпләр белмиләрдер дә әле. Шушы нисбәттән ирексездән яраткан шагыйребез Роберт Миңнуллинның зур мәгънәгә ия булган шигъри юллары искә төшә:

*“... изгелек эшләү җиңел түгел,*
*Ул – зур фидакарьлек...*
*Моның шулай икәнлеген*
*Күпләр яхшы аңлый.*
*Тик барыбер изгелекне*
*Һәркем эшли алмый.*
*Барыбыз да изгелеккә мохтаҗ,*
*Бу заманда бигрәк.*
*Изгелекне эшләү җиңел түгел,*
*Ә эшләргә кирәк!”*

Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел, – ди безнең татар халкы. Әлфинур иренең туган ягына юлны онытмый, аның каберен даими карап тора, Коръән ашлары уздыра, балаларын да шуңа өйрәтә. Кукмара районының Камышлы авылы зиратында җирләнгән, арабыздан вакытсыз киткән тарих фәннәре кадидаты, талантлы галимә, якын дусты булган Фәридә Гаффарова каберенә ел саен барып дога кылуны оештыруны да ул һич авырыксынмый.

Шушы көннәрдә Әлфинур ханым үзенең гомер бәйрәмен билгеләп үтәргә җыена. Аңа теләк шул: тирә-юньдәгеләргә, әниенә, балаларына карата кылган изге гамәлләрең үзенә дә изгелек, яхшылык булып кайтсын, йөзеңдәге сабыр елмаю безне озак еллар дәвамында шатландырып торсын иде!

***Биктимирова Тамина Ахметовна***

**Татарские женщины в нашей истории:**
сборник статей
[**Тарихыбызда татар кызлары:**
мәкаләләр җыентыгы]

*(на татарском языке)*

*Научно-популярное издание*

Оригинал-макет – *А.Р. Тухватуллина*
Подписано в печать 24.06.2025 г. Формат 60×84 $^{1}/_{16}$
Усл. печ. л. 15,5775  Тираж 100 экз. Заказ № 56/3

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии ООО «Фолиант»
420095 г. Казань, ул. Восстания, 100, корп. 6130 (корп. 153)
Тел.: (843) 212-52-25; e-mail: foliantkazan@mail.ru

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
**Татаровед.рф**